PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№8 (296) – АВГУСТ 2016

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Татарстандагы сөт елгалары

Борынгы тәңкәләр ни сөйли

«Эстрада да элитар була ала»

«ЕФӘК» УЗЫШЛАР КӨНДӘЛЕГЕ

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Рөстәм Шакиров
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Владимир Матылицкий
Татьяна Колчина
Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская,
bond@tatmedia.com
Авторлар: Алексей Бугарчёв, Катерина Котова, Айсылу Хаҗиева, Артур Хисмәтуллин
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Лайсән Әхмәрова
Тышлыкта: «Ефәк юл» раллиенда җиңүче Айрат Мәрдиев

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды:**

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-1925

Басарга кул куелды: 18.08.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76
Коммерция директоры урынбасары:
Айваз Диндаров, aivazid@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсәхова, тел. (843) 222-06-05
Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

АКЫЛЛЫ КЕШЕНЕҢ ҖАН ЭЗЛӘНҮЛӘРЕ

Карап торышка – барыбыз да шундый. Барлык төймәләргә дә төймәләнгән. Эшлекле кәчтүм. Галстук, портфель һәм корыч караш. Тормыш буенча – алга, ә баскычлардан югарыга гына атлаучылар без. Кайчак әйтик, иртән эшкә ашыгучы тигез сафларыбызга читтән караш ташласаң, имәнеп китәсең: гүя кешеләр түгел без, ә роботлар. Куркыныч булып китә хәтта: «Брр-рр!» Вәсвәсәдән арынып, роботларның берсе каршына киләсең дә, нәрсәдән эшләнгән икән бу кул дип, кагылып карыйсың. Ә ул, кинәт елмаеп, галстугын бушата да синең белән, ягъни очраклы бер узып баручы белән, бәхетен бүлешә: кичә кич кенә ул әти булган икән! Балалар йортыннан алганнар, үзләренең ике әзмәвере үсеп килүгә дә карамастан. Менә сиңа робот!

Ә икенче бер робот, анысы хатын-кыз җенесеннән, чак кына буш минуты табылуга, өенә шалтыратып, сораша башлый: «Ашаттыгызмы? Йоклап киттеме? Форточканы ябарга онытмагыз, юкса җил тиячәк!» Шулай ук гаиләдә яңа әгъза әллә?

– Кичә кызым урамнан ташландык песи баласы алып керде, – дип елмая робот. – Мин башта каршы идем, аннан кызгандым үзен – бөтенләй бәләкәч бит...

Шул мәлдә күз чите белән генә игътибарын эштәге нәрсәгәдер юнәлтә дә, карашы шунда ук кырыслана төшә, пиджагы барлык төймәләренә төймәләнә...

Менә шулай итеп әверелешле уйныйбыз. Эштә таулар күчерәбез, берәүгә дә тынгы бирмибез, ә авылга кайткач, әниебезнең бакчасында, сорау билгеседәй бөгелеп, карусыз гына колорадо кортларын чүплибез. Чөнки ул – әни, аның сүзе – канун, ул үзенең нәсел-нәсәбен бары тик үз бакчасында үскән файдалы бәрәңге белән генә туендырырга тели.

Гомумән, кризиска каршы торырлык затлар җитәрлек. Эре-эре оешмаларны банкротлыктан тартып чыгаралар, эштә көннәрен генә түгел, төннәрен дә уздыралар. Әмер биргәндә тавышларыннан колаклар үрә тора. Берәүдән дә «Юк!» сүзен кабул итәргә әзер түгелләр. Һичкемне һичничек үсендермиләр. Барлык киртәләрне һәм юлдагы дошманнарны алып атып, бары тик алга гына! Ә менә берәр кешенең борчуы барлыгын сизә калсалар, аннан да бигрәк – авыруын, карашлары мизгел эчендә җылынып китә, һәм ярдәмгә ыргылалар. Чын-чынлап, җанын да кызганмый!

Иң бөгелмәсләре, асфальтны тишеп чыккан чәчәкләргә сокланып, алар алдында тез чүгәргә дә мөмкиннәр. Суга батмас, утта янмаслары баласына операциягә акча җыеп йөргән әни кешене кызганып, яшь коя башларга да әзер.

«Робот» никадәр кырысрак, корычрак һәм сыгылмас-бөгелмәсрәк булсын, аның олы йөрәге шулкадәр үзен танытарак төшә. Бу кеше табигатенең какшамас кануныдыр инде. Һәм безнең баш миебез таулар күчереп, чүлләрне буйсындырып, елгаларның агышын кирегә борып йөргән арада, йөрәгебез туктаусыз яхшылыкка омтыла. Ышанмыйсызмы: безнең журналны укыгыз. Ул нәкъ менә шул хакта – акыллы гамәлләр, игелекле эшләр һәм мәңгелек кыйммәтләр аның нигезендә. Бу бит – безнең нигезебез, хәтта ки асылыбыз да. Аннан оялырга кирәкми.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
892 сум 32 тиен



КАЗАН. ПАТРИАРХ КИРИЛЛ ВИЗИТЫ КӨННӘРЕНДӘ

Солтан Исхаков фотосы.

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Сөт елгаларын ташытучы программалар. Сөтлебикә өчен тудырылган уңайлыклар

8. Березкада күпме алмагач бар? 2016 елгы авыл хуҗалыгы исәбен алу турында

14. Дәүләт хезмәтендә ничек уңышка ирешергә. Дәүләт идарәсе аппаратының заманча системасында мифлар, проблемалар һәм көндәшлелек

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

26. «Татарстанның» алтын запасы. ТР тарихы мизгелләре

28. «Ефәк юл» сикәлтәләре. «КАМАЗ»лар Ак юлбарысны ничек куып тоттылар

32. Алга, тәм-том артыннан! Үзебезнең гастрономик брендлар турында

36. Теләчедә кунакта. Эх, җиләкле җәйләре…

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

42. Тарих сәхифәләре. Борынгы тәңкәләр ни сөйли

46. Бәя югары, әмма бик шәп түгел. Тәкәсез Сабантуй

50. Резеда Әхиярова белән әңгәмә. «Без хәзер бик аз калдык»

54. Сәяхәтләр. Китаплар салган маршруттан…

58. Туфан Миңнуллинны искә алып. «Үзем турында үзем»

86. Югары Ослан районы. Палеозойдан Иннополиска кадәр

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР



27.07

Василий Мосин, 2012 елгы Олимпия уеннары призеры, – ВАДАның россиялеләрне Рио-де-Жанейродагы Олимпиададан читләштерергә уйлавы турында:

– Мин моны юләрлек, дип әйтмәс идем. Бу җентекләп планлаштырылган акция, аның авторлары очраклы кешеләр булмаган, югары вазыйфалар биләгән, үз сүзләре өчен җавап бирә торган кешеләр алар. Максатлары – әлбәттә, гадел түгел. Ни өчен допингтан чиста спортчылар интегергә тиеш? Мин монда сәяси моментны, безнең илебезгә мөнәсәбәтне күрәм.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Фото: Солтан Исхаков

21.07

Мәскәү һәм бөтен Русь Патриархы Кирилл – Татарстан Президенты белән очрашудан соң, мактаулы кунаклар китабында:

– Чәчәк атучы Татарстанны – православиелеләр һәм мөселманнар үзләренең кече ватаны һәм бөек Россия иминлеге өчен иңгә-иң торып эшләгән җирне күреп сөенәм. Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевичка кунакчыллыгы, православиелеләр һәм мөселманнарның озак еллар буе дәвам иткән үзара мөнәсәбәтләренә югары толерантлык күрсәтүе өчен рәхмәт белдерәм.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

21.07

Сергей Нарышкин, РФ Дәүләт Думасы Рәисе, – Казан Мәрьям-Ана иконасы табылган урында төзеләчәк гыйбадәтханә нигезенә беренче ташны салган вакытта:

– Татарстанда изге урыннарны яңадан булдыру һәм яңадан торгызу – бу бердәнбер вакыйга түгел, бу еллар буена һәм хәтта дистә елларга исәпләнгән даими максатчан эш. Биредә диндарларның ихтыяҗларын яхшы белеп һәм толерантлык күрсәтеп кенә калмыйлар, ә бәлки традицион дини җәмгыять вәкилләренең барлык игелекле башлангычларына конкрет ярдәм дә күрсәтәләр. Күбесенчә шуңа күрә дә күпмилләтле Татарстанны һәм Казанны милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм татулык аерып тора.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Сөтлебикәләр өчен **КАЙДА** кунакханәләр төзелгән

Авыл хуҗалыгы исәпкә алулары **НИЧЕК** бара

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Мәктәп һәм балалар бакчаларын капиталь ремонтлау Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү **Сыер абзарларын капиталь төзекләндерү** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ.
НӘТИҖӘЛӘР

СӨТ ЕЛГАЛАРЫН ТАШЫТУЧЫ ПРОГРАММА

Сыер абзарларын төзекләндерү буенча республика программасы 2014 елда гамәлгә кертелде. Чыгымнарның 30 проценты субсидия рәвешендә кире кайтарылу нәтиҗәсендә, Татарстанда йөзләгән хуҗалыктагы сөтлебикәләр өй туйларын «бәйрәм итте».

Автор:
Линар Закиров

Теләче районындагы «Алан» хуҗалыгының баш мал табибы Сәйдәш Дәүләтшин, көтүлеккә килеп туктагач, сыерлар аның УАЗ машинасын сырып алды: берәүләр көзгегә карана, икенчеләре кашына, өченчеләре тыныч кына «абый»ларын күзәтә. «Хуҗалыгыбызда 2200 баш мөгезле эре терлек бар, шуның 620се – савым сыеры», – диде ул.

ИТ, СӨТ, БОДАЙДАН – 103 МИЛЛИОН

«Алан» хуҗалыгында сөт елгалары агыпмы-ага: елына 39 меңнән артык центнер савып алалар. Моннан тыш, өч мең центнер ит җитештерелә. Иген дә мулдан чыга: быел урыны белән гектардан 56 центнерга кадәр җыеп алынган.

– Ит, сөт тапшыру һәм бодай сатудан 103 миллион сумнан да артык табыш керә. Сөтне бер генә урынга тапшырабыз. Юкса, безгә дә китерегез, дип артыбыздан йөрүчеләр күп. Сөтне бүген – бер урынга, иртәгә икенчесенә ташып йөреп булмый. Тотрыклылык булырга тиеш. Сатудан кергән акча хуҗалык казнасына керә, – диде Теләче районындагы иң алдынгы хуҗалыкларның берсе – «Алан» җитәкчесе Хәбир Фәсхетдинов.

– 100 миллионнан артык акчаны кая куеп бетерәсез? – дим.

– Былтыр сыер абзарларын ремонтлау буенча республика программасы кысаларында күршедәге Балыклы авылының «Байкал» хуҗалыгында 100 һәм

Фото: Ната Смирнова



200 башка исәпләнгән ике сыер абзарын төзекләндерүгә 40 миллион сум тоттык, бер өлешен республика казнасыннан кайтардылар. Быел, май башында, Алан авылындагы өч сыер абзарын ремонтлауга керештек. Августка эшләрне тәмамларга ниятлибез. 25 миллион сум тотылды инде, әмма ул гына җитми, тагын кирәк.

– Әлеге абзарлар 80нче еллар ахырында төзелеп, искереп бетте инде. Яңа техника керә алмый, шуның өчен керү юлларын киңәйттек, абзар алдына бетон юллар салдык, – дип сөйләде Хәбир әфәнде.

Хуҗалыкның Алан, Мәтәскә, Балыклы һәм Күкчә авылларындагы бүлекләрендә барлыгы 155 кеше эшли. Уртача хезмәт хакы – 17 мең сум, вакытында түләп барабыз, дип ышандырды безне җитәкче. Үз авылларында эшче куллар җитмәгәнгә, «Алан»га уңган-булганнарны күрше-тирә авыллардан да җәлеп итәләр.

– Былтыр кыйммәтле комбайн алдык. Хуҗалыкта кеше саны кимесә дә, басуда техника эшләп торырга тиеш. Яңарту эшләре алып барыла башлагач, соңгы ике-өч елда ит белән сөт күләме сизелерлек артты, – диде Хәбир Фәсхетдинов.

ШӘҺӘРНЕ МАКТА – АВЫЛДА ЯШӘ

Яшь белгеч Гаяз Кашапов – хуҗалыкта куркынычсызлык техникасы буенча инженер, шул ук вакытта төзелеш эшләре өчен җаваплы. 2012 елда Казанның аграр институтын тәмамлап, ике ел башкалада эшләгән. Әмма күңеле барыбер туган ягына тарткан.

– Яшь белгечләргә каралган торак алу программасына чиратка бастым быел. Яңа елга кадәр бирергә вәгъдә иттеләр. Аңа ия булу өчен, хуҗалыкта килешү нигезендә, кимендә, биш ел эшләргә кирәк, ике елы үтте инде. Безнең авылда берничә ел элек кенә салынган Яшьләр урамы бар, минем кебек белгечләрнең күбесе шунда. Гаиләм белән әти-әниебездә торабыз. Булачак йортыбызның кирпечтән һәм 860 мең сумлык икәнен беләм, мәйданы әлегә билгеле түгел, – дип сөйләде ул.

PRESSA.RU

Моңа чаклы һәр абзарда берьюлы алты сыер савучы эшләсә, президент программасы «килеп җиткәч», сменага бишесе чыгып, берсе чират буенча ял итәчәк.

«Алан»да җитештерү базасын яңартуга һәм ныгытуга акчаны кызганмыйлар, кредитлар да алалар. Хәбир Фәсхетдинов әйтүенчә, озакламый терлек азыгы цехы да ачылачак.

Сүз уңаеннан, сыерларның өй туен үткәреп бетергәч, каршыда гына урнашкан бозау абзарларына да күчмәкчеләр. Югыйсә, «кечкенәләр» үзләренең искереп беткән «торак»ларында бигрәк моңсу күренә. Бәлки, яңа абзарда кәефләре күтәрелер.

«АВЫЗЫҢА КАПМА!»

Баш мал табибы Сәйдәш Дәүләтшин, профессиональ белем алуга ук, «Алан»га эшкә килгән. 13 ел инде узып та киткән.

Без килгәндә (хәер, җәй саен шулай) абзарда күгәрченнәр генә йөри иде, ә сыерлар – кардада. Сәйдәш безне көтүлеккә алып барды. Аклы-каралы сөтлебикәләр безнең белән шулкадәр кызыксынды, түгәрәккә әйләндереп алдылар.

– Сыер – сыер инде ул. Сөтлебикәләр белән кешеләрнең авырулары уртак, терлекнең сәламәтлеген кайгыртырга, вакытында прививкалар, вакцинацияләү ясарга кирәк. Билгеле, һәр сыерның холкы үзгә, кайсысыдыр тыныч, кайсысыдыр котырынкы. Кызу канлыларны кайвакыт дарулар ярдәмендә тынычландырабыз, – дип елмайды Сәйдәш.

– Абзарларны төзекләндерү сыерларга ничек тә булса тәэсир итәме?

– Әлбәттә. Беренче чиратта, микроклиматка игътибар итәргә кирәк. Абзарда вентиляция яхшы эшләп, һава коры, дымсыз булса, сыер азрак чирли, сөте тә сыйфатлырак була. Кеше саву процессында никадәр азрак катнашса, шулкадәр яхшырак, маститның килеп чыгу ихтималы кими, – дип аңлатты әңгәмәдәш.

Аның сөйләвенчә, сыерның уртача гомер озынлыгы – 15-20 ел. Әгәр ул тәүлегенә 40-50 литр сөт бирсә, азрак яшәячәк. Чөнки энергетик ресурслары сөт белән чыгып китеп, организмы тиз таушала. Шуңа да андый сыерлар үз гомерендә 5-6 тапкыр гына бозауларга өлгерә. Ахыр чиктә, йончыган мал иткә җибәрелә, фәнни телдә бу «браковка» дип атала. Андый сөтлебикәне асраудан мәгънә юк, бөтен мөмкинлекләрен сарыф итеп бетергәч, ул 10 литр чамасы гына бирә ала.

Сыерлар сөтне төрле күләмдә бирә. Бу аның физиологиясенә һәм генетикасына бәйле. Әнисе 25-30 литр сөт биргән булса, кызы да шундый ук күрсәткечләр белән сөендерәчәк. Орлыкландырудан, ягъни үгездән дә күп нәрсә тора икән.

Төзекләндерү эшләренә килсәк, сыер абзарларының эчендәге җиһазларны тулысынча алыштырганнар. Бәдрәф белән душ та хәзер шунда булачак, эшчеләрнең хезмәт шартлары бермә-бер яхшыра, дигән сүз.

Иң күп вакыт һәм көч бинаның тышын төзекләндерү, металл корылмаларны урнаштыруга киткән. Сыерларга абзардагы уңай һава торышы – микроклимат булдыру өчен бөтен нәрсәне бөртекләп башкару сорала. Элек савучылар сөтне чиләкләп ташыса, яңартылган абзарда сөтүткәреч сузалар. Сөт торбалардан турыдан-туры суыткычка агып китәчәк. Һәр доярканың күпме сауганын компьютер исәпли.

– Сыер абзарларыннан кала, аларны тоташтыра торган сөт блогын да рәтлибез. Һәр абзарның үз суыткычы булачак. Микроклиматтан күп нәрсә тора. Былтыр «Байкал»дагы абзарларны тәртипкә китергәч, быел сөтне 30 процентка күбрәк ала башладык. Кышын көнкүреш бүлмәләре белән сөт саклана торган бүлмә генә җылытыла. Ә абзарда аның кирәге юк, сыерлар җылыны үзләре бүлеп чыгара, – дип аңлатты Гаяз.

Программа эшли башлады:

2014	2015	2016
Төзекләндерелгән корылмалар саны: 274	Төзекләндерелгән корылмалар саны: 261	Объектлар лимиты: 301



Сыер абзарларын капиталь төзекләндерү буенча республика программасы

	2014	2015	2016
Финанслау күләме:	**~ 1,829 млрд сум**	**~ 1,442 млрд сум**	**~ 1,298 млрд сум**
Республика бюджетыннан:	470,7 млн сум	389,5 млн сум	389,5 млн сум
Бюджеттан тыш чыганаклардан:	1,358 млрд сум	1,052 млрд сум	908,7 млн сум

«Алан» хуҗалыгында, сөтне күбрәк җитештерү максатында, голштино-фриз токымына өстенлек бирәләр. Мәнине «Татарстанның элиталы орлыклары» оешмасыннан алып, сыерны шуның белән орлыкландыралар.

– Орлыкландырылмый торган – кысыр сыерларны иткә җибәрәбез, – диде Сәйдәш.

– Нишләп сыерларыгызның мөгезләре төрле зурлыкта: кайберләренеке бик кыска, ә кайберләренеке галәмәт озын? – дим, машинага кашынып торган сөтлебикәләргә карап.

– Бозауларның мөгезләрен яндыра башладык инде. Юкса, бер-берсе белән сөзешеп күңел ачалар да, соңыннан җәрәхәт белән йөриләр. Малны гел карап торырга кирәк. Тимерчыбык, кадак йотып үлгән чаклары да булды. Аларга, авызыңа капма, дип әйтеп булмый бит.

Ралиф Низаметдинов, Теләче районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы:

- «Алан» хуҗалыгы сөт җитештерү буенча алдынгы урында: район күләмендә тәүлеккә 13,2 литр савып алынса, аларда – 17,1 литр. Ашлык белән дә шул ук хәл: гектардан 35 центнер чыга. Алар язгы чәчү эшләрен беренче булып башлыйлар, урып-җыюны да беренче булып тәмамлыйлар.

Сыер абзарларын төзекләндерү программасы кысаларында «Алан», башка хуҗалыкларга караганда, күбрәк корылмаларын тәкъдим итте. Программа шартлары буенча, чыгымнарның 30 процентын – хөкүмәт, 70 процентын хуҗалык үзе каплый. Әмма «Алан» хуҗалыгы үз акчасын күбрәк тә тотты. Мондый чаралар авыл хуҗалыгын, һичшиксез, алга этәрә. Иген саклау буенча да берәр программа эшләсәләр, яхшы булыр иде. Заманча технологияләр ярдәмендә коры җәйдә дә әйбәт уңыш җыеп алырга була.



Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU



Фото: Ната Смирнова

АВЫЛНЫҢ
АВТОПОРТРЕТЫ

Биектау районының Березка авылында 2016 елгы авыл хуҗалыгы исәпкә алуы турындагы репортажыбыз яңгырап торган ырылдау, бердәм рәвештә кешнәү һәм хайваннар дөньясына хас башка шуныңише авазлар астында узды. «Татарстан» хәбәрчеләре өчен көтелмәгән хәл шул булды – үз хуҗалыкларының хәлләрен сөйләгәндә, гражданнар бер нәрсәне дә яшерми һәм гаҗәеп тыныч күренәләр.

Автор:
Рөстәм Шакиров

PRESSA.RU

– Бездә бит халык төрле продразвесткадыр, алмага салымдыр ише нәрсәләрдән тәмам куркып беткән. Ә кем дә булса нәрсәне дә булса яшереп калырга теләсә? Нишләп соң халык исәпкә алуны шулай тыныч һәм аңлау белән кабул итә, сезнеңчә? – дип сорыйм Татарстанстатның Биектау районы буенча бүлекчәсен җитәкләүче Аида Евдокимовадан, Березкага барганда. Сүз уңаеннан, Березка авылы үзе район үзәгеннән 15 километр ераклыкта урнашкан.

– Беренчедән, яшерүдән бернинди мәгънә дә юк, киресенчә, күрсәтү файдалырак, мондый очракта дәүләттән субсидиягә өметләнергә мөмкин, – ди Аида Марселевна. – Исәпкә алу бит бер максат белән уздырыла – бездә авыл хуҗалыгы хәзер нинди хәлдә икәнлеген ачыклау өчен. Нинди тенденцияләр бар да, җирләр ничегрәк кулланыла һ.б. шундый мәсьәләләр. Алга таба рациональ карарлар кабул итү өчен кирәк бу. Сүз уңаеннан, исәпкә алучы, иң беренче эш итеп, алынган мәгълүматларның беркайда да таралмаячагын, аннан да бигрәк, шәхси үзенчәлекләренең бетерелүен игълан итә. Аларны гомумиләштерү исә бары тик район дәрәҗәсендә генә булачак. Икенчедән, исәпкә алучылар итеп без халык яхшы белгән кешеләрне сайларга тырыштык. Чөнки аларга ышаналар.

УСАЛ ЭТ ЧЫКСА – НИШЛӘРГӘ?

Безне Березкада каршы алган Миләүшә Газизуллина бу критерийларга тулаем туры килә. Әйтергә кирәк, без аны ерактан ук күреп алабыз, чөнки, телефоннан сөйләшкәндә вәгъдә иткәнчә, ул «ориентир» булып басып тора – зәңгәр униформадан (жилет белән кепка) һәм иңенә аскан «Росстат» дип язылган букчадан. Миләүшә Рафисовна җирле Мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли, авылда аны белмәгән кеше юк. Хәер, мондый эшкә дә беренче җәлеп ителүе түгел. Дөрес, бу юлы ул Березкада гына түгел, ә Березка авыл җирлегенә караган һәм халык яши торган калган дүрт пунктта да эш алып бара. Миләүшә Рафисовна әйтүе буенча, халык анда да бик илтифатлы.

Мин кешеләргә башта ук әйтеп куям: «Барлык мәгълүматлар да статистика өчен генә туплана. Мин бит сездә инде ун ел элек булган идем (2006 елда уздырылган беренче авыл хуҗалыгы исәпкә алуы турында сүз бара. – Ред.), йә шуннан соң нинди дә булса артык салым белән интектерделәрме сезне? Юк лабаса». Моннан тыш, без барысын да хуҗаларның үзләре сөйләгәнчә язып алабыз һәм теркибез, бу мәгълүматларны тикшерергә хокукыбыз юк. «Минем ачык җирдә биш квадрат метр кыяр түтәлем бар», – дип әйтәләр икән, мин шулай теркәп тә куям. Сарайларга кереп йөреп, әйткәннәрен тикшерә башласаң, билгеле, сиңа берәү дә телен чишмәячәк.

Исәпкә алучының кулында – планшет, мәгълүматларны ул шунда теркәп бара. «Мейд ин Россия, – дип шәрехли Аида Марселевна. – Планшет белән эш тизрәк бара. Каян, дисезме? «Росстат» өләшеп чыкты. Кире кайтару шарты белән, әлбәттә».

– Ә исәпкә алучыны усал эт каршыласа, нишләргә? – дип төпчеләм Евдокимовадан. Без авыл урамыннан барганда, бер капка артыннан котырып өргән тавыш ишетелә чөнки. – Йә булмаса – холыксыз бер алкаш?

– Әйе, бу чыннан да проблема булырга мөмкин, исәпкә алу эше белән, җитмәсә, күбрәк хатын-кызлар шөгыльләнә, – ди әңгәмәдәшем. – Әмма алар-

– Респондентлар ничек әйтә, шулай язабыз. «Минем биш квадрат метрлы ачык җирдә кыяр түтәлем бар», – дип әйтәләр икән, мин шулай теркәп тә куям.

– Уңышны каямы? Үзебезгә, балаларга, үзара бүлешәбез инде.



– Бассейн бар тагын, аны да теркәгез.



– Яшерүдән бернинди мәгънә дә юк, киресенчә, күрсәтү файдалырак, мондый очракта дәүләттән субсидиягә өметләнергә мөмкин.

ны сез әйткән кебек адреслар буенча чыкканда, участковый озатып бара. Моннан тыш, исәпкә алучылар бәхетсезлек очракларыннан да иминиятләштерелгән. Ә болай, авыл җирендә хәзер бит нигездә әбиләр яши, алар чыгалар да барысын да сөйләп бирә, бигрәк тә – белгән кешеләренә. Менә Биектауда, мәсәлән, хәлләр кыенрак. Анда халык та яшьрәк, җитдирәк, димме – биек диварлар артында җиде кат йозакка бикләнеп яшиләр алар...

Биектау районында 40 исәпкә алучы бар. Нигездә, болар – авыл җирлегендәге секретарьлар һәм Мәдәният йорты хезмәткәрләре. Студентлар да бар – алар икәү. Исәпкә алучылар ике айга якын срокка ялланалар. Эш хакы – айга 16500 сум (чагыштырыр өчен – 2006 елда бу сумма 3300 сумны тәшкил иткән иде). Йөкләмәләргә килгәндә, һәрберсенең – үзенеке, уртача бу 460-500 йорт-хуҗалыкны үз эченә ала. Бер көндә 10-15 йортны йөреп чыгарга кирәк дигән сүз.

АЛМАЛЫ ЕЛ БУЛМАСА ДА...

Беренче капкага кагабыз, ишегалдына узабыз. Күренеп тора: монда нык, таза тормыш белән яшиләр. Капка баганалары өстенә үзенчәлекле каланчалар ясап куелган, ишегалды уртасында – кулдан ясап куелган фонтанлы күркәм генә кечкенә буа, як-ягы матур ташлар белән бизәлгән. Янәшәдә генә – беседка, аннан арырак – күбек бетоннан эшләнгән дәү сарай.

Миләүшә Рафисовна тавышына йорттан хуҗабикә әби чыга, безнең өчен ул – «шәхси ярдәмчел хуҗалыкның башлыгы» (ЯХБ). Ул безне өйгә чакыра, әмма без аңа үз тәкъдимебезне җиткерәбез – исәпкә алуны монда, саф һавада, беседкада гына үткәрик әле, дибез. Әбиебез җиргә кагылышлы документларны алып чыгаргамы-юкмы, дип белешә. «Мәҗбүри түгел, без бит салым хезмәтеннән килмәдек», – дип җавап кайтара Миләүшә Газизуллина. Әңгәмә татар телендә бара – аңлашыла ки, Татарстандагы авылларда йөри торган исәпкә алучыларга ике телне дә камил белергә кирәк.

Бирелергә тиешле сорауларны Миләүшә Рафисовна инде яттан белә.

– Җиде сутый, – әбекәй бакчалары турында сүз алып бара. – Бәрәңге бакчабыз да, шулай ук, җидегә тула.

Йортның хуҗасы кайтып керә – бабакайның кулында яңа гына җыеп алынган әтәч гөмбәсе белән яртылаш тулы пакет. Ул, керә-керешкә, сорауларга җавап бирергә керешә.

– Җидәү без, – ди. Йортта теркәлүчеләрнең исәбе шулкадәр булып чыга.

– Ә аларның кайсылары даими монда яши? (Сорау махсус әзерләнгән – «дачниклар»ның никадәр булуын исәпләп чыгарыр өчен).

– Алар да җидәү. Бездә килде-китте кеше юк, – дип мут елмая бабабыз.

Алга таба хуҗалыкта беренче ярты ел дәвамында җитештерелгән продукция турында сүз китә, шулай ук бу продукциянең кая китүенә дә кагылалар (үзләрен тәэмин итү өчен җитештерәләрме, бу продукция хуҗалыкның төп табыш чыганагымы, әллә өстәмә чыганакмы). Терлек һәм кош-корт исәбен дә җентекләп белешә исәпкә алучыбыз: «бер баш сыер, бер башмак тана, ике баш яшь бозау». Аннары бакча нигъмәтләрен исәплиләр: утыртылган агачларны – чикләвек, цитруслар, йөзем, шулай ук күпьеллык культураларны һ.б. Инфраструктура да тикшерелми калмый: газ, электр һәм су белән

PRESSA.RU

тәэмин ителү, телефон челтәре, йортка асфальт яки башка каты өслекле юл сузылганмы-юкмы, техника һәм җиһазларның исәбе. Березка, беренче чиратта, эшчеләр бистәсе, шуңа да җир өлешләре һәм пайлар турында сораштырып тору кирәкми.

– Бассейн бар тагын, аны да теркәгез, – ди бабакай. – «Ока» дип аталган йөк машинабызны да.

Хуҗаларга рәхмәт белдереп, икенче йортка юнәләбез. Күршедәгесенә түгел, ә бераз арырак китеп.

– Гадәттә, мин кешеләргә уңайлы вакытны сайлап йөрим. Кемнең кайчан өйдә булганын беләм бит, шуңа да кайсына – көндез керәм, кайсына – кичке якта. Менә бу кешеләр, дачниклар булсалар да, биредә җәй буе яшиләр. Алар хәзер өйдә булырга тиешләр, – ди исәпкә алучыбыз. – Шәһәрнекеләр булсалар да, хуҗалыкны бик яхшы, пөхтә тоталар. Әйтергә онытып торам, ялларда без күбрәк йөрибез, чөнки дачниклар нәкъ менә ялларда монда булалар.

Исәпкә алуда «дачниклар» шулай ук ШЯХ буларак теркәлә. Нигездә, яшь кешеләр, ди Миләүшә Рафисовна, һәм нәкъ менә алар исәпкә алуның мәгънәсе турында күбрәк төпченәләр, дип тә өсти.

Әмма кергән йортта безне яшьләр түгел, ә пенсия яшендәге пар каршылый. Аларга бу йорт һәм җир кишәрлеге әбиләре үлгәннән соң мираска калган. Авыл хуҗалыгы продукциясен бары тик үзләрен тәэмин итәр өчен генә җитештерәләр. Дөресрәге – «үзебезгә һәм балаларга, үзара бүлешәбез инде», дип аңлата безгә ШЯХ башлыгы. Терлекләре юк, хәер, дачникларда алар гадәттә булмый да.

Мин бер нәрсәгә игътибар итәм: респондентлар сорауларга шактый җитез һәм ышанычлы җавап бирә, әйтерсең, аларны әзерләп куйганнар. Күрәсең, исәпкә алуга кадәр бер атна алдан исәпкә алучылар юкка гына йөрмәгән – ул чакта алар халыкка нинди сораулар булачагын да сөйләгәннәр, хуҗалар өйдә туры килмәсә, барысын да аңлатып бирә торган хатлар калдырганнар.

Иң соңыннан авыл җирлеге башлыгы Эльвира Әхмәдуллина хуҗалыгына керәбез. Монда инде барысы да җитди, чөнки Эльвира Шәйхулловна зур партияләр белән сөт, ит һәм бал сата. Тракторлары бар, сөт сава торган аппарат, он иләү җиһазы. Әле кичә генә туган бозауны фотога төшереп алабыз. Рәиснең алмагачлары да искитмәле – алмалы ел булмаса да, шау алма биреп утыралар.

БУЫННАР АЛЫШЫНА ҺӘМ АЛМАШЫНА

Гомумән алганда, ди безгә Эльвира Әхмәдуллина, Березкада халык начар яшәми, чөн-

Җирлек башлыгы хуҗалыгында бар да җитди.

Рәиснең алмагачлары да искитмәле – алмалы ел булмаса да, шау алма биреп утыралар.

Авыл хуҗалыгы исәпкә алуы – саннарда һәм фактларда

– Татарстанда исәпкә алу халыкның яртысына диярлек кагылачак. **1030** исәпкә алучы **483** объектны исәпкә алачак.

– Исәпкә алу өчен акчаны федераль бюджет бүлеп бирә (Татарстан **38 миллионга якын** сумма алды). Бу акчаның төп өлеше исәпкә алучы хезмәткәрләргә түләнәчәк.



Песиләр исәпкә алуда катнашмыйлар. Шулай да без берсенә тап булдык.

– Гомумән алганда, Березкада халык начар яшәми.

ки халык тормышны алып барырга тырыша. Биредә, чынлап та, ташландык хәлгә килгән, сатылырга куелган иске йортлар юк диярлек, караусыз ята торган җирләрне дә күрмәдек. Соңгы елларның тенденциясе буларак әйтеп күрсәткәч, бәрәңгене зур-зур бакчалар итеп утыртмауларын ул бер-бер артлы килгән коры елларның тәэсире белән аңлатты.

Аида Евдокимовна тагын шуны да өстәде – нигездә, исәпкә алу шәхси ярдәмче хуҗалыкларда хезмәткәрләр буынының кулланучылар буыны белән алмашынуы турында сигнал бирә:

– 2006 елгы исәпкә алу белән 2016 елгысы арасында аерма гаять зур. 2006 елларда әле авыл хуҗалыгы шактый җитди үсә иде, ә хәзер, үзегез беләсез, никадәр җир эшкәртелми, йә булмаса чәчәк түтәлләре, үлән чәчү һәм агачлар утырту өчен генә кулланыла. Яшьләрнең бит мантыйгы шундыйрак: помидор-кыяр ише нәрсәне үстереп азапланганчы, аларны сатып алу җиңелрәк. Артык күп тир түгеп торасылары килми…

Репортажыбыз башта ук ШЯХны йөреп чыгу белән генә чикләнгән иде, ә аларга сораулырыбыз артык күп түгел безнең, ди Евдокимова (юкса миңа алай тоелмады, җитәрлек шикелле: һәр сораштыру 20-25 минуттан да ким түгел). Авыл хуҗалыгы оешмалары – икенче мәсьәлә, аларның тутыра торган исәпкә алу кәгазьләре 20 биттән дә артып китә. Биектау районында андыйлар – алтау. Монда инде сораштыру – энәсеннән җебенәчә: җирләр, кадрлар, чәчүлекләр, складлар, продукцияне сату, минераль ашламалар һ.б. Авыл хуҗалыгы оешмалары исәпкә алу буенча әзерләнгән кәгазьләрне мөстәкыйль тутыра, аларга алдан ук ничек тутырырга кирәклеген күрсәтәләр. Моның өчен Аида Марселевна берьюлы өч кешене чакырган – бухгалтерны, агрономны һәм зоотехникны.

…«Татарстан» журналы хәбәрчеләре фикеренчә, авыл хуҗалыгы исәпкә алуы, гомумән алганда, кирәкле эш, хәтта файдалы да. Монысы аңлашыла. Безнең өчен бер генә нәрсә сер булып калды – ШЯХ өчен әзерләнгән анкета битләрендә көмешкә кудыру аппаратларының һәм алар ярдәмендә җитештерелә торган продукциянең теркәлмәве. Авыл хуҗалыгында моның белән шөгыльләнгәннәрен белеп торабыз, Россия законнары да бу эшне тыймый. Әлбәттә, ул сату өчен махсус әзерләнмәсә. Әмма, үзара сөйләшеп, шундый фикергә килдек: бу мәсьәләне кузгатсалар, исәпкә алуны уздыра да алмаслар иде. Бу бит – халыкка ышанмау дигән сүз.

– Авыл хуҗалыгы оешмалары һәм ШЯХлардан кала, исәпкә алу крестьян (фермер) хуҗалыкларын, шәхси эшмәкәрләрне һәм бакча ширкәтләрен дә читләтеп үтмәячәк (соңгыларының – кайберләре генә көздә тотыла).

– Исәпкә алуның беренчел нәтиҗәләре **2016 ел** ахырында билгеле булачак. Тулаем, ахыргы нәтиҗәләрен исә, РФ субъектларының барысын да исәпкә алып, **2017 елның** ахырында гына игълан итәчәкләр. Бу инде – җентекләп тикшерелгән, анализланган мәгълүматлар булачак.

PRESSA.RU

ИГОРЬ ПРИВАЛОВ: «КЫЗГАНЫЧ, «ЧИНОВНИК» СҮЗЕ СОҢГЫ ВАКЫТТА СҮГЕНҮ СҮЗЕНӘ ӘЙЛӘНДЕ»

«Әгәр камилләшә бармыйсың икән, сине сызгыртып узып китәчәкләр», – дип раслый Игорь Привалов – КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры. Безнең әңгәмәбез кызыклы килеп чыкты – дәүләт идарәсе аппаратының хәзерге системасындагы мифлар, проблемалар һәм кискен көндәшлек турында ул.

Катерина Котова
әзерләде

– Игорь Анатольевич, халыкта, чиновник ул – бик тук, тормыштан канәгать һәм һәрьяктан яклаган кеше, дигән фикер яши. Бу ялганмы?

– Ялган һәм бик куркыныч фикер. Әле район хакимияте башлыгы вазыйфасында чагымда ук, муниципаль хезмәткә урнашу турында хыялланган кайбер кешеләр миңа туктаусыз шалтыратып үзәгемә үтәләр иде. Әмма алар белән танышып сөйләшкәннән соң, мин бу кешеләрне мондый хезмәткә якын да җибәрергә ярамаганын аңлый идем! Алар безнең эшнең нәрсәдән гыйбарәт булуыннан бөтенләй хәбәрдар түгел бит. Теге, мәгълүм мәзәктәге кебек: «Әле монда акча да түлиләрмени?!» Жванецкий андыйлар турында болай сөйли иде: «Чиновниктан имза кую хокукын алганда, ул бөтенләй файдасызга әйләнә». Шул ук вакытта Николай Гогольнең Акакий Акакиевич образы да – тыйнак кечкенә дәүләт кешесе – ерак үткәндә калды. Бүген мондыйларның дәүләт хезмәтендә кала алуы икеле.

Безнең республикабызда Президент һәм аның командасы шулкадәр нәтиҗәле эшли ки, урыннарда да йоклап кына йөри алмассың. Татарстандагы югары үсеш темпларыннан артка калмас өчен, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең беренчел звеносыннан башлап югары вазыйфаи затларга кадәр һәркемгә үзен даими тонуста тоту зарур. Урыннарда табигый сайланыш бара. Әгәр син көн саен камиллегеңне арттырмыйсың икән, һәрвакыт ниндидер этапта сине узып китәрләр, дигән куркыныч бар. Җитмәсә әле, сызгыртып узачаклар. Кадрлар, элеккечә үк, барысын да хәл итә. Бүген бу постулат бигрәк тә мөһим.

– Әмма, ихтимал, хәтта дәүләт хезмәте системасында да барысы да идеаль түгелдер. Сез аның үсешенә аяк чалучы төп проблеманы атый аласызмы?

– Минемчә, ул күренеп тора – эш күп, җаваплылык – зур, ә хезмәт хакы тиешле дәрәҗәдә түгел. Җаваплылыкның гаять зур булуын тагын бер кат ассызыкларга кирәктер, чөнки бүген дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр үз гамәлләрендә бик чикләнгән. Һәм коррупциягә каршы торуга бәйле мәсьәләләрдә генә дә түгел, ә бәлки үзләренең эштән буш вакыттагы тәртипләрендә дә. Без тикшергән соңгы закон проектларының берсе социаль челтәрләрдән файдалану, төгәлрәге, анда шәхси мәгълүматлар бастыруга бәйле. Әйе, шуңа килеп җиттек. Тагын бирегә нормасы билгеләнмәгән эш көнен, еш кына ял көннәренең дә булмавын өстәгез... Боларның барысы да әкренләп яхшы квалификацияле һәм югары IQ дәрәҗәле кешене уйландыра башлый – мондый эш аңа нәрсәгә кирәк соң әле? Нәтиҗәдә ул үз белеме һәм күнекмәләре лаеклы бәяләнә торган эшкә китә. Асылда, акыллы хезмәткәрләрдән колак кагабыз.

– Мондый хезмәткәрләрне ничек саклап калырга соң?

– Эш хакын арттырырга кирәклеге турында гына сөйләү, минемчә, дөрес түгел. Күрәсең, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне популярлаштыру да кирәктер. Телевизорны кабызыгыз әле. Нәрсә күрәбез? Безгә полициянең җинаятьчеләрне тотуын, ә «начар егетләрнең» – дәүләт хезмәткәрләренең моңа каршылык күрсәтүен, шулай ук бизнес тәгәрмәченә таяк тыгуларын күрсәтәләр. Шунлыктан бүген «чиновник» сүзенең сүгенү сүзенә әйләнә язуына бер дә гаҗәпләнерлек түгел. Һәм бу көенечле дә, чөнки чынбарлыкта дәүләт хезмәткәрләренең күпчелеге – үз эшләренә бирелгән, тырыш кешеләр. Аларның күбесе үзләрен башка миссиядә күз алдына да китерә алмый.

Араларында тулы бер династияләр дә бар.

– Сез күптән түгел Кытайда булып кайттыгыз, ул исә үзенең нәтиҗәле идарә системасы белән дә данлыклы. Без алардан нәрсәгә өйрәнә алабыз?

– Кытай шактый ябык ил. Анда чын дөресен сөйләп бетермиләр. Безне кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү методикалары һәм дәрәҗәсе кызыксындырды – кытайлар моңа зур игътибар бирә. Мисал өчен: дәүләт хезмәтенә яңа алынган хезмәткәр мәҗбүри рәвештә база программасы буенча укырга җибәрелә. Ул теоретик өлештән һәм практик, бәхәсле мәсьәләләр тикшерелә торган тренинглардан гыйбарәт. Уку ай ярым, иртәдән кичкә кадәр бара. Без сорау бирдек, ә эш нишли? Шимбә белән якшәмбе бар бит эшләргә, дип җавапладылар. Ахыр чиктә, төннәр бар! Ягъни, барысы да шактый кырыс. Ел дәвамында дәүләт хезмәткәренең горизонталь яки вертикаль һәр күчеше мәҗбүри уку, квалификацияне күтәрү белән бара. Коррупциягә каршы программаларга бик күп игътибар бирелә. Кытайда дәүләт хезмәткәрләренең барысы да елына бер тапкыр кабат укытыла. Һәм бу әле андагы халык санын исәпкә алып! Без дә бу юнәлештә хәрәкәт итәбез. «РФ дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законга ярашлы рәвештә, безнең республикадагы һәрбер дәүләт хезмәткәре өч елга бер тапкыр квалификация күтәрү курсларын үтәргә тиеш. Ешрак та ярый – аны бу мәсьәләдә беркем дә чикләми. Соңгы яртыеллыкта гына да без 2,7 меңнән артык кешене укыттык. Башка субъектлар белән чагыштырганда, бу бик күп. Шул ук перспективалы Калуга өлкәсендә елына нибары 250 кеше укыла.

– Ә сез безнең идарәчеләрнең дәрәҗәсен ничек бәялисез? Аны да күтәрергә кирәкме?

– Дәрәҗә югары. Безгә Мәскәү тирәсеннән һәм илнең башка төбәкләреннән коллегаларыбыз еш килә – барысын да дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрне әзерләү һәм аларның кабат белемен күтәрү программалары кызыксындыра. Барысы да Татарстанның динамик үсештәге төбәк булуын күрә бит. Сүз уңаеннан, монда безнең мәктәпнең дә казанышы бар. Чөнки әллә нинди заманча җитештерүләр төзеп куеп була, әмма урыннардагы кешеләр аларда эшли белмәсә, бернәрсә дә килеп чыкмаячак. Тикмәгә генә Президент үзенең чыгышларында, безгә кадрлар составын әзерләү һәм кабат укыту белән соңарырга ярамый, дип кисәтми бит. Алайса кешеләр, республика икътисады артыннан өлгермичә, әйләнә-тирәдәге вазгыятьне аңламый башлаячак. Безгә нәтиҗәле идарәчеләр кирәк. Алар булсын өчен, кадрларны даими камилләштерү зарур. Ә бу исә инде – безнең бурыч. Безнең даими тыңлаучыларыбыз арасында – башкарма комитет җитәкчеләре, Президент Аппараты, Министрлар Кабинеты, ТР Дәүләт Советы хезмәткәрләре.

– Сезнең мәктәп аларның квалификациясе үсүгә ни рәвешле булыша ала?

– Иң әүвәл – җитәкчеләр өчен тренинглар. Аларга бүген ихтыяҗ аеруча зур. Бигрәк тә «Сөйләшүләр алып бару сәнгате», «Башкару белән идарә итү», «Хакимияткә таянмыйча идарә итү», «Файдалы киңәшмә», «Халык каршында чыгыш ясау осталыгы» кебекләр. Быел беренче яртыеллыкта гына да безнең тренингларда министр урынбасарлары, республика дәүләт комитетлары һәм ведомстволары җитәкчеләре дәрәҗәсендәге 120дән артык белгеч катнашты. «Эшчәнлек нәтиҗәлелеге. Аны күтәрү күрсәткечләре һәм ысуллары» программасына ихтыяҗ зур. Быел инде 300 кешене укыттык. «Эшлекле хат» курсының зур кызыксыну уятуы безнең өчен көтелмәгән хәл булды. Ел азагына кадәр аны 700 белгеч өйрәнеп чыгачак. Безнең әле махсус программаларыбыз да бар. Мәсәлән, министрлык һәм муниципаль берәмлекләр юридик хезмәтләре җитәкчеләрен квартал саен укыту. Педагоглар арасында – Юстиция министрлыгы, прокуратура белгечләре, судьялар. Документлар әзерләгәндә, суд утырышларында безнең тыңлаучыларыбызга очрарга мөмкин булган нечкәлекләр тикшерелә. Хәзер «Финансист булмаганнар өчен финанслар» дигән яңа программа әзерлибез. Моннан тыш, без инде хәзер үк алга китеп эшләргә тырышабыз – мин үзебезнең Кадрлар резервыннан ел саен чыгарылучы «мәҗбүри егермелекне» күз алдында тотам, алар Татарстан җитәкчелеге составы потенциалы булып тора. Быел безгә ике йөз иллеләп яшь кеше гариза бирде, шулардан

PRESSA.RU

“ – Без парта артына утыртмыйбыз да – кызык түгел ич. Соңгы ел ярымда укыту методикаларын да, программаларыбызның системасын да шактый үзгәрттек.

иллесен сайлап алдык. Безнең мәктәптә квалификацияләрен күтәрү башка «резервчылар» фонында аларның көндәшлеккә сәләтлелеген арттырачак.

– Өлкән кешеләргә кабат парта артына утырырга туры килә. Каршы килмиләрме?

– Без парта артына утыртмыйбыз да – кызык түгел ич. Соңгы ел ярымда укыту методикаларын да, программаларыбызның системасын да шактый үзгәрттек. Стандарт лекцияләрне тренинг һәм кейсларга алыштырдык. Материалны бары уен формасында гына бирәбез. Мәсәлән, абстракт районнарда конкрет хәлләр һәм проектлар моделе тәкъдим ителә. Без җанлы диалогны хуплыйбыз, һәр тыңлаучыбыз башын эшләтсен өчен тырышабыз! Нәтиҗәдә бик уңай җавап реакциясе алабыз, һәм бу безнең дөрес юл белән баруыбызга ышаныч өсти. Күптән түгел без дөньяның әйдәп баручы югары уку йортлары тәҗрибәсен файдалана башладык. Алар үзләренең бизнес-программаларын практика белән шыплап тутырырга тырыша, ә теоретик әзерлекнең төп күләмен дистантка калдыра. Аны тыңлаучыга сессиягә чакыру белән бергә җибәрәләр. Әгәр ул дистантны укымый икән, тестларны эшләп чыга алмаячак. Ул вакытта исә – хушыгыз! Киләсе елга кадәр. Безнең очракта бу дәүләтчелек нигезләренә, өлешчә закон чыгару базасына һәм коррупциягә каршы көрәшкә кагылачактыр, мөгаен. Болар – бөтен дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр мәҗбүри белергә тиешле нәрсәләр.

– Россиядә, судьялар ришвәт алмасын өчен, аларның эш хакын бик югары күтәрәләр. Кытайда исә – аталар, әле бөтен халык алдында. Сезнеңчә, кайсысы нәтиҗәлерәк?

– Шундый һәрбер очракны халыкка җиткерү, тикшерү нәтиҗәлерәк. Бу – өченче юл. Германия полициясендә коррупция белән шулайрак көрәшәләр. Немец тәртип сакчысына ришвәт бирергә уйламагыз да! Сәбәбе гади – югары хезмәт хакы һәм зур соцпакет, анда хәтта коммуналь чыгымнарны һәм балаларны укыту чыгымнарын да түләү керә. Әгәр немец полицейские ришвәт алганда тотыла икән, бөтен нәрсәсен югалта. Хәтта пенсиясен дә! Аның ничек яшәячәге һәм гаиләсен асраячагы инде беркемне дә хафаландырмый. Әлбәттә, мондый юл белән бару өчен, мин алдарак билгеләгән проблемаларны хәл итү зарур – дәүләт һәм муниципаль хезмәтнең абруен күтәрү. Без эшли торган абруйлы юнәлеш – нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрне тәрбияләүгә булышу.

– Ә бу юнәлештә тулаем республикаданиләр эшләнә?

– Көн тәртибендә – персоналны нәтиҗәлелек критерийлары буенча бәяләүне керту. Әлбәттә инде, эш хакын дифференциацияләү максатыннан. Система инде министрлыкларда апробация үтә. Чиратта – муниципалитетлар. Мондый бәя ай

– Россия – кадрларны әзерләү һәм кабат укытуны дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең үз акчасына түгел, бәлки бюджет хисабына башкара торган бик аз илләрнең берсе.

саен биреләчәк һәм, бер яктан, җитештерүчәнлекне арттырырга, икенче яктан – бөтен кешене тигезләүдән китеп, хезмәткә түләүнең мантыйкка ярашлырак системасына күчәргә мөмкинлек бирәчәк, дип фаразлана. Бу очракта дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү, аларның өстәмә белем алу мәсьәләләре дә исәпкә алыначак. Мин күптән түгел Мәскәү Хөкүмәтенең Мәскәү идарә университетында кадрлар әзерләүгә багышланган конференциядә булдым. Анда Көньяк Кореядән килгән профессор чыгыш ясады. Алар дәүләт хезмәткәрләре өчен мобиль программа эшләгән, һәм хәзер алар үз квалификацияләрен бөтен җирдә – ял иткәндә, транспортта, урамда йөргәндә дә күтәрә ала. Йомгаклау тестын да телефон аша үтәләр. Эш хакы тупланган баллар санына бәйле. Залдагы бер ханым Россия өчен аңлаешлы сорау бирде: «Сез үз дәүләт хезмәткәрләрегезне ничек укырга мәҗбүр итәсез?» Әмма Корея профессоры сорауны аңламады. Аның өчен барысы да аңлаешлы: эш хакыңны арттырасың килсә – квалификацияңне күтәр! Һәм менә монда мин төгәллек кертим: Россия – кадрларны әзерләү һәм кабат укытуны дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең үз акчасына түгел, бәлки бюджет хисабына башкара торган бик аз илләрнең берсе.

PRESSA.RU



МОДЕРНИЗАЦИЯЛӘҮ ПРОЕКТТАН БАШЛАНА

«Казан Гипронииавиапромы» – Россиядәге иң абруйлы проект-конструкторлык институтларының берсе. Аның хезмәт юлы тел-теш тидерерлек түгел – биредә уйлап табылган уникаль яңалыклар илебезнең авиация сәнәгате үсеше өчен чын мәгънәсендә катализатор ролен үти. Коллективның югары һөнәри осталыгы теләсә кайсы катлаулылыктагы бурычларны башкару мөмкинлеге бирә.

Быел «Казан Гипронииавиапромы» акционерлык җәмгыяте җитмеш биш еллыгын билгели. Бөек Ватан сугышы башланган вакытта нигез салынган институт уникаль оборона предприятиеләре булдыруда катнаша, җиңүгә саллы өлешен кертә. Соңрак, тыныч тормышта, коллективның проект һәм конструкторлык өлкәсендәге ачышлары СССРның авиация тармагы үсешен тәэмин итә, аны яңа баскычларга күтәрә. Илнең базар шартларына күчүе җитди сынау була, әмма «Казан Гипронииавиапромы»ның чын профессионаллардан торган командасы тиз арада үзенең базар икътисады шартларында да нәтиҗәле эшләргә сәләтле булуын исбатлады. Югары квалификацияле проектчылар коллективы кыска вакыт эчендә үзе өчен эшчәнлекнең яңа юнәлешләрен үзләштерде.

Аэропортларны, федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын, төзелеш индустриясе объектларын, заманча торак йортларны, сәнәгатьнең төрле тармакларына караган предприятиеләрне, хәвефле җитештерүләрне, магистраль торбаүткәргечләрне, тарихи һәм мәдәни ядкарьләр объектларын проектлау… – «Казан Гипронииавиапромы» акционерлык җәмгыяте өчен мөмкин булмаган эш юк. Бүген бу киң профильле институт, ул бай традицияләргә һәм уникаль эш тәҗрибәсенә таяна, иң катлаулы инженерлык бурычларын хәл итәргә сәләтле. «Казан Гипронииавиапромы» акционерлык җәмгыятенең үзе өчен гадәти булган авиация сәнәгате предприятиеләрен яңарту проектларыннан тыш, «Радиоэлектрон технологияләр концерны» акционерлык җәмгыяте составына керүче предприятиеләрне техник яктан үзгәртеп кору өчен проектлар һәм эш документларын әзерләвен әйтү дә җитә.

Казан фирмасының илебез сәнәгатенең куәтлелеген һәм оборонага сәләтлелеген ныгытуга керткән өлешенең ни дәрәҗәдә саллы булуы турында коллективның соңгы ел ярым эчендә башкарган төп проектлары буенча сүз алып барырга мөмкин. Аерым алганда, «Казан Гипронииавиапромы» АҖ Ульяновск шәһәренең «Утес» ачык акционерлык җәмгыяте цехларын реконструкцияләү өчен проект һәм эш документларын әзерләгән. Җитештерүне төптән яңарту биредә «Җитештерүне БИНС, Ми-28НМ комплекслары өчен югары тизлекле параметрларны, акселерометрларны тикшерү һәм исәпләп чыгару җиһазлары, мәгълүматны чагылдыру җайланмалары белән тәэмин итү буенча» максатчан федераль программага ярашлы, платформасыз инерцияле навигация системасын (БИНС) эшләп чыгаруны үзләштерү мөмкинлеге бирәчәк.

Шунысы игътибарга лаек: Казан белгечләре «Утес» ААҖен техник яктан үзгәртеп кору буенча әзерләгән проектны тормышка ашырганда, кирәкле җиһазлар, детальләр

һәм төеннәрне югары сыйфатлы итеп җитештерү көйләнеп кенә калмый, аның үзкыйммәтен киметү дә тәэмин ителәчәк. Асылда, технологик яктан җиһазландыру дәрәҗәсе буенча инерцияле системалар җитештерүчеләрнең дөньякүләм лидерларыннан калышмый торган җитештерүгә нигез салына. Бирегә төп технологик процесслар металл эшкәртү өлкәсендәге иң яңа казанышларны куллану исәбенә автоматлаштырыла. Нәтиҗәдә – җитештерүчәнлек үсә, хезмәт көчен куллану кими, БИНС комплектларын җитештерүнең барлык этапларында да технологик калдыклар күзгә күренеп кыскара һәм продукциянең сыйфаты арта. Аның көндәшлеккә сәләтлелеге үсә, сату базары киңәя.

«Гипронииавиапром» тарафыннан Казанның «Радиоприбор» ААҖнең җитештерү-технологик һәм сынау базасын техник яктан үзгәртеп кору өчен әзерләнгән проектны тормышка ашыру барышында да революцион үзгәрешләр көтелә. Бирегә дәүләт тану системасының яңа буын радиоэлектрон аппаратурасын серияләп җитештерүне оештыру өчен бөтен шартлар да тудырылачак, шулай ук бүгенге көндә үзебездә эшләнә торган авиация техникасына урнаштырылачак якынара навигация һәм утырту системасының бортка урнаштырыла торган яңартылган аппаратурасы да эшләнәчәк.

Механик эшкәртүче җитештерү проектында каралган үзгәрешләрне тормышка ашырганда, СПИле заманча югары токлы җиһазларда өч үлчәмле катлаулы өслекләрдә югары токлы детальләр эшләүнең төп сәнәгать технологияләре үзләштереләчәк. Бу эшләнмәләрнең кабатлануын тәэмин итәчәк, кеше факторын минимальләштерәчәк, шулай ук төп эшләнмәләрне җитештерүгә кергән хезмәт күләмен 6-7 процентка кыскарту мөмкинлеге дә бирәчәк. Шул рәвешле, җыю цехларына тагын да югары сыйфатлы детальләр киләчәк.

Яңа технологияләр «Ульяновск җиһазлар эшләү конструкторлык бюросы» ААҖнең стендлы базасын техник яктан үзгәртеп кору барышында да кулланыла. «Гипронииавиапром» проекты, мәсәлән, металл эшләнмәләре өчен бүгенге көндә иң алдынгы саналучы аддитив җитештерү технологиясен үзләштерүне күздә тота, бу исә массаны, габаритларны, энергия сарыф ителүне киметү, һава басымын кабул итү җиһазларының мөмкинлекләрен киңәйтеп, төгәллеген арттыру, аларны дөньядагы иң яхшы үрнәкләр дәрәҗәсенә күтәрү мөмкинлеге бирәчәк. Оператив рәвештә 3D CAD модельләреннән эшләнмәләрнең прототипларын гадәти металл эшкәртү җиһазларын кулланмый гына эшләп чыгару планлаштырыла, бу яңа эшләп чыгарыла торган очу аппаратларын бәяләү өчен кирәк.

ВК-2500 гаиләсеннән заманча вертолет двигательләренең компонентларын җитештерүне оештыру өчен ресурслар базасы һәм технологик платформалар булдыру «Гипронииавиапром»ның Уфада «УМПО» гавами акционерлык җәмгыятенең 75 нче корпусын техник яктан үзгәртеп кору һәм реконструкцияләү буенча проект эшләрен гамәлгә ашыруда йомгак булачак. Җитештерү куәтләрен бергә туплау, сакчыл җитештерү принципларын куллану эшкәртелүче детальләрне операцияләр арасында күчереп йөртүгә китә торган вакытны шактый кыскартырга, эчке логистиканы оптималь рәвештә корырга, җитештерү мәйданнарын киметергә мөмкинлек бирә. Заманча кисүче корал, аны көйләү чаралары һәм актив контроль системалары белән җиһазландырылган локаль җитештерү челтәренә үткәрелгән СПИле югары җитештерүчәнлеккә сәләтле заманча җиһазлар куллану эшләнә торган детальләрне һәм җыелучы берәмлекләрне эшләп чыгару вакытын шактый кыскарту һәм аның югары сыйфатын тәэмин итү мөмкинлеге бирде.

Роман Рудых,
техник директор урынбасары – проектның баш инженеры

Цехтагы барлык җитештерү һәм логистик операцияләр «төгәл вакытында» принцибы буенча синхронлаштырылган. Җиһаз алдагы операция өчен кирәклесен генә җитештереп бирә. Кулланыла торган җиһазларның типлары һәм аларның урнашу схемалары сыгылмалы үзгәртеп көйләнә торган җитештерү принципларына һәм таләпләренә җавап бирә, бу иң кыска вакыт эчендә ресурсларны минималь дәрәҗәдә кулланып, перспективадагы вертолет двигательләренең яңа компонентларын чыгаруга көчү мөмкинлеге бирә.

«Гипронииавиапром» АҖ эшләп, гамәлгә куйган масштаблы проектларның берничәсе генә әле болар. Һәр шундый проект – уникаль. Аларны бер сыйфат берләштерә: югары һөнәри дәрәҗәдә башкарылган булулары белән алар максималь дәрәҗәдә икътисадый табыш вәгъдә итә. Данлыклы коллективның проект һәм конструкторлык ачышлары иң гадел хөкемдар – вакыт тарафыннан сынала.

«Радиоприбор» ААҖ һавада урнашу дәүләт тану системаларын модернизацияләү, җитештерүне реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан коралландыру, Казан шәһәре.

Реклама

Реклама

«ТЕЛЕВИДЕНИЕ ФТИ»НЫҢ КОСМИК СИСТЕМАЛАРЫ

«Телевидение ФТИ» АҖ – оборона-сәнәгать комплексының күпьюнәлешле предприятиесе, ул телевизион һәм оптик-электрон техниканың, югары үлчәмле оптрониканың иң әһәмиятле тармаклары буенча уникаль фәнни-техник продукция эшләү белән шөгыльләнә.

Санлы телевизион техника эшләүгә зур игътибар бирелә: санлы ысуллар белән телевизион мәгълүматны эшкәртүнең программаларын булдыруга; космик тикшеренүләргә, авиация, шулай ук мәгълүматларны кабул итүнең радиотехник чараларына, теле-, радиоэфирга чыгу белән бәйле башка юнәлешләргә.

«Телевидение ФТИ» АҖ эшләп чыгара:

- КАның тоташуын контрольдә тоту өчен билгеләнгән автоном видеокүзәтү системалары;
- Халыкара космик станциянең Россия сегменты өчен «Орлан-МКС» скафандры сигналын бирү җайланмасы;
- радиациягә бирешмәүчән, күз күреме диапазонында югары үлчәмле КМОП СБИС фото кабул итү җайланмалары һәм радиациягә бирешмәүчән объективлар;
- КМОП фото кабул итү җайланмаларындагы космик билгеләнешле радиациягә бирешмәүчән телевизион камералар (сизгерлеге югары булган йолдызлы датчиклар, тоташтыру системалары, сизгерлеге һәм үлчәме югары булган космик пространствоны күзәтү системалары);
- бортта урнашкан һәм җирдәге комплекслар өчен кабул итү-тапшыру җайланмалары;
- РС МКС, ТПК «СОЮЗ МС», ТГК «ПРОГРЕСС МС»ның күзәтү зонасындагы санлы югары ешлыклы сигналны тотрыклы рәвештә кабул итеп тапшыру өчен җир өстендәге бәләкәй габаритлы комплекслар;
- космик метрология мәгълүматларын кабул итү буенча КАдан килгән гидрометеорологик һәм геофизик максатлы мәгълүматны оператив рәвештә кабул итеп, тематик яктан эшкәртеп һәм анализлап бара торган мобиль автоном пунктлар;
- DVB/DVB-T2 стандарты буенча санлы телевизион эфирның күпфункцияле автоном кабул итү-тапшыру станцияләре (алар зур булмаган торак пунктларда эре телерадиоузәкләрнең сигналы түбән дәрәҗәдә булганда кулланыла);
- катлаулы территориаль-бүлгәләү системалары белән идарә итү һәм мониторинг алып бару өчен аппарат-программа комплекслары: фәнни тикшеренүләрнең иң соңгы нәтиҗәсе – «Восточный» космодромында телевизион инфраструктура объектлары белән идарә итү үзәге.

«Телевидение ФТИ» АҖнең телевизион техника юнәлешендәге заказчылары һәм партнерлары булып: «Энергия» РКК, «КБточмаш им. А. Э. Нудельмана» АҖ, «НИИ химмаш» АҖ, «Арсенал» КБ, «ЦНИИмаш» унитар предприятиесе тора.

«Телевидение Фәнни-тикшеренү институты» АҖ • Адрес: 194021, Санкт-Петербург, Политехническая урамы, 22 йорт • Сайт: www.niitv.ru

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

«ГОЛЛАНДИЯ ЧИРЕ»ННӘН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?

Татарстанда композит материаллардан продукция җитештереп, аны куллану кластеры барлыкка килергә мөмкин, һәм ул барлыкка килергә тиеш тә, дип саный «Пыяла-пластик торбалар заводы» фәнни-җитештерү предприятиесе ҖЧҖнең генераль директоры Сергей Волков. «Татарстан»га биргән интервьюсында БДБ илләре территориясендә пыяла-пластик торбалар җитештерү буенча иң алдынгы предприятиенең җитәкчесе ни өчен моның мантыйкка ярашлы һәм бик табигый булуын аңлата.

– Сергей Алексеевич, бүгенге икътисадый шартларда сезнең предприятие ни хәлләрдә?

– Дөресен әйткәндә, хәзер безгә җиңел түгел. Бездә инновацияле продукция бит, ә кризис вакытында беренче булып нәкъ менә инновацияләр төшеп кала. Ягъни икътисад үсештә булганда – кешеләр перспективага, үсешкә йөз тота, акчасын, көчен кызганмый, ә кыен вакытта көчләр күбрәк вазгыятьне контрольдә тотуга сарыф ителә, һәм планлаштыруда да офыклар тарая.

Бездә ничегрәк чагыла бу? Безнең торбалар коррозиягә бирешмәүчән булуы белән аерылып тора. Ягъни, әйтик, яссы торбалар буенча мондый принцип: күмеп куйдың да оныттың; аның хезмәт итү вакыты чыганаклар гомереннән дә азрак түгел. ТКХда да шул ук принцип. Торба микрорайон күпме яшәсә, шуның кадәр хезмәт итә. Бернинди өстәмә хезмәт күрсәтүләрсез. Ләкин икътисадыйкүзлектән шик-шөбһәләр була икән, безнең кулланучылар болайрак фикер йөртә башлый: бүген барысы да яхшы бит әле, алга таба нәрсә буласы алай ук мөһим түгел.

– Ләкин бу вакытлыча гына күренеш бит? Сәнәгатьтә композит материалларның өлеше барыбер үсәчәк?

– Һичшиксез. Бу шуның белән бәйле: бүген композит материаллар турыдан-туры көндәшлеккә сәләтлелекне билгели. Беренчедән, эшләнмәләр турында бара сүз. Әйтик, гадәти материаллардан эшләнгән хәрби самолетлар безнең заман сугышында һичшиксез җиңеләчәк. Ләкин бу әле «оборонка» гына түгел. Композит материаллар гражданнар сәнәгатендә дә көннән-көн киңрәк кулланыла. Кытайда, мәсәлән, троллейбусларны да композитлардан эшлиләр.

Икенчедән, алар предприятиенең көндәшлеккә сәләтлелеген билгели. Шул ук нефтьчеләрне генә алыйк. Мин бөтен интервьюларда әйтә килдем: «Менә күреп торыгыз, майлы акчалар дәвере үтәчәк. Соңга калганчы, акчаларны пыяла, пластикка тотарга кирәк. Бүген пыяла-пластик торбалардан үткәргечләр салсак, нефтькә бәяләр төшкәч, безнең көндәшлеккә сәләтлелек нефть чыгаруның үзкыйммәте белән билгеләнәчәк, безгә ремонтка дигән чыгымнарның булмавы ярдәмгә киләчәк». Бүген исә базарда бер баррель бәясе билгеле бер дәрәҗәгә җитүгә, без аннан китә дә башлыйбыз.

Һәм өченчедән, бу дәүләтнең көндәшлеккә сәләтлелеген күтәрә. Дәүләтнең «фирма», ягъни тәэминатчы, контрагент буларак. Кайчандыр Россия үзенең эчке проблемаларында кайнашып ятып, бишенче технологик катламны күздән ычкындырды – бу чорда үсеш мәгълүматлаштыру белән билгеләнә иде. Бүген безнең бурыч – алтынчы технологик катламны кулдан ычкындырмау. Монда үсешне нәкъ менә алдан уйланылган материаллар, шул исәптән композитлар тәэмин итә.

– Ә безнең чыннан да бу дулкынны иярләрлек шанслар бармы?

– Ким дигәндә, без артта калмаска дип бара алабыз, ә билгеле бер сценарий буенча барсак, алга да чыга алабыз. Моның өчен сәяси ихтыяр булу кирәк.

Татарстанга килгәндә, биредә заманча композит кластеры булдыру өчен яхшы оеткы салынган. Безнең эре кулланучыбыз бар – «Татнефть» (сүз уңаеннан, Россиядә композит насос-компрессор торбаларына моданы ул кертте). Безнең куәтле химия бар. Мисал өчен, республикада бисфенол-А кебек продукт җитештерелә – бу эпоксид сумаласы җитештерү өчен төп компонент. Безнең төп җитештерүче бар – «Алабуга» махсус икътисадый зонасында пыяла-сүс заводы безнең өчен кирәкле сыйфатта пыяла ровинг эшләп чыгара. Инфраструктура бар – шул ук «Алабуга», индустриаль парклар, технопарклар. Ниһаять, төп җитештерүче – безнең пыяла пластик торбалар заводы.

Шулай итеп, җиң сызганып эшләргә генә. Шул ук вакытта безгә фән үсеше дә ярдәмгә киләчәк. Перспективалы юнәлеш бит; нефть торбалары артыннан тикшеренүләрнең тулы бер чылбыры сузылачак – ТКХ, күмер чыгару сәнәгате, оборона-сәнәгать комплексы, төзелеш, мелиорация, көнкүрештә куллану өчен торбалар һәм эшләнмәләр һ.б. Пыяла пластикның шул ягы өстенлекле, ул артык күп капитал чыгармый гына тиз арада җитештерүләр булдыру мөмкинлеге бирә. Бу җитештерүләрнең күбесе кече предприятиеләр кулыннан да килерлек.

– Әлеге продукциягә ихтыяҗны «Татнефть»тән кала, тагын кем дә булса тәэмин итәргә сәләтлеме?

– Әлбәттә, монда да эшлисе бар әле. Ихтыяҗга стимул булдырырга кирәк, бөтен дөньядагы кебек үк кулланучыны булдырырга һәм аны үстерергә кирәк. Салым ташламалары, рискларны иминиятләштерү, башка норматив чаралар аша... Һичшиксез, икътисад алга барсын өчен аңа этәргеч бирергә кирәк. Шулай да Россиядә әлегә «Голландия чире»н дәвалап булмый әле. Без һаман нәрсәдер көтәбез, юкса күптән инде эшкә тотынырга вакыт.

Завод стеклопластиковых труб ЗСТ

Реклама

PRESSA.RU

БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ПЛЯЖ

О, пляж, бу сүзгә күпме мәгънә сыйган... Бигрәк тә төрле сәбәпләр аркасында диңгез буена бара алмаучылар өчен. Бу җәһәттән күпләр Әлмәт халкына ак көнләшү белән кызыгып карый – анда июль аенда Сулыкларны саклау елы кысаларында яңартылган шәһәр пляжы ачылды. Хәер, әлеге территорияне пляж дип атау да кыен – ул күл янәшәсендәге туристик-рекреацион зона, тулы бер шәһәр пространствосы.

БӘЛӘКӘЙ ҺӘМ ТЫЛСЫМЛЫ

Әлмәт шәһәре пляжы Татарстан Президенты указы белән игълан ителгән тематик ел кысаларында яңартып корылган беренче объект булды. Соңгы тапкыр Әлмәт шәһәрендәге күл территориясе моннан 15 ел диярлек элек – 2002 елда төзекләндерелгән булган. Ул буш тормаган – бирегә балалары белән гаиләләр һәм гашыйк парлар ял итәргә килә торган булган. Су коенганнар, кояшта кызынганнар. Дөрес, биредә су коеныр өчен шактый батырлык кирәк булган – күл күршедәге Петуховка авылыннан агып төшкән пычрак суларны да үзенә сыйдырып барган. Шулай да быел март аенда буа бөялде – экологлар, Петуховкага килеп, ихаталарда су базларын карап, аларның санитар-эпидемиологик таләпләргә туры килү-килмәвен тикшереп чыктылар.

– Без Петуховка халкын берничә тапкыр җыеп, кагыйдәләрне бозган кешеләргә төзәлергә дигән күрсәтмә бирдек, аларга күлнең пычрак су түгү өчен чокыр түгеллеген аңлаттык, – дип сөйли «ТР Әлмәт муниципаль районының Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Айнур Исхаков. – Күпчелеге, әлбәттә, эшкә җаваплы карады: 98 су базының 70е тәртипкә китерелде, калганы су базы буларак файдаланылмый. Нәтиҗәдә, күлгә бара торган өч торба томалап куелды, яңгыр сулары ага торган ике канализация сүтелде, суга якын урнашкан бәдрәфләр алдырылды.

Бер генә мәсьәләне хәл итәсе калды – күлнең рөхсәт ителгән концентрация чик-күрсәткеченнән берничә тапкырга артып киткән пычрак суын ничек чистартырга? Фильтр аша үткәрергәмени инде? Экологлар суны чистарту эшен беркүзәнәкле яшел суүсем – хлореллага «тапшырдылар». Теләсә кайсы сулыкка килеп эләккәч, хлореллага анда өстенлекле культурага әйләнү өчен берничә көн җитә. Ул судан артык углекислый газны чыгара, органик һәм органик булмаган матдәләрне чистарта, шул рәвешле суның чәчәк атуын туктата, патогенлы микрофлораны үтерә. Әлеге күзгә күренер-күренмәс кенә суүсем менә нәрсәләргә сәләтле: дүрт көн эчендә аммонийлы азот туплануын – 40, фосфатларны 20 процентка; алты көн эчендә фенолны – 45 процентка, сигезенче көнгә нефть продуктларын 36 процентка киметә. Хлорелла кислород бүлеп чыгара, бу исә, үз чиратында, авыр металл калдыкларыннан арынырга ярдәм итә. Әле болар гына да түгел – хлорелла судагы азык чылбырындагы иң түбән баскыч ролен дә үти: аны зоопланктон ашый, зоопланктон белән балыклар туклана. Тагын шунысы мөһим: аны куллану өчен ремонт яки суны чистарту өчен яңа корылмалар таләп ителми, бары тик үсемлекне суга җибәрү дә җитә.

КИЧӘ

БҮГЕН

БАРЫГЫЗ ДА – КҮЛГӘ!

– Күлне төзекләндерү эшен белгечләрнең зур бер командасы – дизайнерлар, проектчылар, төзүчеләр башкарды. Алар күлне шәһәр халкының ялы өчен уңайлы итү хакына тәүлек әйләнәсенә тырышты. Барлыгы 62 оешма җәлеп ителде, – дип сөйләде бәйрәмгә берничә көн кала журналистларга Әлмәт районы башлыгы Айрат Хәйруллин.

Пляжны ачу тантанасы 13 июльдә булды. Әлмәт бу көнне Беренче Май демонстрациясенә охшаган иде – шәһәр халкы сулыкка таба бөтен районнардан агылды. Күпләр гаҗәпләнүләрен дә яшермәде – бу чыннан да безгәме? Әйе, кадерле әлмәтләләр, шулай ук республиканың көньяк-көнчыгышында яшәүчеләр һәм аларның балалары, боларның барысы да сезнеке! Шулай ук – вейк-бординг белән шөгыльләнү өчен парк та – спортның бу төре безнең илдә популярлык яулый гына бара. Күлдә су чаңгыларында шөгыльләнү өчен ике трасса ясалган (башлап шөгыльләнүчеләргә һәм остаракларга). Гаилә белән актив ял итүчеләргә – скалодром, арканлы парк, тренажерлы мәйданчык, пляж волейболы, балалар өчен мәйданчык. Һәм террасалы кафе – ул ел әйләнәсе эшләячәк. Һәм көймәләр, катамараннарны прокатка бирү пункты. Ачык һавада бассейны, спей-паркы (балалар өчен сулы мәйданнар) һәм сауналары да бар. Һәм, ниһаять, фитнес һәм йога белән шөгыльләнү өчен ике катлы павильоны. Тагын бик күп мавыктыргыч архитектура формалары, дизайнлы эскәмияләр. Бер сүз белән әйткәндә, шәһәр халкын тарту көченә ия булган бөтен нәрсә дә. Җәй көннәрендә генә түгел, мисал өчен, вейк-парк кышка тау чаңгычылары һәм сноубордчылар өчен күнекмәләр мәйданына әйләнәчәк. Пляжга керү бушлай. Алга таба инде теләккә һәм мөмкинлеккә карап: пляж бушлай һәм коммерция нигезендә тәэмин итә торган зоналарны үз эченә ала.

Шәһәр халкына хәвеф-хәтәр турында борчылыр урын юк: пляжның барлык объектларында халыкара квалификацияле профессионал инструкторлар эшли; территориядә – сак предприятиесе хезмәткәрләре, коткаручылар кизү тора, ә суда даими рәвештә коткару көймәсе йөзә. Пляжда медицина хезмәте дә булачак.

– Мин бу матурлыкка сокланам! – диде пляж ачу тантанасына килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Бу вакыйганы РФ Дәүләт Думасы депутаты Ринат Хәйров (үзе дә Әлмәттә туып-үскән) «Татарстан»га болайрак шәрехләде:

– Мин үзем малай вакытта бу күлдә коена идем. Әти-әниләр, әлбәттә, ачуланалар иде, чөнки күл суының балалар сәламәтлеге өчен куркыныч булуын беләләр. Әмма малай кешене бу гына туктата аламы соң? Ә хәзерге малайларга качып йөрисе дә юк – пляж да, күл дә чиста. Бирелдәге инфраструктура балаларны гаджетлардан аерып, сулык ярында физик культура белән шөгыльләнергә этәрер, дип өметләнәм. Гомумән, Сулыкларны саклау елы кысаларында мондый проектларны тормышка ашырып, республика үз халкын кесә калынлыгы һәм социаль статусына карамыйча, сулыклардан тигез файдалану хокукы белән тәэмин итә.

...Кабатлап әйтәбез, Әлмәттәге шәһәр пляжы ТРнда тематик ел кысаларында ачылган беренче объект булды. Яланаяк ак кварцлы комнан атлаганда, вейк-бордистлар ясаган пируэтларны күзәтә-күзәтә, әлеге материалның авторы туктаусыз рәвештә мультфильм героеның танылган гыйбарәсен кабатлап барды. Аз гына үзгәртсәк, ул болайрак яңгырый: «Әйе... Мондый пляжым булса, бәлки, мин беркая да китмәс идем!»

Реклама

PRESSA.RU

СЫЙФАТ ШУЛ УК, ӘММА АРЗАНРАК

75 ел элек Казанның РТИ заводы үзенең эшчәнлеген илнең сугыш вакытындагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен резина-техник эшләнмәләр чыгарудан башлый. Заводта 46 кеше хезмәт куя. Бүген исә «Кама-Идел резина-техника акционерлык җәмгыяте» («КВАРТ» АҖнең) 1500 хезмәткәре 7 меңнән артык исемдәге продукция җитештереп, Россиянең барлык төбәкләрендә һәм якын чит илләрдә сата.

Импортны алыштыру һәм ассортиментны киңәйтү программасы кысаларында компания үз акчасына даими рәвештә яңа төр продукция эшләп, аны җитештерүгә кертә. Предприятие структурасына эшләнмәләрнең яңа төрен үзләштерүче проект-конструкторлык технологияләр бүлеге һәм резина кушылмаларының яңа рецептурасын тикшерү һәм уйлап чыгару өчен заманча җиһазландырылган лаборатория керә.

Июньдә «Халыкара Кыр көннәре» күргәзмәсендә компания серияле җитештерүгә чыгарылган яңа продукциясен дә, шулай ук инде тәҗрибә туплаган үрнәкләрен дә куйган иде. Алар арасында – 2014 елның мартында үзләштерелгән терлекчелек комплекслары өчен әзерләнгән 1800х1200х22 мм үлчәмдәге резина түшәкләр. Проектны гамәлгә ашыра башлаганчы, «КВАРТ» АҖ белгечләре тикшеренү үткәргәннәр, фермерлык хуҗалыкларында булганнар, терлекчеләрнең тәкъдим-теләкләрен тыңлаганнар. Мәгълүматлар туплаганнан соң, проект-конструкторлык бүлеге келәмнең конструкциясен эшли. «КВАРТ» АҖ белгечләре горурланып шуны ассызыклый: алар эшләгән түшәк техник характеристикасы ягыннан Kraiburg* (Германия) фирмасыныкыннан бер дә калышмый икән, ләкин шул ук вакытта өч тапкырга арзанрак. Бу турыда ТР ПРезиденты Рөстәм Миңнехановка да ул Дәүләт Думасының Аграр мәсьәләләр комитеты рәисенең беренче урынбасары, Сөт җитештерүчеләрнең милли берлеге президенты Айрат Хәйруллин белән «КВАРТ» АҖнең стенды янында тукталганда әйтәләр. Күргәзмә нәтиҗәсе буларак, «Кызыл Шәрык Агро» АҖ өчен эре партия эшләү турында сөйләшүләр бара инде. Продукциянең сыйфатын «Ак Барс» Холдинг компаниясендә дә уңай бәяләгәннәр. Бер объектны 2015 ел ахырында җәйгәннәр, алдагы заказлар буенча сөйләшүләр алып барыла.

Күргәзмәдә шулай ук силикон җиңнәр һәм патрубкалар бар иде, алар үзебезнең илдә җитештерелә торган автомобильләр һәм авыл хуҗалыгы техникасы кирәк-ярагы өчен 2015 елда чыгарыла башлаганнар. Бүгенге көнгә патрубкалар белән «КАМАЗ» ГАҖ кызыксынган, «РОСТСЕЛЬМАШ» ҖЧҖ белгечләре белән актив эш алып барыла. Әлегә машиналарны җыйганда, «РОСТСЕЛЬМАШ» ҖЧҖ Италиядән кайтартылганнарыннан файдалана, ләкин «КВАРТ» АҖндә җитештерелгәннәре сыйфат ягыннан бер дә калышмый, бәясе 20 процентка түбәнрәк.

«КВАРТ» АҖ ирешелгән уңышларда гына тукталып калмыйча, алга таба базарда киң кулланылыштагы продукцияләрнең яңа төрләрен үзләштерергә планлаштыра. 2017 елда сыеклыкларны күчереп йөртү өчен яссы килеш төрелә торган җиңнәр җитештерүне үзләштерү планлаштырылган. «КВАРТ» Россиядә аларны беренче җитештерүче булырга исәп тота. Сату базары сокланырлык. Аларның продукциясе нефтьчеләргә, металлургларга, шахтерларга һәм, әлбәттә инде, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә кирәк. Предприятиедә аларны арзан бәядән сыйфатлы продукция белән тәэмин итәчәкләренә ышаналар.

«КВАРТ» АҖнең авыл хуҗалыгы өчен генә резина-техник эшләнмәләр җитештерүче түгеллеген искә төшерү урынлы. Предприятие сәнәгатьнең бөтен тармакларында да кирәкле эшләнмәләрнең киң ассортиментын җитештерә. «КВАРТ» АҖ озак еллар дәвамында «Татнефть» ГАҖ белән эшли. Татарстан нефтьчеләре өчен 2014 елның декабрендә ТатНИПИнефть белән берлектә җитештерүгә суда бөртә һәм җылыга бирешми торган пакерлар чыгарылган. Функцияләре ягыннан алар Американың «ТАМ» фирмасы эшләнмәләре кебек үк, ләкин берничә тапкырга арзанрак. Бу яңалык белән тармакның «Газпромнефть», «Роснефть», «Сургутнефтегаз» кебек гигантлары да кызыксынган.

– Безнең предприятиедә заказчы белән арадашчыларсыз гына аралашу мөмкинлеген хуп күрәләр, менә шушындый чаралардагы кебек, – дип күргәзмәгә йомгак ясый «КВАРТ» АҖнең маркетинг бүлеге башлыгы Айрат Натфуллин. – Без ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, аеруча терлекчелек буенча министр урынбасары Нәҗип Хаҗиповка, министрлыкның күчмә утырышларына даими чакырып торганы өчен рәхмәтлебез. Андый чараларда без заказчының үзен ишетә алабыз, проблемалар турында фикер алышып, уртак тырышлыклар белән аларны хәл итү юлларын табабыз. Безнең предприятие кулланучыларыбызның югары таләпләренә җавап бирергә тырышып, актив рәвештә алга бара.

Реклама

* Kraiburg – Германиянең резина эшләнмәләр заводы.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Ефәк юл» батырлары **КЕМНӘР**

«Татарстанның» «алтын» запасын **НИЧЕК** тулыландырырга

Республиканың гастрономик бренды **НӘРСӘ** ул

Җиләк җыю «спорт төре» белән **КАЙДА** шөгыльләнәләр

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»НЫҢ АЛТЫН ЗАПАСЫ

Килешәсездер, йөз ел – ул узып барышлый гына билгеләп үтелә торган бәйрәм түгел. Бигрәк тә сүз яраткан республикабыз турында барган вакытта. Әйе, безнең мәңге яшь һәм дәртле Татарстаныбызга дүрт елдан нәкъ бер гасыр булачак!

1964 елның августы. КПСС ҮКның беренче секретаре Никита Хрущевның Татарстанга визиты. Бер айдан Никита Сергеевичны хакимияттән читләштерәләр һәм пенсиягә җибәрәләр.

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

1960нчы еллар. Сәламәт тәндә – сәламәт рух. Биектау районы мәктәпләренең берсендә – иртәнге гимнастика бара.

1970нче еллар. Иделдә кояш баешы. Барысы да бүгенгедәй кебек.

1955 елның июне. Казанга Һиндстан премьер-министры Джавахарлал Неру һәм аның кызы Индира Ганди килә.

1950нче еллар. «Ракета»ның иң тәүге капитаннарының берсе – Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев (сулдан) үзенең ярдәмчесе белән.

1984 ел. Евгений Евтушенко КДУның актлар залында үзенең «Мама и нейтронная бомба» поэмасын укый.

1968 елның җәе. Юрий Гагарин – Татарстанда совет-япон дуслыгы фестиваленең мактаулы кунагы.

Табигый, туган республикабыз белән исеме буенча гына түгел, рухы буенча да адаш булган журналыбызда алдан ук юбилярга нинди бүләк ясарбыз икән дип баш вата башладык. Һәм вакланып тормаска – БАНК бүләк итәргә булдык! Өстәвенә, анда сакланган акчалар беркайчан да үз бәясен югалтмый, доллар курсына бәйле булмый, ел саен кыйбатлана бара торганын. Һәм без аңа нигез салдык – бүгенге санда!

Таныш булыгыз, «Татарстан» журналының Фотобанкы. Аның сейфларында бик кыйммәтле хәзинәләр – фотосурәтләрдә сакланып калган зур тарихның геройлары һәм мизгелләре урын алачак. Республика, аның җиңүләре һәм ирешкән уңышларының елъязмасы. Һәрберебез банкта кертем ясаучы була алабыз – соңгы йөз елда республикабызның үсүе һәм чәчәк атуы, Татарстанда булган вакыйгалар турында сөйләгән сурәтләрне рәхмәт әйтеп алыр һәм саклар идек. Ә иң кызыклы фотоларны – укучылар игътибарына тәкъдим итәрбез.

Бүген исә Җәвит Акчурин – Фотобанкыбызның беренче мактаулы кертемчесенең эшләрен бастырабыз. Озак еллар дәвамында ул журналистика факультетында фото эшен укытты һәм беркайчан да фотоаппаратын кулыннан төшермәде. Сәясәтчеләр һәм галимнәр, шоу бизнес йолдызлары һәм Татарстанның гади кешеләре һәрвакыт аяз булмаган советлар чоры... – үзенең барлык уникаль фотоархивын Җәвит Галимович шушы көннәрдә «Татарстан» журналына бүләк итте.

PRESSA.RU

АК ЮЛБАРЫС ЭЗЕННӘН

«Ефәк юлы» раллиенда җиңү яулаган «КАМАЗ-мастер» командасының июль аенда ирешкән уңышы турында барлык алдынгы мәгълүмат агентлыклары хәбәр итте. Әмма җиңүгә ирешүнең нинди бәягә төшкәне кадрлар артында калды.– сезнең игътибарга «Татарстан» тәкъдим иткән узыш көндәлегеннән алынган өзекләрдә – ярышның иң кызыклы мизгелләре.

Яр Чаллы КАМАЗлары экипажы өчен үз җирендә узган әлеге кыска этап балалар өчен ясалган комлыктагы күңел ачу кебек кенә булды.

Фото: Ната Смирнова, «Ефәк юлы» проекты матбугат хезмәте тарафыннан тәкъдим ителде

Рәсми мәгълүматларга караганда, Пекинга кадәр сузылган ралли Мәскәүнең Кызыл мәйданыннан старт алды. Әмма 8 июльдә Васильевский спусктагы вакыйга узышлар алды гына – барлык 95 катнашучы экипажны тамашачыга тәкъдим итү булды. Әлеге парадны «Ефәк юлы»ның гамәлдәге җиңүчесе хокукында Дмитрий Сотниковның КАМАЗы ачты.

Ә чын-чынлап узыш бер көннән соң – Казанда башланып китте. Казансуның уң ярында урнашкан кечкенә генә ике километрлы тизләнеш участогы оештыручылар көче белән мәкерле чүл кисәгенә әйләндерелгән иде. Ком калкулыклары, капкын-чокырлар һәм текә борылышлар. Яңгыр астында юешләнгән үзле комда озак вакытка ике джип батып кала. 2006 елда узган «Дакар» раллиеның җиңүчесе Люк Альфарның старт алдыннан әйтелгән сүзләре юш килде. Ул болай дигән иде: «Ике километрга сузылган әлеге участокта җитди көрәш булачак. Биредә бик зур җиңү яулап булмас, әмма бик күп нәрсәне югалтырга мөмкин...»

Әмма Яр Чаллы КАМАЗлары экипажы өчен үз җирендә узган әлеге кыска этап балалар өчен ясалган комлыктагы күңел ачу кебек кенә булды: ул юлны алар бик ашкынып һәм югалтуларсыз гына узды. Үзләренеке өчен җан аткан тамашачылар, әлбәттә, бу күренешне ошатты. Бигрәк тә Эдуард Николаев ярышка кушылган вакытта. Чөнки аның экипажы әлеге узышта капотының башкарылышы ягыннан яңа булган машинаны сыный. 310нчы номерлы матур кара йөк машинасы соңгылар рәтендә, инде бик соң – төнлә белән старт алды. Яңа машина үзен ефәктән шактый ерак торган юлда ничек тотар, анысын алдагы көннәр күрсәтер.

– Миңа әле алда капот булуга күнегергә, яңа машинага өйрәнергә, аны тоемларга кирәк, – ди Эдуард Николаев. – Без командада даими рәвештә иң югары нәтиҗәләргә

Автор:
Артур Хисмәтуллин

PRESSA.RU

Узыш өчен махсус әзерләнгән тизләнешле юлсыз участок пычрак измәсенә әйләнде, ә бу экипажлар өчен үтеп булмаслык киртәгә әйләнергә мөмкин иде.

ирешү өчен бездә иң яхшы техника булсын өчен эшлибез.

Узышта техника күп нәрсәдә зур роль уйный, шулай да бөтен нәрсәдә үк түгел. Читтән тәэсир итә торган факторлар да җитәрлек. Мәсәлән, һава торышы. Татарстанда ул коеп яуган яңгырлары белән истә калды, оештыручыларга хәтта Казан һәм Уфа арасындагы өлештә планлаштырылган тиз йөри торган араны уздырмаска туры килде. Узыш өчен махсус әзерләнгән тизләнешле юлсыз бу ара пычрак измәсенә әверелде, ә бу экипажлар өчен үтеп булмаслык киртәгә әйләнергә мөмкин иде. Хәер, әлеге «вак-төяк» «КАМАЗ-мастер» командасының җанатарларына автошәһәрдә матур очрашу оештыру өчен киртә булмады. Узышчылар кәрванын каршыларга дип шәһәр урамына меңнәрчә шәһәр халкы чыккан иде. Яр Чаллы шәһәре мэры Наил Мәһдиев халык алдында командага булган мәхәббәтен аңлатты:

– Болар безнең шәһәр һәм безнең ил геройлары. «КАМАЗ-мастер»ның җиңүенә ышанабыз.

13 июль. Узышчылар Казахстан далаларында сынау уза. Кустанайдан Астанага кадәр булган этапта аларга 720 километрдан артык юл узарга кирәк, шуларның 220 километры – тизләнешле участок. Яңгырлар даланы юып ашаган, шуңа биредән үтү кыенлашкан. Трассаның урта бер өлешендә зур бер пычрак кисәге Айрат Мәрдиевның КАМАЗына «кизәнде». Нәтиҗәдә электрика сафтан чыкты. Төзәтүен төзәттеләр, тик шактый вакыт әрәмгә киткән иде.

– Пычраклык аркасында ярты трассаны юлга аркылы бардык, тайгак үләндә машина туры бара алмый иде, – дип аңлатты фиништан соң Айрат Мәрдиев.

Алма-Атадан Кытайның Бортал шәһәренә кадәр сузылган **җиденче этап** хәлиткеч булды. Махсус араның 32нче километрында капотлы КАМАЗ тиз генә калкулык аша сикереп узды һәм... ташка килеп төште. Картер тишелде, җиргә май ага башлады. Тишек бик зур, экипаж аны «салкын эретеп ябыштыру» ысулы белән ямарга маташа. Әмма чишмәдән ургылган май ямаулыкны кабат юып төшерә. Кабат ремонт... Нәтиҗәдә лидер буларак старт алган «өч йөз унынчы» финишка егерме беренче булып килә. Җиңү дигән хыял белән хушлашыргамы инде?

18 июль. Тугызынчы этап. Өремче – Хами. Африкадагы узышу диярсең. 45 градус эсселектә ком буйлап 384 километр юл узасы.

– Без старт вакытында ук бик эссе буласын аңладык һәм үзебез белән күбрәк су алдык, – дип сөйли 306 номерлы КАМАЗ пилоты Айрат Мәрдиев. – Мин йөк машиналары арасында икенче булып, артта калган этапның җиңүчесе голландияле Мартин Ван ден Бринктан соң старт алдым. Үз алдыма аны куып тоту максатын



куйдым. Һәм, алда баручы көндәшем инде 40нчы километрда ук күренә башлагач, бик шаккаттым. Узыш вакытында без зур ком чокыры күрдек, аның янынан ук узып киттек, бик саклык белән генә төштек. Ул чакта ук катнашучыларның кайсы да булса берсе һичшиксез монда төшеп утырыр әле дип уйлап куйдым. Ә Брикны без комнан чыгып барган чакта ук узып киттек. Һәм этапны беренче булып тәмамладык.

Мәрдиев саклык белән узып киткән ком чокырында Андрей Каргиновның 314 номерлы экипажы әйләнеп капланган. Раллиның соңгы этапларында ул команда буенча иптәшләрен саклап барган, арттан барган. Ә менә аның үзенә ярдәм кирәк булгач, көндәшләрнең берсе дә туктамаган, ә үзенекеләр инде еракта булган. Бәхеткә, экипаждагыларның берсе дә имгәнмәгән.

Хамидан Дунхуанга кадәр сузылган **унынчы этап** каньоннар аша туфраклы юлдан уза. Тизләнеш_ле участокны тәмамлый торган өлеш – диңгездән ике мең метр биеклектә: пилотларның колагы томалана. Этапны россиялеләрнең төп көндәше голландияле Мартин Ван ден Бринк җиңә. Ул узышта һаман лидер булып бара, әмма Айрат Мәрдиевны бу хәл каушатмый:

– Брин әйбәт бара, әмма аның арыганлыгы күренә. Соңгы этапта ул тишелгән тәгәрмәчләр белән финишка керде, – дип әйтә Айрат.

Көч сынашачакбыз әле. Әмма шулвакыт һава торышы голландияле ягына күчә. Гоби чүлендә ком давылы, һәм унберенче этап үткәрелми. Безнекеләр голландияле артыннан җитеп өлгерерме? Ә бит узышның финишына кадәр күп калмады...

Уникенче этап. 425 километр озынлыктагы махсус участок ком һәм корыган елгалар үзәне аша уза. Дюналар аша югалтуларсыз узу – җебегәннәр өчен куелган максат түгел. Тәвәккәлләсәң – тәмам батып калырга мөмкин, сак кылансаң – вакытны югалтасың. Безнекеләр – тәвәккәлли. Һәм җиңә! Эдуард Николаев – этапта беренче, Мәрдиев – икенче. Әмма Айрат төп бурычын үти – голландиялене уза. Хәзер йөк машиналары классындагы узышның лидеры – Россия экипажы!

– Без Ван ден Бринктан соң дүрт минут узгач старт алдык, – дип сөйли Мәрдиев. – Мин эзләре буенча ук аның бездән алга китәргә маташуын күрдем, әмма барыбер без аны узып киттек. Мин сигналга баскач та, ул безне уздырып җибәрде. Аннан соң, 140нчы километр тирәсендә тәгәрмәчебез тишелгән булса да, мин аны күрмәдем. Финишка тәгәрмәчкә һаваны суыртып өстәгән хәлдә барып җиттек.

Бар нәрсәгә нокта ком аша уза торган **14 этапта** куелды. Ул вакытка Айрат Мәрдиевнең 306нчы КАМАЗы арттан баручылардан шактый алга китә алды, һәм аңа юлны хәвеф-хәтәрләрсез, тыныч кына узу кирәк иде. Ул әлеге бурычны төгәл үтәде.

– Без аз гына темпны киметтек, тыныч кына бардык, чөнки көзгедән артыбыздан килүчеләрне күрмәдек. Матур калкулыкларны карап хозурланырга мөмкинлек туды. Ышаныгыз, андый мөмкинлек бик сирәк очракта гына була, – дип сөйләде соңрак Айрат Мәрдиев.

Һәм менә барысы да тәмам. Ун меңнән артык километрга сузылган авыр узыш артта калды. Алда – 500 километрлы соңгы этап, ул инде бернәрсәгә дә тәэсир итми. Узышчыларга бары тик яуланган урыннары буенча тантаналы рәвештә Пекинга керәсе генә калды.

24 июль. Пекинның танылган «Кош оясы» дип аталган Олимпия стадионы каршында бүләкләү тантанасы. Айрат Мәрдиев һәм Дмитрий Сотников экипажларына йөк машиналары классында беренче һәм икенче урыннар өчен трофей: бронзадан ясалган ак юлбарысларны тапшыралар. Күк мифологиясендә юлбарыс батырлык һәм рухи ныклыкны аңлата.

Безнең узышчылар әлеге сыйфатларны тулысынча күрсәтте. Лидерлар гына түгел – бердәм механизм булып эшләгән бөтен команда. Алай булмаса, җиңүгә ирешеп булыр иде микән?! Истәлек өчен фотосурәт: Мәрдиев һәм Сотников экипажлары янында подиумда «зәңгәр армада»ның барлык экипажларында көч түккән пилотлар, штурманнар һәм механиклар. Җиңү – барысы өчен дә бер ул!

PRESSA.RU

ТЕЛ ЙОТАРЛЫК ТАТАРСТАН

«Тамак туя – күз туймый». Бу гыйбарә безнең татар милли ризыкларына бик тә туры килә. Туристлар өчпомакларыбызга беренче кабып караудан ук гашыйк була, диләр. «Татарстан» журналы кайсы районнарның нинди ризыклар белән дан тотуын ачыклады.

Автор:
Линар Закиров

ЛАЕШ КАЗЛАРЫ

Лаеш районындагы Имәнкискә авылына килеп кергәч, кая карарга да белмәссең – адым саен берсеннән-берсе тәмле ризык сатыла. Мондый матурлыкка машинадан гына карап буламыни?! Бер сәүдә ноктасы янында туктап, казылыкка һәм аның белән аралаштырып эленгән кара төстәге таякларга игътибар иттек.

– Нәрсә соң бу? – дип аптырадык.

– Казылыкка охшатып ясалган агач ботаклары бу. Казылык әз калды, шуңа таяк эләргә туры килде. Товар матур күренергә тиеш бит, – диде әңгәдәшебез.

Без Имәнкискәгә казылык түгел, ә какланган һәм ысланган каз эзләп килдек. Гайсә абый Мөхәммәтҗанов авылда казны иң оста каклаучыларның берсе икән.

– Бу безнең гаилә бизнесы, – дип башлады ул сүзен. – Казларга кадәр җиләк, йомырка саттык, күпләп тавык асрадык. Ә 15 ел элек күңелебез казларга тартты. Талымлы түгелләр, төп ризыклары – чирәм белән су. Безнең авылда бик оста мал табибы бар. Пенсиядә булса да, казларыбызга һәрвакыт витаминнар алып килә. Шуңа күрә алар сау-сәламәт булып үсеп җитә, – ди.

Мөхәммәтҗановларның 1500 казы бакчада каңгылдый, шуңа да бәрәңгене кырда үстерәләр. Гайсә Мөхәммәтҗанов әйтүенчә, мөгезле эре терлеккә караганда, кошлар акчаны күбрәк тә, тизрәк тә китерә. Үгез симертүгә өч ел чамасы китсә, казлар алты ай дигәндә әзер була. Сентябрь-октябрьдә Мөхәммәтҗановларда өмә башлана.

– Каклау һәм ыслау өчен зур бинабыз бар, озынлыгы – 15 метр, киңлеге – 7 метр. Җәй көне ысламыйлар, моның белән чебеннәр очудан туктагач, салкынча көннәрдә генә шөгыльләнергә кирәк. Гадәттә, ыслау сезоны сигезенче мартка тәмамлана. Җәен заказ буенча гына әзерләп бирәбез, – дип сөйләде Гайсә әфәнде.

Ул безгә казны өй шартларында ничек ысларга кирәклеген тәфсилләп сөйләде. Иң элек рассол әзерлисе: өч килограммлы каз исәбеннән кайнаган суга ике килограмм тоз, укроп һәм башке төрле тәмләткечләр салабыз. Түшкәне рассолда бер атна тотабыз. Аннары тышын кат-кат тоз белән ышкыйбыз да эченә икешәр килограмм тоз һәм бодай тутырабыз.

– Казның эчендә урын күп, бөтен нәрсә сыя, борчылмагыз, – дип елмая гаилә башлыгы. – Казны кәгазь капчыкка төрәбез дә чормага элеп куябыз. Алты ай шунда торырга тиеш. Бөтен нәрсәне вакытында эшләп куйсаң, сабан туена тел йотарлык ризык әзер дә була, – диде.

Гайсә абый казны ыслау серләрен дә ачып салды.

– Түшкәне рассолда ике тәүлек тотарга кирәк. Шуннан соң аны ыслагычка (коптилка) урнаштырабыз. Аның белән эш иткәндә бензин кулланырга ярамый. Юкә яки имән агачы тузанын гына яндыру рөхсәт ителә. Бераз гына булса да нарат агачы тузаны эләксә, сумала түшкәгә тиеп, тәмен бозачак, – дип аңлатты Гайсә әфәнде.

Әңгәмәдәшебез ысланган, какланган каз алганда, нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеген дә сөйләде.

– Яхшы ысланган каз алтынсу төстә булырга тиеш. Тоз аз кулланылган булса, иттән ят ис аңкып торачак. Тәм буенча да чамалап була. Казның бот тирәсеннән бераз гына кисеп аласыз да авыз итеп карыйсыз. Түшкәнең кыяфәтенә бер зыян да килмәячәк, – диде ул.

Имәнкискәлеләргә карап, Азнакай, Балык Бистәсе, Чистай районнарында каз бизнесын җәелдерүчеләр күбәйгән икән.

– Минем янга республиканың төрле почмакларыннан килеп, казларны үстерү һәм әзерләү турында сораштыралар. Ике сәгать дәвамында бар белгәнемне ачып салам. Июнь ахырында ике егет килеп китте әле. Алар күптән түгел армиядән кайтканнар да ике йөзәр баш каз алганнар, – дип сөйләде әңгәмәдәшебез.

Сатып алучыларның да тынычлыкта калдырганы юк, дип өстәде каз патшасы. Яңа ел алдыннан шалтыратып, берничәшәр түшкәгә заказ ясыйлар. 31 декабрь көнендә Мөхәммәтҗановларның 150ләп казы Яңа ел табынына «очып китә».

Имәнкискә эшкуарлары арасында көндәшлек юк, дип ышандырды безне Гайсә әфәнде.

– Мисал өчен, минем казларымны алып бетерделәр, ә кемдәдер, киресенчә, күп калды, ди. Мин шул кешедән сорасам, ул мизгел эчендә китереп бирәчәк. Үзегез аңлыйсыздыр инде, сату урыны матур күренергә тиеш. Бер генә каз эленеп торса, нинди хәл, ди ул. Иманым камил, сатып алучы бер генә түгел, ә унлап каз эленеп торган кибет янында туктаячак, – дип маркетинг серләренә дә төшендерде каз патшасы.

БАЛЫК БИСТӘСЕ БАЛЫКЛАРЫ

– Елга балыкларыннан бездә корбан балыгы, алабуга, судак, җәен, жерех, ә диңгезнекеннән – форель, сайра һәм терпуг бар, – дип, «Нива» машинасының багажнигына җәеп салынган товарлары турында сөйли башлады Анна Тимина. Әңгәмдәшебез Балык Бистәсе районындагы Саескан Тавы авылы тирәсендә, Кама елгасы аша салынган күпер янында ысланган һәм киптерелгән балык сата.

Аның сөйләвенчә, 15 ел элек, Кама өстеннән күпер салынганчы, машиналарны елганың бер ярыннан икенчесенә паром күчергәндә, хатын-кызлар балыкны көймәдә дә, паромга су буе булып җыелган машинадан-машинага йөреп тә саткан.

– Ул вакытта балыкны эшкәртмичә генә ыслый идек. Тора-бара кешеләр эшкәртеп бирегез, дип үтенде. Элек, бүтән төрле технология буенча ыслаганда, балык кап-кара була иде. Ыслау рәвешен үзгәрткәч, шушындый алтын төскә керә башлады. Заман белән бергә атлыйбыз, – дип горурланып сөйләде әңгәмәдәшебез.

Сатучыларның күпчелеге балыкны үзе тотмый, ә сатып ала икән.

– Зур партияләп – 50-100әр килограмм алабыз. Балыкны өйгә үк китерәләр. Башта аерабыз: ыслый торганнарын – үзенә, киптерергә дигәннәрен – үзенә. Яхшы балык каты булырга һәм сөякләре таралып тормаска тиеш. Кайвакыт начары да эләгә. Киптерелгән балыкта, әйтик, корбанда, солитер дип аталган суалчан булырга мөмкин, ул кеше сәламәтлегенә зыянлы. Балыкны яргач, паразит шунда ук килеп чыга. Андый балыкны, әлбәттә, ташлыйбыз. Бәхеткә, соңгы вакытта солитер очрамый диярлек.

Балыкны зур тазларга салабыз да эшкәртә башлыйбыз. Берничә сәгать тозда тотам да, каны һәм шакшысы калмаслык итеп юам. Бу бик мәшәкатьле эш, бөтен бармакларым җәрәхәтле, – дип, Анна кулларын сузып күрсәтте.

Балык 40 минут ыслана. Моның белән кичен шөгыльләнәләр дә товарны икенче көнне иртән иртүк сатуга чыгаралар. Ысланган килеш ул ике көн генә тора ала. Бер көн эчендә бөтен балыкны алып бетерәләр, диярлек, дип күзен дә йоммыйча әйтте Анна. Беренче көндә сатылмый калган балык икенче көнгә күчә. Икенче көндә беркем алмаса, аны песиләргә ашаталар.

Киптерелгән балыкка да сорау зур. Башта аны, өстенә авыр әйбер белән бастырып, бер тәүлек тозлы суда тоталар, ә аннары бер атна киптерәләр.

– Ысланган балык сатып алганда нәрсәгә игътибар итәсе?

– Сатучының киңәшләренә колак салыгыз, беренче эш итеп яңа балыкны биреп җибәрергә тырышабыз. Безнең янга зур-зур автобуслар килеп туктый, кемдер үзенә, кемдер күчтәнәчкә ала… Сезгә иске, бозылган балыкның нинди булуын күрсәтер идем. Ни кызганыч, андые миндә юк, – дип сөйләнде Анна, товарын актарган арада.

– «Кызганычка» түгел, «бәхеткә» диегез…

Имәнкискәдә, Гайсә абый ышандырганча, эшкуарлар арасында көндәшлекнең эзе дә булмаса, Саескан тавында күзәтелә. Сатучылар үзләре дә моны яшерми.

– Кемдәдер балыкның – бер төрлесе, ә кемдәдер икенче төрлесе бар. Әйтик, миндә терпуг бар, ә күршемдә ул юк. Биредә тәкъдим ителгән балыкның иң кыйммәтлесе – җәен, бер кисәге 700 сумга кадәр җитәргә мөмкин, – дип шаккатырды әңгәмәдәшебез. – Теге яки бу балыкның сатуда булуы сезонга бәйле. Язын судакларны күп тоталар. Уылдык чәчү чорында балык булмый, диярлек. Кайсысын күпләп алырга өлгерәсең, шунысын сатасың.

– Яңа ел табынына төп ризыкны балыктан әзерлисездер, мөгаен?

– Ю-у-ук инде, – диде Анна. – Без аны көн дә ашыйбыз. Балык бик файдалы.

– Өч яшьлек балам көненә бер терпуг яки судак ашый, – дип әңгәмәгә күршедәге сатучы да кушылды. – Һәр ял көнендә балыкка йөрибез. Күңел өчен…

Сатучы кызлар балыктан уха, җәеннән шашлык ясаулары турында да сөйләде.

– Уханы нәкъ менә учакта әзерләргә кирәк. Өйдә андыйны пешереп булмый, – диде Анна.

– Санэпидемстанция белән мөнәсәбәтләрегез ничек соң? – дип уңайсыз сорау да бирдек әле.

– Ай саен киләләр, кайвакыт икешәр тапкыр, бөтен нәрсәне тикшерәләр. Бер агулану очрагы да булганы юк, – дип сөйләде Анна Тимина. – Без монда гел эшлибез. Ә кайбер сатучылар, трассага чыгып баса да, үз урыннарын алыштырып тора. Кайбер юлчылар, трассада бозылган балык алып, монда киләләр дә, безне гаепле итеп калдырмакчы булалар, – дип сөйләде.

Фото: Луиза Шарова

PRESSA.RU

Гатауллиннарның ике сыеры тәүлегенә 15 литрдан артык сөт бирә. Терлек азыгын күбрәк бирсәң, сыерлар да сөтне арттыра. Каймакның тәме азыкка бәйле. Сыер әрем ашаса, каймакка да әче тәм керә.

– Малга борчак, печән, салам бирәбез. Үгезләр дә тотабыз. Кышын суеп, итен сатабыз. Аны «сөтле» клиентларыбыз алып бетерә, – дип елмайды Фәүзия апа белән Илдус абый.

– Терлек санын арттырырга җыенасызмы?

– Юк, болай да инде җиңел түгел. Шушы сыерларны да балалар хакына гына тотабыз.

Фәүзия апа эремчекне менә ничек әзерли: сөтне сепаратор аша чыгарып, бер көн оета. Икенче көнне килеп чыккан массаны марляга төреп, өстенә авыр әйбер бастыра. Суы саркып чыксын өчен. Өченче көнгә эремчек әзер дә була. Аңардан исә гөбәдиягә салына торган корт әзерлиләр. Моның өчен эремчеккә сөт салып кайнаталар. Килеп чыккан массаның сыекчасын саркытып, сулы кәстрүлгә салып, шикәр комы өстиләр дә, кызарганчы, гадәттә, көне буе кайнаталар.

ШӘЛЕ СӨТЕ

Шәле – Татарстанның иң зур авылы, биредә бер меңнән артык хуҗалык исәпләнә. Җирле халык сөт ризыклары: сөт, каймак, эремчек, корт белән дан тота. Уңган-булган шәлелеләрне башкаланың һәр базарында очратырга була.

Фәүзия апа белән Илдус абый Гатауллиннар 1978 елда өйләнешкәннәр. Шуннан бирле бүгенге көнгә чаклы ике сыер тоталар. Фәүзия апа гомере буе фермада эшләгән. 2003 елга кадәр сөт ризыкларын Казанга үзе алып барып сатса, шуннан соң эстафетаны улы Илгиз белән килене Гөлфинәгә тапшырган.

– Шәледә сыер тотучылар аз. Элек көтүгә 200ләп баш сыер чыкса, хәзер утызга да тулмый. Безнең тирәдә яшәүчеләрнең күбесе сөтне миннән килеп ала, шәһәр халкына аз гына кала. Казанда даими клиентларыбыз бар, продукция шуларга гына җитә. Улым белән киленем шәһәргә алты литр каймак, 20 килограмм эремчек һәм 1,5 литрлы 10 шешә сөт алып бара. Заманында сөтне Казанга чиләкләп, көянтәләр белән автобуста ташый идек, – дип хатирәсе белән уртаклашты Фәүзия апа.

Әңгәмәдәшләребез сөйләвенчә, үз вакытында авылда колхоз җирләренә мал-туарны кертмәгәннәр. Ә хәзер әлеге җирләрнең беркемгә кирәге калмаган. Сүз уңаеннан, Шәле авылы тигәнәккә баткан. Шуларны чабып чыгу авырмы икән?!

МАМАДЫШНЫҢ КАМЫР РИЗЫКЛАРЫ

Мамадыштагы камыр ризыклары сатыла торган тукталышны ничек кенә атамыйлар: «Йөремсәк пәрәмәчләр», «Зеленка», «Пятачок», «Яшел тукталыш», «Чишмә», «Рәхмәт аланы», «Татарча Макдоналдс»... Соңгысы белән уртаклыклар, чыннан да, бар. Мондагы милли (өчпочмак, гөбәдия, чәкчәк, кыстыбый) һәм интернациональ (пицца, вафельная трубочка, королевская ватрушка) ризыкларны юлчылар мизгел эчендә ашап бетерә.

Түбән Сөн авылыннан Гөлфираз апа Усманова «Рәхмәт аланы» оешкан мәлдә – 1993 елдан бирле монда. Элек-электән бу урын Сай кичү дип аталган.

– Моннан ерак түгел чишмә бар. 90нчы елларда аның янәшәсеннән юл салгач, машина йөртүчеләр анда туктый башлады. Шул тирәдә яшәүче хатынга юлчылар камыр ризыклары сатарга тәкъдим иткәч, ул кыстыбый әзерләп чыккан. Сеңлем, чишмә янынан узганда, күршеләребезнең дә сатып утырганын күргән дә, мине бу эш белән шөгыльләнергә үгетләде, – дип сөйләде Гөлфираз апа.

Көннәрдән бер көнне ул, фермадагы эшен ташлап, бер чиләк дучмак пешергән дә шул тукталышка киткән.

– Беренче көнне «Рәхмәт аланы»на авыл юлыннан түгел, ә басу аша киттем. Кеше күзенә күренәсем килмәде. Дучмакларны күз ачып йомганчы алып бетерделәр. Тере акча тотып, өйгә кош тоткандай кайтып кердем. Ул вакытта колхозда акча бирмиләр иде. Шуннан соң,

миңа карап, башкалар да камыр ризыклары сатып көн күрә башлады, – дип сөйләде әңгәмәдәшебез. Биредә хәзер Мамадыштан гына түгел, Алабуга белән Чаллыдан да килеп саталар.

Хатын-кызлар ике сменалап эшли, Гөлфираз апа – икенчесендә. Өенә төнлә кайтып керә. Иртән торып, пешеренә дә көннең кыл уртасына ризыклары инде әзер була.

– Юлчылар бөтен нәрсәне үз итә: өчпочмакны да, королевская ватрушканы да. Без мал тотмыйбыз, эремчек белән кортны авыл халкыннан сатып алабыз, – диде ул.

– Беренче булып аның гөбәдиясен алып бетерәләр, – дип сөйләшүгә Гөлфираз апаның сул ягында балык сатучы хезмәттәше кушылды.

– Һәркем үз рецепты буенча әзерли, – дип дәвам итте Гөлфираз апа. – Мин әбием белән әнием өйрәткәнчә пешерәм. Гөбәдиягә йомырка кушарга кирәк, әмма мин аны кулланмыйм, чөнки җылыда торып, ул пирогның тәмен боза.

Мамадышта дөге бәлешен яратып пешерәләр. Кодагыем Яңа Чишмә районында яши. Берсендә аңа үзебезнең бәлешне алып бардым, чөнки аларның ягында итле бәлешкә өстенлек бирәләр. Өчпочмакны сыер итеннән әзерлим. Чәкчәкне дә үз куллары белән пешердем, – дип халкыбызның төп ризыгына ымлады ул.

– Чит ил туристлары да туктыймы соң?

– Еш туктый, аңлашуда кыенлыклар тумый, аларны еш кына рус телен белгән гидлар озата йөри. Күптән түгел французлар белән таныштык әле. 6-7 машина белән дөнья буйлап сәяхәт иткән чаклары иде. Аларны ашаттык, мәтрүшкәле чәй эчерттек. Бик канәгать калдылар.

ӘЛМӘТ БАЛЫ

Башкорт балы бренд дәрәҗәсенә җитеп, бүген сыйфат билгесе буларак кабул ителә. Татар балын да танытырга кирәк, диләр Әлмәт районы Чупай авылында яшәүче этиле-уллы умартачылар Наил белән Рамил Гыйбадуллиннар. Без аларның бал аерткан чагына туры килдек.

– Бабам да, әтием дә озак еллар умарта тоткан. Әтигә карап, мин дә бу шөгыльгә тартылдым. Бүгенге көндә урманда 35 умартабыз бар. Унлап кына умартаны бакчада да тотарга була. Артыкка китсә, кортлар күршеләрне тынгысызлый башлый, шуңа күрә басуга яки урманга чыгару ягын карарга кирәк була. Балны ел саен бер үк вакытта түгел, өлгерүенә карап, төрлечә аертабыз, – дип сөйләде Рамил.

– Өлгергәнлеген ничек белеп була? – дим.

– Кортлар балны рамдагы кәрәзгә тутырып, өстен каплый. Умартачылар телендә бу «печатьләү» дип атала. Әгәр рамның, ким дигәндә, яртысы печать белән капланса, бал өлгергән булып чыга. Бездә кортларның ике төре бар: среднерусские һәм карпатка. Китапта язылганча, карпатканың борыны озынрак, шуңа да ул среднерусские керә алмаган чәчәкләрдән дә нектар җыя ала. Кортлар башта чәчәктән нектар җыя, умартага кайткач кына аны балга әйләндерә.

Алар шулкадәр эшчән, йокламыйча, көне-төне эшлиләр дә эшлиләр. Рамнар бал белән шыплап тулып, кортлар эшсез калса, умартаны ташлап чыгып китәләр, шуңа күрә аларны гел карап торырга кирәк, – диде ул.

Яшь умартачы сөйләвенчә, һәр балның үзенчәлеге бар: төс ягыннан юкәнеке үтәкүренмәле, донникныкы аксыл, көнбагыш белән рапсныкы саргылт, әлеге баллар тиз «утыра». Ә иң «чыдамы» – чәчәк балы.

– Бал сатып алганда еш кына, нәрсәдән җыелган, дип сорыйлар. Ул тулысынча бер генә төрле була алмый, кортларның бер өлеше нектарны башка чәчәктән алып кайтырга мөмкин. Башкача да була ала: кортлар балны ике атна юкәдән җыеп бетергәч, башка чәчәккә күчәргә мөмкиннәр, – дип аңлатты Рамил.

– Күп кенә кешеләр тарафыннан макталган башкорт балыннан авыз иткәнең бармы?

– Әйе, юкәнекен кабып караганым бар. Безнекеннән тәмлерәк, дип әйтә алмыйм, бер чама. Әмма безнең якларда чиста юкә балы сирәк очрый. Башкорт балын элек тә, хәзер дә күп кенә күргәзмәләргә алып барганнар. Шулай йөри торгач, бренд итүгә ирешкәннәр. Безгә дә алардан үрнәк алып, тел йоларлык балларыбызны чит төбәкләрдә һәм илләрдә танытырга кирәк, – диде ул.

Фото: Линар Закиров

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

Эх, җиләкле җәйләре...

«Җәйне ни өчен яратасың?» – дип сорасалар һәм дә җавабымны бары тик өч сүз белән генә җиткерергә кушсалар, мин болай дип җавап кайтарыр идем: «Җиләк. Кайнатма. Компот». Ашарга яратканга гына да түгел, ә җиләкнең җәй фасылын суыткычларда ел дәвамында саклап, истә тотучы булганына.

Автор:
Айсылу Хаҗиева

СПОРТНЫҢ «ҖИЛӘК ҖЫЮ» ТӨРЕ

Дөресен генә әйткәндә, мин ике шөгыльне яратып бетермим. Беренчесе балык тоту булса, икенчесе – җиләк җыю. Чиләккә дә җыеп карыйм үзен, ашап та, ләкин җыелмый. Нишләтәсең?! Моны холыкка бәйле, ди белгечләр. Җиләк җыю бертөрле, монотон рәвештә башкарыла торган эшләргә кергәнгә күрә, моңа бары тик сабыр, тыныч холыклы кешеләр генә алына ала икән. Шулай ук «тургай», «ябалак», «күгәрчен» классификациясен искә төшерсәк, җиләк җыярга барыр өчен, «тургай» булып туарга кирәк, имештер. Чөнки кояшның беренче нурлары белән син, чиләк-бидоннарыңны алып, елга буйларына кузгалырга тиеш булачаксың.

Минемчә, җәйнең чын-чынлап башланганын календарь буенча түгел, ә юл буйларында җиләк сатып торучы апаларга карап билгеләргә кирәктер. Кая да булса сәфәргә чыксаң, 5-10 чакрым саен машиналар тора, ә яннарында исә – чиләк-чиләк тәмле, хуш исле җир җиләге... Шунысы кызганыч: җиләкләре авыз суларын китерсә дә, бәяләре уйланырга мәҗбүр итә. Хаклары 1 литры өчен 500 сумнан башлана, ә ул әле чистартылган да булса, бу матур чиләкләр янына якын килем димә. Җир җиләге арзан бәядән «йөри» дә алмый торгандыр. Бу кәсеп белән шөгыльләнүчеләр минем белән килешер. Мыжлап торган черки, озынборын, кигәвен арасында, иелеп-бөгелеп, кеп-кечкенә җиләкләрне җыю – бер дә рәхәт эш түгел.

Шуңа да карамастан, «җиләк сезоны»ның башланганын зарыгып көтүчеләр бихисап. Авыл җирлегендә яшәүчеләр өчен бу үзенә күрә спорт төре дә бит. Бер-берең белән: «Ә без фәлән кадәр җыйдык!» – дип мактанышып алулары ни тора! Шушы мөлдерәмә тулган чиләкләрне күргәч, ару-талулар да юкка чыга торгандыр. Ә инде аларны кайнатып, кышка әзерләп куйгач, дөньясы бөтенләй түгәрәкләнә...

Сез дә сизәсез, мөгаен, безнең тормышыбыз көннән-көн үзгәрә бара. Кәстрүл, пастеризацияләнгән банкалар, кайнатылган капкачлар урынына иттарткычлар (ә җиләк сезонында алар җиләктарткычларга әйләнә), блендерлар килә. Минем абыем кайнатмалар әзерләү вакытында аш бүлмәсенә кереп тә карамый. «Өйдән Ташкент ясагансыз!» – дип, үзалдына сөйләнеп, ишегалдында юк була...

Мин менә мондый сорауга җавап эзләдем бу җәйдә: кайнатылган җиләкме, әллә бары шикәр комы салып болгатып куелганымы? Кайсы файдалырак? Шушы сорауга җавапны кичекмәстән эзләп табарга кирәк иде! Ләкин, әйткәнемчә, мин җиләк җыярга яратучылар рәтеннән түгел, шуңа да бу өлкәдә миңа караганда күпкә тәҗрибәлерәк булган кешеләргә мөрәҗәгать иттем.

ГАИЛӘ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘДЕК!

Бу ел җиләк җыярга яратучылар өчен аеруча уңышлы булды. «Җиләк күп икән, башкалар җыеп бетергәнче, миңа да барып кайтырга кирәк», – дигән сүзләрне кемнән генә ишетмәдем. Шуңа да җиләк җыяр өчен ерак сәфәргә чыгып тормадык, ә Казанга терәлеп үк торган Теләче районына юл тоттык. Айдар авылын күргәч тә, телгә Габдулла Тукай шигыре килеп төште:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул...

Чынлап та, Айдар авылы тау башына салынган, чишмәләргә дә бай икән. Бер чишмәсе нәкъ авыл уртасыннан челтерәп агып ятса, икенчесе Айдар янынан узып китүче сәфәрчеләрнең сусавын баса. Шулай итеп, авылның матурлыгына соклана-соклана, безне көтеп торучы йорт янына килеп тә туктадык. Җир җиләге кайнатмасын бүген безнең өчен Хаҗиевлар гаиләсе әзерләячәк. «Гаиләләре белән әзерләмәгәннәрдер бит инде, ник хуҗабикәнең генә исемен атамаска?» дигән сорау килгән булырга мөмкин башыгызга. Юкка гына әйтмим, чынлап та гаилә белән әзерләдек!

Җиләк җыю яшь кызлар эше буларак күңелгә кереп калган. Шуңа да: «Кызыгыз Гөлфинә җиләк җыярга ятарамы соң? Иптәш кызлары белән җиләккә йөриләрме?» – дип сорамый кала алмадым. Минем соравыма Вафирә әби җавап бирергә булды: «Әй, кызым, бу елны кара елан күп диләр шул, шуңа да җиләккә үзләре генә йөрергә куркалар бит...»

Фото: Айсылу Хаҗиева

PRESSA.RU

Кερә-керешкә, өстәлгә игътибар иттем, җир җиләгеннән ясалган кайнатмалар инде күренә: «Җиләк эшен чынлап та яраталар икән» дип, эчемнән генә үземә искәртеп тә куйдым. Мин блокнотымны алырга да өлгермәдем, Руфия ханым инде кайнатма рецептын диктант яздырган кебек әйтеп яздыра да башлады.

Төгәлрәге, Руфия ханым аш бүлмәсендә кайнады, ә менә күрше бүлмәдән Рәшит абый белән ак яулыклы Вафирә әбинең киңәшләре, җиләк темасына кагылышлы әңгәмәләре ишетелеп торды.

Кερә-керешкә, өстәлгә игътибар иттем, җир җиләгеннән ясалган кайнатмалар инде күренә: «Җиләк эшен чынлап та яраталар икән» дип, эчемнән генә үземә искәртеп тә куйдым. Мин блокнотымны алырга да өлгермәдем, Руфия ханым инде кайнатма рецептын диктант яздырган кебек әйтеп яздыра да башлады.

КАЙНАТУ ТҮГЕЛ, ҖЫЮ РӘХӘТ

Бүгенге көндә җиләкне блендерда әйләндереп, шикәр кушып кына куючылар да (монысы «заманча» вариант) һәм озак-озаклап плитәдә кайнатучылар да (ягъни «консерваторлар» да) очрый. Ләкин без өченче вариантны күз уңаеннан ычкындырганбыз икән бит әле! Җиләкләтә генә суыткычта саклаучыларны күләгәдә калдырганбыз лабаса! Руфия ханым бик тә уңган хуҗабикә булганга күрәдер, бу өйдә җәен-кышын җиләккә (шулай ук башка төр җимешләргә дә) аптырамыйлар. Киштәләрдә слива компотлары, чия кайнатмалары да тезелешеп тора. Ни өчен дигәндә, гаилә ишле һәм һәрбер кешенең теләгән истә тотып эш итәргә кирәк. Мәсәлән, олы уллары Рушан слива компотын ярата, кайнатмаларга исе китми икән, төпчек кызлары Гөлфинә җир җиләген үз итә, гаилә башлыгы Рәшит абыйга чәй янына чия кайнатмалары кирәк, ди, иң җайлы кеше уртанчы уллары Рифат дип аңладык. Ул барлык тәмле әйберне дә үз итә, диделәр.

Хуҗабикәнең үзенә килгәндә, ул виктория җиләгеннән ясалган кайнатмаларны өстен күрә, ләкин бу җиләк бакчаларында нигәдер үсеп китә алмый икән. «Ашарлык кына шул», – дип елмая Руфия ханым. Ул арада яныбызга Рәшит абый чыгып, куакларны, җиләкне ничек карарга кирәклеге турында сөйли башлады... Бакчачылык темасына багышланган кечкенә генә дәресне тыңлап бетергәннән соң, Руфия апага мөрәҗәгать иттем: «Җиләкне җыярга яратасызмы, әллә кайнатыргамы?» Сез бит инде беләсез, бу минем – авырткан темам. «Әлбәттә җыярга! Кияүгә чыкканчы да, кызлар белән җиләккә барырга ярата идем. Әни аларны кайната торган иде. Хәзер инде мин җыям, ә кызым – кайната...»

Шунысы кызык: вакыт узса, заманалар үзгәрсә дә, җиләк кайнату рецепты үзгәрешсез калган. Ләкин бу хакта бераз соңрак сөйләрбез.

МОНДА ҖИЛӘК КҮП ИКӘН, АЮ-БҮРЕ ЮК ИКӘН...

Җиләк җыю яшь кызлар эше буларак күңелгә кереп калган. Шуңа да: «Кызыгыз Гөлфинә җиләк җыярга яратамы соң? Иптәш кызлары белән җиләккә йөриләрме?» – дип сорамый кала алмадым. Минем соравыма Вафирә әби җавап бирергә булды: «Әй, кызым, бу елны кара елан күп диләр шул, шуңа да җиләккә үзләре генә йөрергә куркалар бит...»

Авыл җирендә бер бәлане икенчесе алыштырып кына тора инде. Шатланып, куанып каз-үрдәк үстергән вакытта төлке килеп чыгып, малларны харап итсә, җиләкле җәйнең ямен еланнар җибәрә. Рәшит абый әнисенең сүзен эләктереп алды да, елан турында да сөйләп аңлатты, борчулары белән дә бүлеште: «Элек авыл халкы яратып сарык-бәрәннәр асрый иде бит. Хәзер генә барсы да сәламәт яшәү рәвеше алып бара башлады. Имеш, сарык ите кан басымына килешми, гипертония чире белән авыручыларга әлеге итне ашарга ярамый икән, диләр. Аннары, сарык тиресен җыючылар да бетте. Эшкәртүчесе булмагач, бозыла бит алар. Шулай итеп, сарыкларны асраудан туктадылар да инде. Ә сарык көтүләре булмагач, еланнар күбәйде. Тузбашка, мәсәлән, мал исе ярамый, ди, үзенә күрә куркыту чарасы да, агу да булып торган ул ис аның өчен. Хәзер рәхәтләнеп үрчиләр инде...» Шунысын да әйтергә кирәк: Хаҗиевләр гаиләсе малны күп асрый. Утар тутырып сарык асрыйлар.

Ярый, җиләккә әйләнеп кайтыйк. Айдарлылар җир җиләгенә Субаш авылы елгасына баралар икән, ә кура җиләккә – Үрнәккә. Үрнәк дигәне элек авыл булган, вакыт узган, авыл таралган, ә ташландык бакчаларда котырып-котырып кура җиләге үсә башлаган. Кура белән сыйланырга теләүчеләр барысы да шушы «урман»га йөриләр, ди. Шунысы кызык: җиләк җыярга урыннары күп, җыярга да яраталар, ләкин авылларында беркем дә җиләк сату эше белән шөгыльләнми. Халык бары тик үзе өчен генә җыя. «Ни өчен шулай соң?» – дигән соравыма, авылыбыз М 7 трассасыннан читтәрәк урнашкан, ә сатарга шәһәргә кадәр барып йөрү уңайсыз, дип җавап бирделәр алар.

ФАЙДАСЫ КҮП, БЕЛЕГЕЗ!

Уңган хуҗабикәләр нинди генә җиләктән кайнатма әзерләми. Минем бер танышым фейхоа җиләге кайнатамалары белән якыннарын шатландырырга ярата. Шулкадәр күп җиләк төре арасыннан кайсысын сайлап алырга соң? Әйдәгез, җиләкләрнең рейтингын төзик әле.

Виктория җиләге.

Әлеге җиләкне яратып ашаучылар мәңге яшь булып саклана икән. Чынлап! Тәннәре җыерчыкларга, пигментацияләргә дә бирешми, ди. Виктория организмны антиоксидантларга баета, тән тиресенең матурлыгын саклый торган коллаген матдәсенең юкка чыгуына юл куймый икән. Шулай ук, виктория җиләген яратып ашаучылар йөрәк-кан тамырлары системасы авыруларына бирешми. Ишемия, гипертония ише сүзләрне аларга ишетергә дә туры килми икән.

1

2

Чия.

Бу хуш исле җиләк составында яман шешкә каршы көрәшүче матдәләр бар, диләр. Шулай ук чия ялкынсынуны баса, кандагы шикәрне «көйли». Чия составында антоциан һәм биофлавоноидлар бар икән. Болары исә артрит һәм баш авыртуларына каршы көрәшә.

Кура җиләге.

Мунчадан чыгып, кура җиләге кайнатмасы белән чәй эчәргә яратмаучылар бармы икән? Булырга тиеш тә түгел! Чөнки кура белән дус булырга кирәк. Әлеге җиләк пектин, клетчаткага бай. Димәк, ябыгырга теләүчеләрнең иң зур ярдәмчесе. Ашкайнату системасын көйли, начар холестеринны организмнан чыгаруда булышлык итә.

3

4

Карлыган.

Бу җиләк безнең рейтингыбызның җиңүчесе. Чөнки алда санап үтелгән бар сыйфатларны да карлыганда табарга була. Моңа өстәп, ул күзнең күрүен нормага китерә, хәтерне яхшырта һәм тән тиресе авыруларын дәвалый.

Дәва, файда турында сөйләшәбез икән, шунысын да әйтергә кирәк: Хаҗиевлар гаиләсе хәтта җир җиләгенең чүбен дә ташламый. Киптереп, чәй итеп эчәләр. Кыш көннәрендә, салкын тигәнне сизүгә үк, Руфия ханым якыннары өчен шушы хуш исле чәйне кайната. Җир җиләгендә иммунитетны ныгыта торган матдәләр күп, дару эчәргә тотынганчы, шулай дәваланалар. Сүз уңаеннан, иммунитет нык булсын өчен, һәр кешегә елына 250 г җир җиләге ашарга кирәк, ди белгечләр.

ЧИЛӘГЕНӘ КҮРӘ – КАПКАЧЫ, ҖИЛӘГЕНӘ КҮРӘ – БАНКАСЫ

Кайнатмаларны әзерләргә алынганчы, берничә этапны үтәргә кирәк:

1. Банкаларны пастеризацияләргә.
2. Капкачларны кайнатырга.

Безнең очракта Руфия ханым банкаларны кайнап торган чәйнек авызына гына куеп алды. Пар банканың һәр «почмагына» үтеп, бактерияләрне юк итә. Кайнатманы бары тик стериль банкаларга гына тутырабыз.

Капкачларга килгәндә, ике төрле вариант бар. Беренчесе: капкачларны кайнатабыз. Моның өчен табакка су салабыз, газ плитәсенә куябыз. Шунда ук табага капкачларны чумдырабыз. Су белән бергә капкачларыбыз да кайный. Икенчесе: яңа кайнап чыккан су белән капкачларны йөгертеп кенә алабыз. Мондый ысул блендр ярдәмендә ясалган кайнатмалар өчен яхшы.

Җиләкләрне җыйдык, банка-капкачларның хәстәрен күрдек, инде рецептларга күчик.

РУФИЯ ХАҖИЕВА РЕЦЕПТЛАРЫ:

Беренче рецепт
(газ плитәсендә әзерләү өчен)

Җир җиләге (чистартылган) – 3 кг
Шикәр – 3 кг

Иң элек зур савытка 3 кг җиләгебезне салабыз, аңа 1 кг шикәр комы кушып, 5-6 сәгатькә алып куябыз. Шулай эшләгән вакытта җиләкләрдән сок бүленеп чыга.

Кайнатма кайнату өчен әзерләнгән савытыбызны алып (безнең очракта – эмаль табак), калган 2 кг шикәр комын салабыз да җиләкләрдән бүленеп чыккан сокны өстибез. Табагыбызны газ плитәсенә утыртабыз. Сүрән утка куеп, шикәрнең тулысынча эреп беткәнен көтәбез. Өченче этапта җиләкләрне кушабыз. Барысын бергә тагын 30 минут чамасы кайнатабыз. Кайнатманы кайнар килеш әзер банкаларга тутырабыз.

Икенче рецепт
(блендерда әзерләү өчен)

Җир җиләге (чистартылмаган) – 3кг
Шикәр – 4 кг

Җиләкне иттарткычта яисә блендерда изәбез, аннары аңа 4 кг шикәр комы өстибез. Шикәр төпкә утырмасын өчен, һәрдаим болгатып тору зарур. Әзер кайнатманы шулай ук банкаларга салырга кирәк.

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ РЕЦЕПТЫ:

Җир җиләге (чистартылган) – 1кг
Шикәр – 1кг
Су – 1 стакан

Кагыйдә буларак, кайнатма әзерләү шикәр сиробы ясаудан башлана. Шикәргә су салып, эреп беткәнче кайнатырга. Сироп чиста һәм үтә күренмәле булырга тиеш. Соңрак җиләкләрне сиропка әз-әзләп тиз салырга кирәк. Җиләкләрне салып бетергәч, савытны ут өстеннән алып, җиләкләр сиропка батсын һәм бөтен савытка таралсын өчен селкеткәләргә һәм кабаттан ут өстенә куярга кирәк. 10-15 минуттан соң кайнатма өстенә күбек чыга башлый, аны сак кына тишекле чүмеч белән җыеп торырга кирәк. Күбек чыкмый башлагач, кайнатма әзер санала.

Чәйләрегез тәмле булсын!

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА
ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАННЫ»
УКЫ!

WWW.PROTATARSTAN.RU

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Борынгы тәңкәләр **НӘРСӘ** турында сөйли

Быелгы федераль Сабантуйга **НИНДИ** бәя куелды

Профессиональ композиторлар **КҮПМЕ** калган

Китаплар **КАЯ** сәяхәткә алып китә

Палеозой эрасына **КАЙСЫ** авыл аша барасы

PRESSA.RU

БОРЫНГЫ АКЧАЛАР НИ СӨЙЛИ?

Тарих фәненең археология, этнография, эпиграфика, геральдика, сфрагистика кебек ярдәмче тармаклары янәшәсенә нумизматика дип атала торган тагын бер искиткеч кызык һәм үзенчәлекле тармакны куярга була. Нумизматика – металл акчалар тарихы турындагы фән (кәгазь акчаларны бонистика өйрәнә). Күбесенчә очраклы рәвештә табыла торган акча хәзинәләре һәм археологик казулар вакытында килеп чыккан акчалар нумизмат галимнәрнең өйрәнү объекты булып торалар.

Автор:
Алексей Бугарчёв

АКЧА СУГУ – ДӘҮЛӘТЧЕЛЕКНЕҢ МӨҺИМ БЕР БИЛГЕСЕ

Нумизматика фәне борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүдә искиткеч зур роль уйный. Акча-товар мөнәсәбәтләрен өйрәнмичә торып, икътисадның (беренче чиратта эчке һәм тышкы сәүдәнең) үсеш дәрәҗәсен күз алдына да китереп булмый. Акча һәм сәясәт тә бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр. Акча сугу – дәүләтчелекнең мөһим бер билгесе. Антик чорда һәм урта гасырларда хакимлек иткән күп кенә идарәчеләрнең (корольләрнең, ханнарның, хәтта императорларның) исемнәре язма документларда түгел, нәкъ менә алтын, көмеш, бакыр тәңкәләрдә теркәлеп калган. Акчалары сакланып калмаган булса, без хәтта Алтын Урда ханнарының да тулы исемлеген төзи һәм аларның идарә иткән вакытларын ачыклый алмас идек.

Акча табылдыкларын археологлар да көтеп кенә тора. Культура катламын тәшкил иткән туфракны алар хәтта нечкә иләктән үткәреп иләп тә алалар, чөнки борынгы акчалар йорт һәм хуҗалык корылмаларының, каберлекләрнең һәм башка борынгы объектларның төгәл датасын бирә. Ә дөрес дата – тарих фәненең нигезе.

Безнең якларда табылган иң борынгы акчалар антик чорга карыйлар. Рим императорлары чыгарган акчалар, сирәк кенә булса да, Идел белән Урал арасында яшәгән халыкларның археологик истәлекләрендә очрый. Шундый акчаларның берсе Болгар музеенда саклана. Имәнкискә кабиләләре калдырган бер шәһәрлектә – ул хәзерге Балык Бистәсе районының Троицкий Урай авылы янында казып тикшерелгән иде – Сасанид патшалары Пероз (457–483) һәм Кавадның (488–497) көмеш акчалары табылды. Византия императорлары суккан акчаларның да әле VII гасырда ук Кама буйларына кадәр таралган булуы мәгълүм. Византия солидлары (алтын акчалары) Бөек Болгар дәүләте идарәчесе Кубрат ханның Полтава өлкәсе Перещепино авылы янында ачылган каберлегендә дә бар. IX гасырда әйләнешкә кергән Саманид дирһәмнәре исә Урта Иделдә генә түгел, бөтен Европада киң тарала. Идел Болгарының беренче ханы Алмыш та (мөселманча исеме – Җәгъфәр Ибн Абдаллаһ) 902–908 елларда нәкъ менә шул дирһәмнәрне өлге итеп алып, үзенең акчаларын чыгара башлый.

Болгар акчалары арасында Җәгъфәр Ибн Абдаллаһның улы Микаил исеме белән сугылган акчалар күбрәк очрый. Аннан соңгы акчалар Абдаллаһ Ибн Микаил, Талиб ибн Әхмәт (Суварда сугылган), Мөэмин Ибн Әхмәт, Мөэмин Ибн Хәсән хакимлек иткән чорда чыгарылганнар.

X гасыр азагында Болгарда һәм Суварда акча сугу эше туктатылып кала. Шәрык илләреннән керә торган дирһәмнәр дә XI гасыр башларында юкка чыга. Хәер, бу күренеш Идел Болгары өчен генә хас түгел. Акча чыгару эше Европа илләренең күбесендә тукталып кала. Сәбәбе бер: акча сугучы илләрдә җир астында яткан көмеш чыганакларының ярлылануы. Яңа рудниклар ачылганга кадәр озак кына вакытлар үтә. Көмеш кризисы XIII йөз башларына кадәр дәвам итәчәк әле.

ТАРИХИ ВАКЫЙГАЛАР ШАУКЫМЫ

1242 елның язында җиңелү белмәс Бату хан армиясе Көнбатыш Европадагы һөҗүмнәрен кинәт туктатып, яңадан көнчыгышка, Түбән Идел буйларына йөз тотып чигенә башлыйлар. Моның җитди сәбәбе була, әлбәттә: 1241 елның декабрендә Монголия империясенең бөек ханы Үгэдэй каан үлеп китә. Аның уллары һәм якын туганнары, ыруг-кабилә башлыклары яңа хан сайлап кую максаты белән Каракорымга – империя башкаласына ашыгалар. Бату хан корылтайга барудан баш тарта. Чөнки белеп тора: бөек хан (каан) итеп барыбер Гуюкны – Батуның көндәшен сайлап куячаклар.

Бату бик акыллы эш йөртә, Каракорымга кайтып бушка вакыт үткәргәнче, биредә, Идел буе далаларында, төпләнеп калырга була. Хуш, аның кул астындагы җирләрнең исәбе-хисабы юк – Себердән башлап Дунай ярларына кадәр. Атасы Җучи хан мирас итеп калдырган шул олыста ул – Чыңгыз хан оныгы – тыныч кына мөстәкыйль идарәче булып та яши ала ич! Әнә, яңа хан булып сайланган Гуюк та әлеге җирләрне Җучи олысы буларак таныды һәм Батуны биредә тулы хокуклы идарәче итеп раслады.

Күңеленә хуш килгән, кайсыдыр яклары белән туган җирләрен хәтерләтеп торган Түбән Идел далаларында башкала сыйфатында яңа шәһәр төзүгә керешкәнче, Бату үзенең станын – резиденциясен вакытлыча Болгарда урнаштырырга карар кыла. Биредә ул ныклап мөстәкыйль дәүләт төзү эшенә тотына. Нидән башларга? Әйе, беренче чиратта акча сугу эшен яңадан торгызырга кирәк. Нәкъ менә Болгар җирлегендә! Ни өчен дигәндә, Болгар – күптән танылган сәүдә үзәге генә түгел, кайчандыр акча сугу үзәге дә булган, 1236 елгы сугышлардан соң тормыш та ярыйсы гына тернәкләнеп килә.

1230нчы еллар азагында һәм 1240нчы еллар башында Болгарда бакыр акчалар сугу эше җайга салына. Авырлыклары – 4-8 грамм чамасы. Алгы ягында 1180–1225 елларда хакимлек иткән һәм мөселман дөньясында бик абруйлы саналган Багдад хәлифәсе Насир лид-Диннең исеме һәм титулы күрсәтелгән: «Хак динлеләрнең хакиме» («Повелитель правоверных»). Тәңкәнең икенче ягында: «Тормыш – мизгел, аны изге эшкә куллан» («Жизнь есть час, употребляй ее на богоугодные дела») дигән тәгъбир урнаштырылган. Кызганыч, сугылган елы күрсәтелмәгән, шуңа күрә дә Насир лид-Дин акчаларының чыгарыла башлау вакытына караган проблема нумизматика фәнендә әле һаман да ахырынача хәл ителмәгән килеш кала бирә. Кайбер галимнәр, ул акчалар Насир лид-Дин әле үзе исән чакта ук, ягъни 1225 елга кадәр сугылган, дип уйлыйлар, икенчеләре исә аларны Бату ханга һәм 1258–1266 елларда идарә иткән Бәркә ханга нисбәтле итеп карыйлар. Соңгылары хаклыдыр, дип уйлыйбыз, чөнки Насир лид-Дин хәлифәнең исеме монголлар явыннан соң Бохарада, Сәмаркандта, Отрарда, Алмалыкта һәм башка Урта Азия һәм Казахстан шәһәрләрендә, башлыча 1220–1260нчы еллар аралыгында сугылган акчаларда очрый.

1240нчы еллар башында Болгарда авырлыклары 2 граммнан артмаган көмеш акчалар да суга башлыйлар. Тәңкәләрнең алгы ягында «Хак динлеләрнең хакиме Насир лид-Дин» дип язылган, арткы ягына исә «Динар, Болгар казнасы суккан» (Динар, чекан казны Булгарской») дигән сүзләр бастырылган. Бераздан әлеге легенда яңасы белән алмаштырыла: «Динар, Болгарда сугылган» («Динар, чекан Болгара»).

Бакыр акчалар элеккечә «Тормыш – мизгел, аны изге эшкә куллан» тәгъбире белән сугылалар, әмма аларның авырлыгы 4 граммнан артмый инде. Тәңкәләрнең арткы ягында «Динар, Болгарда сугылган» дигән легенда. Күрәсең,

PRESSA.RU

Насир лид-Дин исеменнән сугылган Болгар бакыр тәңкәсе, «архаик» тип

Насир лид-Диннең көмеш динары

Насир лид-Диннең көмеш динары

Мункәнең бакыр тәңкәсе

Мәңге Тимер исеменнән сугылган көмеш тәңкә, Кырымда сугылган

бакыр тәңкәләр дә, көмешләре дә бер үк штемпель белән сугылганнар.

МУНКӘ КААН АКЧАЛАРЫ

Сәяси вакыйгалар гел үзгәреп тора. 1248 елның язында Монгол империясенең бөек ханы Гуюк вафат була. Каракорым тәхете өлкәнлек буенча Батуга күчәргә тиеш. «Син безнең патшабыз булырга тиеш, чөнки Чыңгыз нәселеннән берәү дә синнән өлкәнрәк түгел», – дип мөрәҗәгать итәләр аңа. Ләкин Бату Тулуйның улы Мункә файдасына каан тәхетеннән баш тарта: «Аны тәхеткә мин утырткач, чынлыкта хөкемдар мин булармын», – ди. 1251 елда үткән корылтайда Мункә каан итеп сайлана. Табигый ки, акча сугу эшендә дә үзгәрешләр килеп чыга.

Бату хан Болгар акчаларын Мункә каан исеменнән суктыра башлый. Көмеш тәңкәләрнең алгы ягына кааның иseме, арткы өслегенә «Болгарда сугылган» дигән сүзләр языла. Түгәрәкнең уртасына Мункәнең сәнәк рәвешендәге ыруг тамгасы урнаштырыла. Көмеш тәңкәләрнең авырлыгы башта 1,07-1,15 грамм булып, соңрак ул 0,7 граммга кадәр кими.

Мункә исеменнән сугылган бакыр акчалар үзләренең «кыяфәтләре» белән көмеш тәңкәләрдән аерылып тормый, әмма аларның бер үзенчәлеге, «кызык» ягы бар: Насир лид-Дин иseме белән сугылган элеккеге бакыр тәңкәләрнең өслегенә яңа штемпель сукканнар – килеп чыккан Мункә акчалары. Алтын Урда нумизматикасында танылган белгеч, Болгар дәүләт тыюлыгында саклана торган меңнәрчә борынгы акчаларны кулыннан үткәргән тәҗрибәле галим Җәмил ага Мөхәммәтшинның әйтүенә караганда, «Насир лид-Диннеке» булмаган, чиста бакыр түгәрәкләргә сугылган Мункә акчалары гадәттән тыш сирәк очрыйлар. Шунысын да әйтеп үтик: бу вакытта әле Насир лид-Дин акчалары да әйләнештән чыкмаган була. Табигый ки, аларның икесенең дә авырлыклары бертөрле – 1-3 грамм чамасы.

БАТУ ХАННАН СОҢ...

Сәясәттә тагын үзгәрешләр килеп чыга. 1256 елда Бату хан фани дөньядан мәңгелеккә күчә. Җүчи олысында хакимияткә Батуның улы Сартак килергә тиеш була. Ләкин ул Монголиядән, тәхеткә Мункә ханның ризалыгын алып кайткан җиреннән, юлда үлеп кала. Сартакның улы Улагчы да ничектер сәер үлем белән котелмәгәндә дөнья куя. Тәхеткә Бату ханның бертуган энесе Бәркә утыртыла.

1259 елда Мункә хан да вафат була. Тәхет варисы буларак каан тәхетенә Мункәнең бертуган энесе Арыг-Буга тәгаенләнә. Әмма тәхеткә Мункәнең тагын бер энесе дәгъва кыла. Ул, Хубилай, бу вакытта үзенең армиясе белән Кытайда була. 1260 елның июнендә Хубилай үзе яклыларның корылтаен җыя, һәм аны каан дип игълан итәләр. Империядә ике хакимият барлыкка килә һәм алар арасында җитди көрәш башлана. Үзенең армиясенә таянып, Хубилай Арыг-Буганы тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр итә. Арыг-Буга кечкенә бер провинциядә хәрбиләрнең даими күзәтүе астында яши. 1266 елда үлә.

Монголиядән ерак урнашкан Җүчи олысында хакимиятне законсыз рәвештә үз кулына алган Хубилай-узурпаторны танымыйлар. Бәркә берсүзсез Арыг-Буганы законлы каан дип кабул итә һәм аның исеме сугылган көмеш акчалар чыгара башлый. Аларның алгы ягына «Арыг Буга / бөек каан», икенче ягына «Болгарда сугылган» дип язылган һәм түгәрәк уртасына хакимнең тамгасы төшерелгән. Арыг-Буганың Хубилай белән тәхет өчен дүрт-биш ел буена тарткалашуы дәверендә Болгарда мондый

Насир лид-Диннең көмеш динары

Мәңге Тимер вакытындагы кайда сугылганлыгы билгесез көмеш тәңкә

Арыг-Буганың көмеш тәңкәсе

Мәңге Тимер вакытындагы билгесез көмеш дирһәм, Биләрдә сугылган

Мәңге Тимер вакытындагы билгесез дирһәм, Кирмәндә сугылган

акчалар күп чыгарыла. Шул дәвер эчендә аларның авырлыгы 0,80 граммнан 0,50 граммга кадәр төшә. Арыг-Буга акчаларыннан торган хәзинәләрдәге тәңкәләр саны 300, 500, хәтта 800 данә тәшкил итә. Еш кына ул акчалардагы язулар начар сугылган, легендалар кайвакыт тулы да түгел, бөтенләй буш (язусыз) түгәрәкләр дә очрый.

Арыг-Буга исеме белән сугылган бакыр акчалар юк, әмма элегрәк Насир лид-Дин һәм Мункә исеме белән чыгарылган тәңкәләр әле һаман әйләнештә йөргән.

МӘҢГЕ ТИМЕР ТАМГАСЫ

1266 елны бөтен Монгол дәүләте өчен кискен борылыш елы дип санарга була. Монголиядә почетлы әсирлектә – Арыг-Буга, Җүчи Олысында исә Бәркә хан вафат булалар. Җүчи нәселеннән булган идарәчеләр белән Тулуйныкылар (Мункә, Арыг-Буга һәм Хубилай шул нәселдән) арасында мөнәсәбәтләр ахыргача бозыла. Җүчи Олысының Бәркәдән соңгы ханы Мәңге Тимер (1266-1282) үзәкләштерелгән Монголия империясе хакимиятенә буйсынудан баш тарта. Олысның төрле өлкәләрендә сугыла башлаган тәңкәләрдә яңа тамга – Мәңге Тимер тамгасы пәйда була (кайвакыт аны ялгышып Бату хан тамгасы дип атыйлар). Кырымда, мәсәлән, өслегенә «Мәңге Тимер хан» һәм «Кырымда сугылган» дип язылган көмеш ярмаклар (вак акча мәгънәсендә) чыгарыла. Анда акчаның чыгарылган елы да күрсәтелгән – 665 (хәзерге календарьга күчерсәң, 1266 елның 2 октябреннән 1267 елның 21 сентябренә кадәр вакытка туры килә) һәм уртага Мәңге Тимернең тамгасы куелган. Хәрәзм акчаларында да шулай: акчаның чыгарылган урыны – Хәрәзм, елы – 665/1266–1267 һәм Мәңге Тимер тамгасы.

Болгар тәңкәләренә Мәңге Тимернең ыруг тамгасы гына төшерелгән һәм сугылган урыны күрсәтелгән. Мондый акчалар Болгарда гына түгел, Биләрдә һәм Кирмәндә дә чыгарыла башлаган.

Мәңге Тимер акчалары – Җүчи Олысының Монгол империясеннән аерылып, яңа, мөстәкыйль дәүләт барлыкка килүен раслаучы бик әһәмиятле тарихи чыганак. Әлеге дәүләтнең оешу тарихын өйрәнгәндә нумизматика материалларына таяну мөһим, чөнки язма чыганакларда бу тема җитәрлек дәрәҗәдә киң яктыртылмаган.

Элгәреге Җүчи акчаларын тикшереп алынган мәгълүматлар күрсәткәнчә, Бату ханның 1242 елда көнбатыш яуларын тәгәлләп, Идел буена килеп төпләнүе әле һич тә яңа дәүләт барлыкка килүен аңлатмый. Җүчи Олысы башкаласы Каракорымда урнашкан бердәм Монгол имприясенең тик бер өлкәсе генә була. Бату һаман да империянең баш ханына бәйле булып кала бирә, аның вассалы санала. Буйсындырылган халыклардан җыеп алынган салымнар да турыдан-туры Каракорымга озатылган, бакыр һәм көмеш тәңкәләргә бөек ханның исеме сугылган. Әмма Бату максатчан рәвештә Каракорымнан бәйсез, мөстәкыйль дәүләт кору юлыннан барган. Алтын Урданың яңа ханы Бәркә бәйсезлек юлында зур адым ясый. Ул Монгол империясе кааны исеменнән акча сугуны туктата, әммә тәңкәләргә үз исемен куярга батырчылык итми әле.

Бату һәм Бәркә ханнарның сәясәтен дәвам итеп, Мәңге Тимер, ниһаять, үз исеменнән акча суга башлый. Бер үк вакытта таркалып баручы империя башкаласына салымнар җибәрүне дә туктата. Бу исә инде Җүчи Олысының мөстәкыйль дәүләткә әверелеп китүен аңлаткан

P.S.:
Нумизматика чыганаклары буенча соңрак Алтын Урда исеме белән аталган Җүчи Олысы дәүләтенең оешып бетүе 1266–1267 елларга карый, дидек. Димәк, тарихыбыздагы бу мөһим вакыйга моннан 750 ел элек булган. Гыйльми даирәләрдә бу датага игътибар итмичә калмаслар, шәт.

PRESSA.RU

Фото: Линар Закиров

ТӘКӘСЕЗ САБАНТУЙ

Автор:
Линар Закиров

Нижгар якларына барып, милләттәшләребез белән күптәннән аралашасым килде. Быел андый форсат туды – Түбән Новгородта икенче тапкыр федераль Сабантуй узды. Баруын канатланып барсам, кайтканда исә андый хисләр кичермәдем.

«ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ БӘЙРӘМНЕ САБАН ТУЕ ДИП АТЫЙЛАР»

Федераль бәйрәм кунаклары ачылу тантанасында 200 килограммлы чәкчәктән авыз итте. Милли тәм-том Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Валерий Шанцевның да күңеленә хуш килгәндер.

– Исәнмесез кадерле, дуслар! – дип, ул зур стадионга җыелган халыкны үзебезчә – татарча сәламләде. Корылма зур булса да, килгән кешесе бик аз, берничә трибуна гына тулы иде. Югыйсә, Түбән Новгород өлкәсендә 50 меңгә якын милләттәшебез яши.

– Сабантуй – барыбыз өчен иң яраткан бәйрәмнәрнең берсе. Күп кенә милләтләр үзләре җыелган бәйрәмне «сабантуй» дип атый. Хәтта шулай дип әйтәләр дә: «Без сабантуйга барабыз». Татарлар Идел буе халыклары мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән. Шуны да истә тотарга кирәк: Россиянең күпмилләтле уникаль мәдәнияте күпчелек халыкларның мәдәниятләренә нигезләнеп төзелгән, – диде ул.

Валерий Шанцев башта татарның: «Бердәмлектә – көч» мәкален, ә аннары Түбән Новгородта туган атаклы шәхес – Кузьма Мининның 400 ел элек әйткән «Купно за едино!» сүзен телгә алып:

– Бердәмләшеп, уртак фикергә килеп кенә барлык проблемаларны

PRESSA.RU

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, быел Сабантуйлар дөньяның 27 илендә һәм илебезнең 57 төбәгендә гөрләп узды.

хәл итә һәм алга атлый алачакбыз, – диде.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, быел Сабантуйлар дөньяның 27 илендә һәм илебезнең 57 төбәгендә гөрләп узды. Аны бөтен җирдә түземсезләнеп көтәләр.

«КАЗАН МИҢА БЕЛОРУССИЯНЕ ХӘТЕРЛӘТТЕ»

Түбән Новгород Сабан туенда бәйрәмебезне яратучылар һәм аны мактаучылар күп очрады. «Джерело» украин мәдәнияте җәмгыяте әгъзасы Людмила Плева әйтүенчә, ул Сабантуйда татар мәдәнияте белән беренче мәртәбә генә таныша.

– Сабантуй, чын мәгънәсендә, гаилә бәйрәме, биредә синең нинди милләттән, кем булуыңа карамыйлар. Бөтен нәрсә аңлашыла. Татар бию коллективлары чыгыш ясаганда, үзем дә сизмәстән: «Бу бит безнең украин музыкасы!» – дип әйтеп куйдым да сәхнә артында бии башладым. Кул эшләнмәләре, балчыктан ясалган чүлмәкләр, ризыклар – болар барысы да безнеке, – диде Людмила Плева.

– Советлар Союзы чорының иң атаклы маршалы кем? – дип сорады миннән шул вакытта төшке ашны бергәләп ашаган ир-ат.



– Жуков, – дип ике да уйламыйча җавап бирдем.

– Дөрес! Ләкин ул Георгий, ә мин Юрий, – диде «Российский фонд мира» халыкара иҗтимагый оешмасының Түбән Новгород бүлеге рәисе урынбасары. – Казанда эш буенча еш булам. Көймә белән килеп туктыйсың, тел йотарлык пылавыгыз белән чәкчәктән авыз иткәч, рәхәт булып китә.

– Казан – искитмәле шәһәр, бөтен җирдә тәртип, чисталык ягыннан ул миңа Белоруссияне хәтерләтте, – дип күңелгә май булып ятарлык сүзләр әйтте белорус мәдәниятенең Түбән Новгород төбәк иҗтимагый оешмасының идарә рәисе. – Тарихи урыннар бик күп, аларны бөек кешеләребез идарә иткән чордан бирле ничек бар, шулай саклыйсыз. Былтыр диннәр храмында булырга насыйп булды. Анда Россия халыклары мәдәниятләренә багышланган күп кенә чаралар үткәргәннәр икән инде. Храмда бөтен нәрсәнең бушка эшләнүе әйбәт. Элемтә булдырып, озакламый Казан белән Түбән Новгород арасында телекүпер үткәрергә килештек. Татар халкына тарихи хәтерне саклаганы өчен чиксез рәхмәт.

«ЧЫН КӨРӘШ МОНДЫЙ БУЛМЫЙ!»

Ул арада егетләр келәмдә абсолют батыр исеме өчен бил алышты. Федераль Сабантуй җиңүчесенә, гадәттә, автомобиль һәм таза тәкә бирелә. Тимер ат бөтен кешенең күз алдында торса, тәкәсе күзгә чалынмады.

Келәм кызган вакытта без көрәшнең бөтен нечкәлекләрен белгән Раил Мараков белән сөйләшеп алдык. Ул 2014 елда Томскида узган Сабантуйда абсолют батыр булып, машинага ия булды. Томскига самолет белән барган булса, туган ягы – Теләчегә әр-яңа «тимер ат» иярләп кайтты. Быел уңыш 2014 елдагыча елмаймады – әңгәмәдәшем абсолют үлчәү категориясендә икенче урында калды.

Раил профессиональ көрәш белән 2003 елдан шөгыльләнә. 2013 елда Казан федераль университетының физик тәрбия институтын тәмамлаган. Тренеры Вакыйф Дәүләтшин кул астында ул биек үрләр яулаган. Күптән түгел Раилне Теләче районының Иске Җөри авыл җирлеге рәисе итеп билгеләгәннәр. Шулай итеп хәзер ул авылны чолгап алган проблемалар белән дә көрәшә.

Бабам да көрәшкән, ул авылның иң көчле кешеләренең берсе булган, диләр. Оста көрәшче булыр өчен көненә ике-өч тапкыр шөгыльләнергә кирәк. Ул вакытта күп кенә мавыгуларың, шул исәптән кызлар онытылып тора, – дип елмайды спортчы.

– Иске Җөридә көрәш белән кызыксыналармы?

– Бу юнәлештә башкарасы эшләр шактый. Идеяләр күп, ләкин аларны тормышка ашырырга вакыт җитми, – диде Раил, сорауларыма җавап биргән арада келәмнән күзен алмый гына. Анда Питрәч пәһлеваны Фәрхәт Фәйзуллин (авырлыгы – 130 килограмм) белән Түбән Новгород өлкәсе Бор шәһәре егете Рөстәм Садыйков (авырлыгы – 85 килограмм) бил алышты.

Хөкемдар яшел форма кигән Фәрхәт Фәйзуллинны җиңүче итеп таныгач, нижгарлылар ду килде, яңадан көрәштерүләрен сорады. Хөкемдарлар колак салды. Чираттагы бил алышудан соң Садыйков җиңүче итеп табылды.

– Кеше көлдермәгез, чын көрәш мондый булмый! – дип, трибунадагы халык гөж килә башлады.

Халыкара категориядәге хөкемдар Әнәс Хәлилов шушы вакыйга уңаеннан урында үз бәясен бирде.

– Түбән Новгород егетләре аяк чалып көрәшә, ә бездә бу катгый тыела. Минем фикеремчә, без аларны яңадан көрәштерергә тиеш. Сарыклар да исән калырга, бүре дә тук булырга тиеш. Бу ярышлар татар көрәшенең Россия спорт комитетында кабул ителгән таләпләре буенча уздырыла, ә Нижгар өлкәсендәге көрәш кагыйдәләре белән түгел, – диде ул.

Рөстәм Садыйков барыбер абсолют батыр булып калды. Аңа чит ил машинасы ачкычларын тапшырдылар. Ә җилкәсендә тәкәне күрү насыйп булмады...

Келәм батырларын бүләкләгәннән соң федераль Сабантуй билгесе – тулпар ат Әстерхан татарларына тапшырылды. Алар да милли бәйрәмебезне үзендә икенче тапкыр кабул итәчәк. Ат дигәннән, гадәттә, Сабан туенда ат чабышы үткәрелә, әмма оештыручылар бу юлы аны уздыруны кирәк дип тапмаган.

Кунаклар гына түгел, күрәсең, оештыручылар да милли бәйрәмне үткәрүдә хаталарын таныган. Ябылу тантанасында Түбән Новгород өлкәсе татарларының милли-мәдәни автономиясе башкарма директоры Рамил Салихҗанов та:

– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов узган ел Красноярскида узган Сабантуйның оештырылуына югарып бәя биреп, аны супер дип атады. Бездә дә шундый дәрәҗәдә булдымы-юкмы – әйтә алмыйм, Президент безнең Сабантуйны хупласа да, андый югары бәяне ишетмәдек. Киләсе елда Әстерхандагы Сабантуйның да супер итеп оештырылуын теләр идек, – диде.

Дөресен әйткәндә, без, Татарстаннан килгән бер төркем журналистлар, Түбән Новгородта Сабан туе рухын тоймадык. Аның каравы, Татарстанның теләсә кайсы авыл Сабан туенда диярлек рәхәтләнеп ял итеп, күңел ачарга була.

«ИДЕЛ БУЙЛАП СИБЕЛЕП ЯШИБЕЗ»

Бәлки, без, Казан татарлары, артык бәйләнчектер. Аның каравы, бәйрәмгә илнең 46 төбәгеннән җыелган кунаклар арасында бәйрәмне оша-тучылар да булды.

Илүзә апа Шәмсетдинова белән Сәет абый Хөсәеновка ерак йөрисе булмады, алар Сабантуй тамашасы гөрләгән парк тирәсендә генә яши. Илүзә апа 1936 елда туган, 1941 елда әтисен фронтка алып китканнәр. Әниләре өч бала белән калган. Кеч-кенә Илүзә Казанның 80нче мәктәбендә «биш»легә генә укыган. 10нчы класстан соң ул югары уку йортына керергә теләгән, әмма әнисенә берүзенә бөтен гаиләне күтәрергә авырга туры килә дип, Илүзә техникумга ке-реп, стипендия алып укыган.

– 1956 елда, укып бетергәннән соң, юллама буенча берничә шәһәрнең берсен сайларга куштылар. Әнием: «Кызым, Казанга якынрак шәһәрне кара инде», – дигәч, Горькийны (Түбән Новгородның элгәреге атамасы – авт.) сайладым. Кияүгә чыгып, калырга да булыр иде, әмма безнең туй үткәрергә түгел, ашарга һәм киярг дә бернәрсә булмады бит. Өч ел эшләрмен дә кайтырмын, дип уйладым. Язмыш башкача хәл итте. Горькийга киткәч, Казанны бик сагындым, бәйрәм саен кайтып тордым. Апам Әстерханда гомер кичерә, Идел буйлап сибелеп яшибез шулай, – дип сөйләде ул.

Илүзә апа 38 ел Түбән Новгород май комбинатында инженер-технолог, цех башлыгы булып эшләгән. 1958 елда кияүгә чыккан, аннан фатир алган. Ире дә комбинатта хезмәт куйган. 25 ел бергә гомер кичергәннән соң, ул йөрәк өянәгеннән вафат булган. Уллары Равил белән Рифат, оныклары Илүзә апага һәрчак ярдәм итеп торалар. Сәет абый белән алар инде уналтынчы ел бергә икән.

– Ничек таныштыгыз? – дип со-рыйм.

– Сәет тә комбинатта эшләде. Ирем үлгәч, эштәгеләр, уңган-булган егет бар, дип аны мактады. Сәетнең 50 ел бергә торган хатыны да ахирәттә инде.

– Тумышым белән Түбән Новгород өлкәсенең Бызлау авылыннан. Гаиләдә алты бала идек, – дип сөйләшүгә Сәет абый да кушылды. – Абыйларны сугышка алып киткәч, ике апам һәм әнием белән калдык. Ашыйсы килә, ягарга утын кирәк. Бодай бирмиләр, бөтен нәрсә фронтка китә. Кыш көне әни белән урманга салам урларга бардык. Ихатага өч йөз метр кала, колхоз председателе сакчы белән бергә килеп чыкты да саламга ут төртте. Әни белән елый-елый өйгә кереп киттек. Председатель акыллы кеше булса, бүтән алай эшләмәгез дип, безгә, ятимнәргә, саламны калдырган булыр иде.

Илүзә апа Казанда Каюм Насыйри урамында, Кабан күле буенда яшәгән. Берничә ел элек аның җәяүлеләр урамы итеп корылуын ишетеп, гаҗәпкә калган.

– Телевизордан урамга брусчатка салуларын күрсәттеләр. Бик матур булган, ачык һавадагы музей, дисәң дә була. Кызганыч, агач йортыбыз калмады шул инде.

– Илүзә апа, сезне, Казан татарын, нижгар татарлары ничек кабул итте?

– Аларны «цыкылдаучы» халык дип атыйлар. Казан татарлары «пычак», «почмак» дисә, нижгарлылар – «пыцак», «пыцмак», дип сөйләшә. Кайвакыт каенанам казанча сөйләшүемнән көлеп куя иде. Өйгә кайткач, абыем: «Чын нижгар мишәренә өйләнеп беткәнсең», – дип төрттерә иде. Нижгар татарлары эремчекле ватрушканы кәкәш, ди. Ирем аны әзерләргә сорагач, «Ни өчен тәмле әйберне шундый оятсыз сүз белән атыйлар?» – дип аптырадым. Түбән Новгородта бәрәңгене – картоп, ә кәбестәне щти, диләр. Җирле сөйләмгә тиз генә күнегә алмадым.

– Ә минем әнием прижинца әзерли иде, – дип, аш-су темасын Сәет абый да күтәреп алды. – Башта камыр баса, аны җәя һәм спираль рәвешендә ясап, мичкә куя иде. Аның тәмлелеген белсәгез!

«ШИК» ҺӘМ «КАДАК»: АЕРМА НӘРСӘДӘ?

Чираттагы әңгәмәдәшебез Сиринә Газизовна, Казан химия-технология институтын тәмамлап, юллама буенча Волградка китә. Ул да, өч ел эшләрмен дә кайтырмын, дип ниятли… Әти-әнисе Апас районыннан. Грузиядән кайткач, аларны Актанышка җибәрәләр, әңгәмәдәшебез шунда туа да инде.

– Ни өчен Волгоградны сайладыммы? Әтием Сталинград сугышында катнашып, исән-имин өйләнеп кайтты. Нинди шартларда көрәшкәне турында ник нык ыгытып сорашмадым икән, дип үкенәм. Әле ярый шул вакыйга хакында татарча-лы-русчалы язылган истәлекләре сакланып калды. Волгоградта 1971 елдан бирле яшим. Шунда кияүгә чыктым. Мәрхүм ирем – татар, мишәрчә сөйләшә иде, аның бабалары Пенза ягыннан, – дип сөйләде Сиринә Газизовна.

Волгоград татарларының да Казан татарлары өчен ят булып тоелган хикмәтле сүзләре җитәрлек. Сиринә ханым сөйләвенчә, бервакыт шулай ире бакчада кайнашканда, хатынының әнисеннән шик сораган. «Нәрсә соң ул?» – дип аптыраган ул. Баксаң, мишәрләр кадакны шик дип атый икән.

– Сүзлекне ачып карасак, анда ике төрле вариант та бар, – дип сөйләде әңгәмәдәшебез. – Татарстаннан аермалы буларак, Волгоградта бик яратып пәрәмәч пешерәләр. Ә менә кыстыбыйга исләре китми, аның нәрсә икәнлеген белмиләр дә диярлек.

– Сезнең якларда татар теленең хәле ничек?

– Гаиләдә әбиләр татарча сөйләшсә, оныклары, аларга әбикәюшка дип эндәшә, – дип елмая Сиринә ханым. – Атнага бер тапкыр татар теле укытыла торган якшәмбе мәктәбе эшли. Кызыксыну бар. Урта буын заманында туган телне өйрәнмәгән, ә хәзер, нинди югалту кичерүләрен аңлагач, оныкларын татар мәдәниятенә тартырга тырышалар.

Игорь Баринов, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе:

– Элек-электән, үтеп барган һәркем өйгә кереп һәм шатлыгы белән уртаклаша алсын өчен, хуҗалар ишекләрен бикләмәгән. Милли бәйрәмнәр дә киң итеп ачылган капкалар төсле безне гаҗәеп мәдәнияткә алып керә, халыкның рухи байлыгы һәм гореф-гадәтләре белән танышырга мөмкинлек бирә. Язгы чәчү эшләреннән соң үткәрелә торган бәйрәм күптән инде Россиянең генә түгел, бөтен дөнья мәдәниятенең аерылгысыз өлешенә әйләнде.

Михаил Бабич, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле:

– Сабан туе күп гасырлар дәвамында Идел буендагы милләтләрне һәм мәдәниятләрне бергә туплаган. Ул безне төрки халыклар мәдәнияте белән таныштыручы милләтара бәйрәмгә әйләнде. Сабан туе хезмәткә хөрмәт белән, үз җиренә һәм мәдәниятенә ихтирам белән карарга кирәклеген аңлата. Бүген ул татар, башкорт һәм башка милләтләрнең яшь буыннарына гореф-гадәтләрне аңларга һәм тоярга ярдәм итә.

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты:

– Сабантуй – безнең йолаларыбыз һәм гореф-гадәтләребез, туган-тумача, дуслар белән күрешү, башка халыкларга үзенчәлекләребезне күрсәтү мөмкинлеге. Бәйрәмнең нindidер өлешләре үзгәрергә тиештер, ә менә төп идеясен һич кенә дә үзгәртергә ярамый.

Автор фотолары

PRESSA.RU

«МИН СИНЕҢ БЕЛӘН АУГА ЧЫГАР ИДЕМ, ӘХИЯРОВА»

Балачагым да, тормышымның бөтен барышы-агышы да аның көй-аһәңнәре белән өретелгән: «Зәңгәр томан», «Зинһар өчен, кермә төшләремә», «Ак кәгазь», «Бергә узыйк Казан урамын», «Идел-йорт», «Сөембикә»... Нинди икән ул – күңеленнән мондый аһәңнәр түгелерлек зат, дип еш уйлый идем. Бик нечкәдер, бик хиследер, бик нәзберектер... Ә танышкач, тормышта ныгып килгән теориямә тагын бер кат инандым: иң нечкә-хисчән, эстетик кыйммәткә ия сәнгать әсәрләрен тудыручы талантлы шәхесләр, беренче чиратта, ныклы умырткага ия һәм гаҗәеп дәрәҗәдә эшчән кешеләр алар.

Әңгәмәне
Луиза Янсуар
алып барды

СИРӘК ТОВАР, ЯКИ ҖИДЕ ЯШЬЛЕК КОМПОЗИТОР

– Гаиләбездә музыкантлар, композиторлар юк иде. Башкортостаннан Казанга күченгәч, мине Совет районының 72нче номерлы немец телле мәктәбенә 1нче сыйныфка укырга бирделәр һәм – 7нче музыка мәктәбенә. Скрипка белән фортепианода уйный башладым. Фортепианоны бик ошаттым. Җиде яшемдә, миңа пианино алгач, уйный-уйный, музыка язарга керештем. Әле аны ничек язарга кирәклеген дә рәтләп белмим, әмма нәрсәдер «чыгарам». Әни махсус нота дәфтәре алды һәм мин көйләремне шунда терки башладым.

Музыка мәктәбендә 5-6нчы классларда Лоренц Блинов дигән композитор композиция дәресләре алып бара башлады. Без, көй чыгара торган берничә бала, аның дәресләренә йөрдек. Музыка мәктәбен скрипка буенча тәмамладым. Музыка училищесына укырга кердем дә теория факультетын тәмамладым, чөнки композиторлар өчен махсус бүлек юк иде. Аны бетергәч, консерваториягә инде нәкъ менә композиция буенча укырга кердем.

Дөрес, музыка училищесында укыганда, композициягә өйрәтер өчен, Мирсәет Яруллин килеп йөри иде. Минем өчен һәм Венера Җиһаншина дигән тагын бер кыз өчен. Ә консерваториядә теория һәм композиция факультетында Рафаэль Нуриевич Белялов классында укыдым. Инструментовка һәм оркестровка буенча – Нәҗип Гаязович Җиһановта.

Курста бердәнбер кыз бала идем. Ә курсны барлыгы бишәү тәмамладык. Бездә бит күп кеше укымый, без, кем әйтмешли, «сирәк товар». Минем белән укыган ир-егетләр, композиторлыкка укысалар да, композитор булмадылар. Аларның хәзер кайда икәнлекләрен дә белмим.

«ӘНКӘЙ БУЛМАСА, КОМПОЗИТОР БУЛМАС ИДЕМ»

– Әнкәй бик иҗади кеше иде, төрки телләрдә сөйләшүче балаларга рус телен тиз һәм сыйфатлы итеп өйрәтү буенча гаять күп дәреслекләр, методик кулланмалар авторы, филология фәннәре кандидаты. Татар телен әйбәт белсәң, кимендә, бер атна эчендә теләсә нинди тугандаш төрки телдә сөйләшә алачаксың, шуңа татарча белергә кирәк, дип тәрбияләде ул безне.

Әткәй исә әнкәйнең тоемлавына чын күңелдән ышана иде. Аның сүзенә колак сала, фикеренә таянып эш итә. Чөнки гаиләдә әнкәй – рухи лидер. Ә әткәй – икътисадчы, ТАССРның Госпланында Җыю бүлеге мөдире булып эшләде. Бер-берсенә зур терәк булып, аңлашып яшәделәр.

Сеңлем бар иде. Лилия исемле. Ни кызганыч, 36 яше туларга бер көн кала, йөрәк авыруыннан вафат булды. Бик чибәр, акыллы, укымышлы иде ул... Филология буенча кандидатлык диссертациясе якларга җыенып йөри иде... Ул чакта бит йөрәккә операцияләрне юньләп ясый да белмәгәннәр, хәзер булса, без аны коткара алган булыр идек, дип уйлыйм.

Талант ул һәр балага бирелгән була, әмма әти-әнисе тиешле вакытта дөрес юнәлеш бирмәсә, күмелеп калырга да мөмкин. Мине музыка мәктәбенә бирмәгән булсалар, композитор булырга мөмкин икәнлеген белмәс тә идем. Каян белим мин аны?! Тагын бер мөһим әйбер – ышаныч. Әнием миңа бик нык ышанды. Пианинода уйнавымны күргәч, талантым бар дип исәпләде һәм бу талантка һәрвакыт гаять җитди карады. Әйткәләгәннәр аңа: «Сезнең кызыгыз башкалардан бер җире белән дә аерылмый, ә сез аны әллә кемгә исәплисез», – дип. Әмма әнинең ышанычын кемнәрнеңдер сүзләре генә какшата алмый иде. Әнкәй булмаса, мин композитор булмас идем.

Шулай ук музыка мәктәбендә нинди укытучыга эләгүең дә зур роль уйный. Миңа бу яктан да язмыш елмайды – Алексей Васильевич Конюхов дигән укытучыда укый башладым мәктәптә. Скрипка буенча укытты. Мине бик үз итеп, яратып үстерде. Ә минем сеңлемә (ул фортепианога йөрде) җайсыз укытучы туры килде. 4 нче класстан соң: «Булды, җитте, башка йөрмим», – дип ташлады.

ӨЧ ОСТАЗ

– Өч мәтр. Өч шәхес. Һәрберсе үз йогынтысын ясамый калмады. Әмма кайсы күбрәк тәэсир иткәндер, анык кына әйтә дә алмыйм. Чагыштырып та булмый.

Мирсәет абый, иң беренче җырымны тыңлап, фатихасын биргән кеше. Хәтерлим, Ренат Харис янына бардым. «Яшь ленинчы» газетасында җаваплы секретарь булып эшләгән вакыты. Ул әле бик яшь, утызы да тулмаган иде. Равил Фәйзуллин сүзләренә язылган «Таң» дигән җырымны алып килдем. Ренат абый бит ул шагыйрь, белеме буенча – филолог, ә ул чакта, редакциянең үзендә утырмасалар да, махсус музыкаль белеме булган кешеләр газета-журналларда консультант булып эшлиләр иде. Һәм менә Ренат абый үзләрендәге консультантны, ягъни Мирсәет Яруллинны чакыртты. Мирсәет абый килде дә, җырны көйләп карап, бастырырга була, дип профессиональ бәясен бирде. Ул вакытта мода бар иде – җырларны, ноталары белән бергә, газета-журналларда бастыру.

Дуслык шуннан башланды. Концертларына йөри башладым. Гомумән, без гаиләбез белән татар

PRESSA.RU

урнәгә булмаса, мин берәр музыка мәктәбендә пианинода уйнарга өйрәтеп утыручы укытучы булып кына калыр идем. Әмма әни баштан ук алга зур максатлар һәм таләпләр куйды.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов композитор Резеда Әхиярова белән шагыйрь Ренат Харисқа «Шагыйрь мәхәббәте», «Алтын Урда» әсәрләрен иҗат итеп, татар опера һәм балет сәнгатенә керткән саллы өлешләре өчен мактаулы бүләк – «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшыра.

композиторларының симфоник концертларына еш йөри идек. Мирсәет абыйның әсәрләрен бик яраттым. Ул миңа музыка училищесына кергәндә дә бик нык ярдәм итте, әзерләде.

Займищеда «Журналист» дип аталучы бакча ширкәте бар иде. Әти белән әнинең шунда йорты урнашкан. Бакча күршеләребез – Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев. Илдар абый белән бик дус булгангадыр инде, аларга кунакка Мирсәет абый килеп йөри. Җырлар язалар, спектакльләргә музыка иҗат итәләр, мәш киләләр. Әткәй белән әнкәй Илдар абыйлар белән аралаша, билгеле инде, Мирсәет абый белән дә. Безгә дә кунака кереп чыккалыйлар бу даһилар. Шуңа да Мирсәет абыйны кечкенәдән якын итеп, ихтирам итеп үстем. Мине Композиторлар берлегенә кабул иткәндә, зур илтифат күрсәтте. 1989 елда Композиторлар берлегенең рәисе нәкъ менә ул иде.

Рафаэль Нуриевич белән консерваториягә керер алдыннан таныштым. Аның кул астында кыллы квартет яздым, романслар. Шуларны коллоквиумда – керү имтиханнарда – күрсәттем. Һәм биш ел дәвамында аның классында укыдым. Гаҗәеп талантлы, кызыклы композитор иде. Һәм энциклопедик белемле шәхес тә. Шагыйрьләр, язучыларның иҗатын һәрчак күзәтеп, өйрәнеп барды. Миңа да шул белемнәрне сеңдерде.

Нәҗип абый Җиһанов бары тик композиторларда гына инструментовка-оркестровка буенча дәресләр алып бара иде. Нәкъ менә шул дәресләргә йөргәндә, 3нче курста, мин бәби алып кайттым. Нәҗип абый, көмәнем барлыгын сизгәч: «Аңлашылды, димәк син академик отпускка китәчәксең тиздән», – дигән иде. Әмма әнкәй катгый әйтте: «Укуыңны дәвам итәсең, без сиңа булышырбыз». Иремнең әнисе дә шул фикердә торды.

Балам 25 декабрьдә туды, мин инде аңарчы барлык имтиханнарны тапшырган идем. Һәм бөтен төркем белән бергә икенче семестрга укырга чыктым. Нәҗип абый, мине күреп алды да: "Дааа, Әхиярова, мин синең белән аю ауларга барыр идем», – диде. Мин ул чакта «аюга бару»ның нәрсә икәнлеген дә белмим. Ә ул бик катлаулы эш икән – көчле ихтыяр, чыдамлылык, максатчанлык таләп итә торган. Хәзер горурланып искә алам.

«КОМПОЗИТОРША» ДИГӘН ТӨШЕНЧӘ ЮК»

– Тормышымда ир-ат музыкантлар, педагоглар, мэтрлар зур роль уйнады. Алар миңа һәрвакыт тигез итеп карады, бу, бәлки, холык-табигатем белән дә бәйле булгандыр. Мин дә үземне алар арасында хатын-кыз итеп, ягъни икенче планда булырга тиешле итеп тоймадым. Әлбәттә, хатын-кыз өчен нәзакать, наз, матурлык иясе булу – ул табигый нәрсә. Әмма профессиянең җенесе юк!

Композиторлар арасында хатын-кызлар бармак белән генә санарлык бит. Ул – конкрет ир-ат һөнәре. Минем табигатемдә ирләрчә тотрыклылык, ныклык бар. Җебеп төшмим. Нинди генә авыр хәл булмасын, үземне кулга алып, алга барам. Бу тәрбия гаиләдән килә – әнкәйдән. Ул бик максатчан, көчле шәхес кенә түгел, ә гаҗәеп оратор, лектор, эшендә гел лидер, башкаларга юл күрсәтүче дә иде бит. Мәскәүдә Милли телләр институтында эшләде, гел зур аудиторияләр алдында чыгыш ясый иде. Бәлки, аның

«БЕЗГӘ ҖЫР ЯЗАРГА ЯРАМЫЙ ИДЕ»

– Аннары аспирантурга кердем. Музыка белгече дә буласым килде. Диссертация яза башладым, әмма ташладым. Композиторлык күбрәк минеке булып чыкты. Аспирантура шуңа төшендерер өчен кирәк булган да, мөгаен.

Беренче җырларымны язып, берсеннән-берсе әйбәт җырчыларның аларны башкара башлаган чагы иде – Вафирә Гыйззәтуллина, Римма Ибраһимова, Айдар Фәйзрахманов, Асаф Вәлиев, Венера Ганиева. Алар радиодан даими яңгырый, халык яратып кабул итә – иҗади тормыш бөтереп алды мине үз эченә, гаҗәеп кызыклы тормыш. Ул җырчылар шулкадәр модада иде, концертларында халык залга сыймый. Алар бөтен Союз буйлап гастрольләрдә йөриләр... Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, Госман Садә, Ренат Харис... – минем иҗатташ шагыйрьләрем дә санап бетергесез. Консерваториядә укыганда болай булыр дип башыма да китермәгән идем. Анда бит куелган жанрлар, кысалар, академик атмосфера. Ул барыбер дә элитар сәнгать.

Консерваториядә укыганда безгә җыр язарга ярамый иде. Ул чакта Ленин белән бәйле даталар модада – әйтик, 22 апрельгә син, һичшиксез, нииндидер әсәр язарга тиешсең. Эстрада плебейлар жанры дип исәпләнә иде әле. Эстрада өчен язып, юньле композиторлар рәтендә йөри алмыйсың, янәсе. Әмма мин, бу стереотиплардан арындым да, күңелем ничек куша, шулай иҗат итә башладым. Академик жанрны ташлап, эстрадага гына күчмәдем – икесен дә тигез алып бардым. Тик халык мине нәкъ менә эстрада өчен язылган эшләрем аша күбрәк белә: «Зәңгәр томан», «Зинһар өчен, кермә төшләремә», "Туй күлмәге», «Чаба поезд», «Яратыгыз» һ.б. җырлар авторы мин аның өчен.

«МУЗЫКАМНЫ ЯРАТА ТОРГАН ИРЛӘРНЕ САЙЛАДЫМ»

Беренче җәмәгатем музыка белгече иде. Без аның белән әле музыка училищесында укыганда ук таныштык. Хәзер ул П.И. Чайковский исемендәге 1нче номерлы Музыка мәктәбе директоры. Яша белән 17 ел бергә яшәдек. Бергәләп кызым Алинаны тәрбияләп үстердек. Ике оныгыбыз бар. Ул мине аңлап, хөрмәт итеп яшәде. Әле хәзер дә концертларыма йөри,

һәр уңышыма сөенә, котлый. Еш кына әйтеп куя: «Мин синең беренче ирең булуым белән горурланам», – ди.

Без аның белән бик яшьли өйләнештек, әбиләрем, әти-әниләр татар милләтенннән булмавына пошынды да әле. Әмма бик культуралы кеше булуын күргәч, яраттылар. Алар гомер буена бер-берсенә карата яхшы мөгамәләдә булдылар. Мине дә Яшаныкылар бик җылы кабул итте.

Ә аннары... Олегны очраттым. Финляндиягә бер төркем музыкантлар белән барган идек. Таныштык, аралаштык, телефоннар алмаштык. Мин аны ниндидер концертыма чакырдым. Колонналар залында иде ул. Миңа анда магнитофон кирәк булды. Олегтан ярдәм итүен үтендем. Ул китерде. Шуннан башланды бер-беребезгә тартылу... Бөтенләй көтмәгән-уйламаган мәхәббәт булды ул. Шулай булмаса, мин Яшадан китмәс тә идем. Ә алдап-йолдап, ике җирдә ике тормыш алып бару – табигатемә туры килми. Без икебез дә гаиләләребезгә бер-бербезне яратуыбыз турында әйттек, аерылыштык һәм Олег белән кушылдык. Башкача мөмкин түгел иде.

Тормыш юлдашларымның икесеннән дә уңдым. Хатын-кыз өчен, аеруча иҗат белән шөгыльләнә торган хатын-кыз өчен, бу бик мөһим. Ирләрем миңа бик зур терәк булдылар. Аларны шулай сайлаганмындыр да, мөгаен – музыкамны ярата һәм мине хөрмәт итә торганнарны. Икенче ирем – үзе дә композитор, бездән еш кына: «Сез бер-берегезгә конкурентлар түгелме?» – дип сорыйлар иде. Юк. Без дуслар, иҗатташлар булып яшәдек.

Ул академик музыка өлкәсендә күп эшләде, симфонияләр язды. Һәм цирк өчен музыка иҗат итте. Искиткеч талантлы композитор иде. Яшәргә безгә килсә дә, артык безнең тормышка «кереп китмәде», Мәскәүнеке булып кала бирде. Миңа ачуланганда әйтә торган бер сүзе бар иде: «Мин синең музыкаңны үзеңә караганда күбрәк тә яратамдыр әле». «Зәңгәр томан»ны тыңлагач, аякларымны кочаклап елады. Хисле кеше иде, тирән, бай эчке дөньялы. Беренче ирем дә нечкә күңелле кеше. Мин алар кадәр үк хисчән түгел үзем (Көлә).

«ФАРВАТЕРНЫ КҮР!»

Әнкәй гел әйтә килде: «Фарватерны күр! Төп бурычыңны вак-төякләреннән аера бел, юкса максатыңа барып җиткәнче, әллә кайларга барып төртеләчәксең». Шушы принцип миңа ирләрем белән яшәгәндә дә, бала тәрбияләгәндә дә, иҗатта да, кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә дә искиткеч ярдәм итте. Минем белән ирләрем дә, башкалар да идарә итә алмады. Шуңа да әйтә алам: зирәклегең җитсә, «бер казанга ике тәкә башы да сыя». Иң мөһиме – лидер булырга, аркадаш булырга кирәк, әмма диктатор түгел. Тагын бер әһәмиятле шарт: гаилә төзегәндә, культурасы, дәрәҗәсе, тәрбиясе ягыннан үзеңә тиңдәш кешене сайларга кирәк. Нәкъ менә шул культура, интеллигентлык гаиләне кыен чакларында коткара.

Олег белән бер-беребезнең эшенә кысылмый идек, әмма һәрчак киңәшләштек. Ул, мәсәлән, ни дә булса яза, кайсыдыр урында шикләнә яки кайсы вариантны сайларга белмирәк тора һәм миңа мөрәҗәгать итә: «Резик, тыңлап кара әле, монысын сайлыйммы, тегесенме?» Мин һәрчак үз фикеремне әйтәм: «Олег, миңа менә бу вариант кулайрак тоела». Һәрчак фикеремне аргументлап бирәм. Ул тыңлый, мин әйткәннәрне исәптә тотып, эшләп бетерә. Мин дә шулай итә идем. Бу искиткеч зур бәхет – дәртләнәсең, илһамланасың, язасы гына килеп тора.

Бәхәсләшә дә идек. Әмма, ничек кенә үз фикеребезне алга сөрсәк тә, һәрберебез үзенчә эшләп куя иде барыбер. Тик беркайчан да бер-беребезне рәнҗетмәдек. Чөнки мин аның зур шәхес булуын белә идем, ул мине шулай исәпләп яшәде. Бу сокланудан һәм бер-береңнең музыкасына гашыйклыктан килә – тормыш-көнкүрештә ул вак-төякләрдән саклый.

«БЕЗ ХӘЗЕР БИК АЗ КАЛДЫК»

Композиторлар берлегендә 10 га якын яшь композитор, мин аларның барысына сокланып, зур ихтирам белән карыйм. Бездән соң килгән алмаш, киләчәктә татар музыка сәнгатен алып баручылар бит алар. Үзебезгә остазлар ихтирам белән карадылар, безне дә шулай тәрбияләделәр.

Хәзер без бик нык сирәгәйдек. Иң аз әгъзасы булган берлек – безнеке. Чын профессиональ композиторлар турында сүз алып барам, әлбәттә. Сәбәбе – үзгәртеп кору елларында безнең һөнәргә зур зыян килде. Элек композиторларга бик яхшы түлиләр иде, аларның заказлары бар, аларны дәүләт тәэмин итеп торды. Ә акча булмагач, һөнәрнең дәрәҗәсе төшкәч, ир-егетләр бу профессиядән берәм-берәм китә башлады.

Әле мин иҗатка килгән елларда гына да Сатып алу комиссиясе гөрләп эшли иде – елга 4 тапкыр җыелалар. Бу, димәк, дәүләт күләмендә композиторның эше кирәкле, әһәмиятле, дигән сүз. Һәр композиторга заказ бүлеп бирелә, язганнары карала, сайлана. Гонорар түләнә. Хәзер без Рәшит Кәлимуллин белән елына бер тапкыр ул комиссиядән көч-хал белән берничә композиторга гонорар түләнә торган итеп, эшләрен уздыра алабыз. Нинди ир-егет килсен бу өлкәгә?! Гөлнара Тимербулатова, Елена Анисимова, Юлия Бекбулатова, Эльмира Галимова, Наталья Варламова – күрәсезме, нигездә, хатын-кызлар. Ир-атлардан танылып килүче Эльмир Низамовның исемен атый алам.

Резеда Әхиярова кадерле оныклары белән.

КИТАПЛАР САЛГАН МАРШРУТТАН…

Кешенең күңел картасының масштабы ул укыган китаплардан, һәм алар аша ачкан дөньялардан гыйбарәт. Һәм, әлбәттә, сәяхәтләрдән. Еш кына болар кушылып та китә. Китаплар, ымсындырып, төрле илләргә, шәһәрләргә, тауларга, шарлавыкларга, диңгез ярларына сәфәргә дәшә башлый. Һәм син кузгаласың…

Автор:
Луиза Янсуар

Сәфәргә үз машинаңда чыгып китүдән һәм йөреп кайтудан да рәхәте юк – мин моңа инде өченче җәй рәттән инанам. Кайда телисең – шунда җилдерәсең. Экскурсияләр белән генә барып булган җирләргә, әлбәттә, машинаны куеп торып, күмәкләшеп барып кайтасың. Ә аннары кабат – үз иркең белән йөрисең. Шулай йөргәндә, дөньяны сиңа бер генә тур да күрсәтә алмаганча ачасың. Бар җетелегендә, бар чынлыгында. Һәм – иң вак детальләре белән дә.

«Диңгезгә!» – юлга чыкканда төп юнәлеш шулай билгеләнгән иде. Тагын да төгәлрәк: «Кара диңгезгә», ягъни картадагы Сочи, Геленджик, Абхазия кебек пунктлар алдан ук тамгалап куелды. Күңелнең яшерен почмагындагы иреккә зарыккан аваз: «Тауларга!» – дип тә пышылдады, ишетелер-ишетелмәс кенә. Ә аннан маршрутка кинәт Кырым да өстәлде.

Мин диңгез ярында сәгатьләр буе кызынып ятып, кунакханә-пляж арасында таптанып йөри торган зат булмагач, сәфәрнең чуар һәм тиктормас булуын алдан ук чамаладым. Шулай булды да. Һәм әле тагын – әдәби-мәдәни-тарихи…

Сочига кояш күтәрелгәндә килеп җиттек. Беренче эш итеп, магнолияләргә күмелеп утырган «Мак»та тамак ялгап чыктык та диңгез яры буйлап… Сталин дачасына җилдердек. Аның турында Сталинның биографиясен яктырткан китаплардан укып белә идем. Шулай итеп, диңгезгә сәяхәт тарихка сәфәрдән башланды.



ЯШЕЛ ҺӘМ ЯШЕРЕН

Әйтүләренә караганда, халыклар әтисенең Советлар Союзы территориясендә 20ләп дачасы булган. Ул аларның кайсыларында бер тапкыр булып карарга да өлгермәгән, диләр. Көньяктагы дачалардан аеруча атаклылары – Сочида Зеленая Рощада урнашканы һәм Абхазия территориясендә Холодная речкадагы биләмәсе.

Сочидагы дачада безне шунда ук инандырырга ашыктылар: бу дачасын Сталин башкаларыннан күбрәк яраткан. Мин, скептикланып, «бу хакта Иосиф Виссарионович кемгә дә булса әйткән, йә булмаса, көндәлегенә теркәп калдырганмы» кебегрәк сораулар яудырырга ашыккан идем, хезмәткәрләрнең кәефе төште. «Бу дачага, Сталинның башка дачалары кебек үк, музей статусы бирмиләр», – дип, борчуларын җиткерергә ашыктылар. Шуннан без экскурсиягә кузгалдык.

Дача диңгездән 50 метр биеклектә урнашкан. Аңа менеп җиткәнче, борма-борма юллардан барасы. Күрәсең, саклык нияте белән шулай эшләнгәндер, дип фаразладым. Сәфәрдәшем рациональрәк аңлатма тапты: мондагы тау һәм урман эченнән башкача юл салып та булмас иде. Зеленая Рощадагы дачадан «Адлер» аэропортына 12 км чамасы, ә Сочи үзәгенә – 5 км. 50 га территорияне биләп торган бу утар яшеллеккә күмелеп, хуш исле чәчәкләргә төренеп уты-



Сталинның Сочидагы дачасы



Автор фотолары

ра. Ул үзе дә ямь-яшел. Монысына инде экскурсовод та игътибарыбызны юнәлтә: Сталинның барлык дачалары да диярлек шушындый яшел төстә, бу, үзенә күрә, «камуфляж», яшерү ысулы.

Сочидагысын да, Сталинның башка күп кенә дачаларын да архитектор Мержанов проекты буенча төзиләр. Проектны эшләгәндә, Сталинның бер генә теләге була: «Фонтаннар булмасын!» Алар юк та.

Дачаның эченә узабыз: бөек юлбашчы яшәгәндә атмосфера нинди булса, хәзер дә шундый ул биредә. Кыйммәтле агачтан эшләнгән мебель, затлы люстралар, махсус заказ белән эшләнгән диван һәм Сталинга Мао Цзэдун бүләк иткән көмеш өстәл приборы, ул таптап йөргән келәм, бильярд өстәле һ.б. Дөресен генә әйткәндә, Романовларның сарайларындагы шикелле, зиннәтлелек, купшылык юк. Урыны-урыны белән аскетлык та сизелә хәтта.

Туристларны, аеруча чит илдән килгәннәрен, иң тәэсирләндерә торган күренеш: кулына төрәбкә тотып, эш өстәле артында утырган Сталинның балавыздан ясалган фигурасы. Шундый гадәти ул, хәтта карап торышка юаш та күренә – бу уемны кычкырып әйтеп ташлаганмын икән. Экскурсовод шунда ук элдереп алды: «Дөресен генә әйткәндә, шундый факт бар – Сталин дачаларында ял иткәндә, шулкадәр шикләнә, курка торган булган, гаилә әгъзалары да, иң якын яраннары да аның кайсы бүлмәдә йоклавын белмәгәннәр». Бу хакта ЖЗЛ сериясендә Сталин турында чыккан китапта укыганым бар иде. Тора-бара аның бу халәте паранойяга әйләнә, ул көне-төне үз янында корал тота, әллә ничә кат йозакка бикләнеп кенә черем итеп ала торган була, имеш. «Үз өеңдә дә тынгы, иминлек тапмыйча яшә инде...» – монысын эчтән генә уйладым.

30–40нчы елларда дачада иң югары сәяси лидерлар, партия әгъзалары ял итә торган була. Хәзер дә дачаның капка төбендә хәтәр ялтырап кара «Мерседес»лар тезелеп тора. Кара «Волга»ларның лаеклы алмашлары.

Абхазиядәге Холодная речка дачасы яшерен объектларның берсе була. Аның дәүләт номеры – 18. Сталин, имеш, бу урынны корабльдә йөзгәндә күреп ала һәм бер күрүдә үк гашыйк була. «Монда минем дачам булырга тиеш!» – ди. Әлбәттә инде, юлбашчыга каршы килеп булмый, баш өсте, диярга генә кала. 1932–1933 елларда аны торгызалар да. Ул диңгездән 200 метр югарылыкта урнашкан. Әйтерсең, тауга «бикләп куелган». Төсе, гадәттәгечә, яшел. Өч катлы. Йортның мәйданы – 500 кв. метр.

Сүз уңаеннан, бу проект «Совершенно секретно» грифы астында тормышка ашырыла. Аны төзүчеләр, бу хакта берәүгә дә сөйләмәм дип, ант итәләр һәм махсус документка кул куялар, проект җитәкчесе – шул ук архитектор Мержанов. Безне Абхазия буенча йөртүче экскурсоводыбыз Элана, елмаеп, Иосиф Виссарионовичның әлеге дачаны төзүен бик уңышлы гамәл, дип ассызыклады. Беренчедән, Абхазиянең таулар эчендә урнашкан йөрәгенә – сокланып туймаслык Рица күленә илтә торган юллар төзелә, гомумән, юллар мәсьәләсе җитди куела. Икенчедән, дача салынуга, Багрыпста (Холодная речканың абхазча атамасы) елгасында көне-сәгате белән диярлек ГЭС төзелә. Бөек юлбашчы, шулай итеп, Абхазиянең горур һәм кыргый йөрәгенә цивилизация китерә.





Аисны (Абхазия)

РИВАЯТЬЛӘР ЧЫНГА АША ҺӘР АДЫМДА

Мин бу кыргый матурлыкка, нәкъ Иосиф Виссарионович шикелле, бер күз ташлауда ук гашыйк булдым. Ә, сүз башым бит Шүрәле, дигәндәй, Абхазиягә без машина белән керә алмыйча җәфаландык – таможня аша узуы шактый кыен, чират озын. Ике көн рәттән шул чиратның койрык очында тордык-тордык та автобус туры белән чыгарга булдык.

Маршрутыбызның иң-иң күңел алгысыган нокталары – Рица күле, Яңа Афон монастыре һәм, әлбәттә инде, Яңа Афон мәгарәсе. Абхазиягә кереп, Гагра белән Пицунданы узуга, телефоннар тотмый, утыра башлады. Ә менә, ни гаҗәп, таулардагы балны сатып алганда, «Татфондбанк» картасы белән түләү ялт иттереп узды.

Тукталган урыннарыбызда һаваның тыгызлыгыннан, тауларның мәгърурлыгыннан баш әйләнә. Шулай ук, ярымташландык, ярымҗимерек поселокларны, ядрә, шартлау эзе сакланган, ягъни Грузия белән сугыштан соң калган, әле һаман да төзәлмәгән «яра»ның җөйләрен күреп, йөрәк кысыла. Бу «ябып куелган» илнең матурлыгын кайчандыр бөтенсоюз туристлары кулланган бит... Ә хәзер ул, горур рәвештә, буп-буш пляжлары, үзгәртеп кору елларыннан бирле шул килеш калган урбанистикасы белән «балкып» утыра һәм минем ише кайчандыр октябренок-пионер булган мәхлукны еламсырата.

Яшерен-батырын түгел, монда Россия туристларын «савалар», әмма яратмыйлар. Мин Эланага Татарстан турында әйткәч, беләбез, диде, һәм безгә карата мөнәсәбәт күзгә күренеп йомшара төште. (Абхазиянең әле шундый чагы – без 90нчы елларда кичергән Ренессансны алар, холык-табигатьләренә дә бәйле рәвештә, урыны-урыны белән гаять дәрәҗәдә романтикалаштыралар). Ә инде таулардагы абхаз картлары белән бергә куп-куе, каракучкыл-яшел тау балы аертканда, чикләр бөтенләй дә юкка чыкты диярлек. «Минем монда яшисем килә», – дим аларга. «Кил, – диләр, тешсез авызларын җәеп, елмаеп, – бергәләп бал аертырбыз...» «Мин бит һөнәрем буенча – журналист», – дим, балның тамак төбенә утырган рәхәт әчесеннән күзләрем яшьләнеп. Агайларның

йөзләреннән, таулардан күләгә узгандай, караңгылык йөгереп уза: «Яман һөнәр...» – ди берсе, төребкәсен пошкырта-пошкырта.

Шунда, таулар бишегендә, матурлыгына сокланып туймаслык Рица әргәсендә, мин Эланадан һәм картлачлардан Апсны Иленең борынгы риваятьләрен тыңладым һәм, сабый сыман, яңадан могҗизаларга ышана башладым. Сезгә дә укырга киңәш итәм – Наталья Милованова әзерләгән «Легенды Абхазии» дип аталган рус һәм инглиз телләрендәге китапта абхазларның иң кадерле ядкәрләре тупланган. Кемдер аларны артык самими, пафослы дип табар, бәлки, әмма мин нәкъ менә үземнең борынгы бабаларымның риваятьләрендә сакланып калган матурлык белән горурлыкны күрдем. «Апсны Иленең могҗизасын тояр өчен йөрәгеңне ачарга кирәк, ә уйларыңны – туктатып, тәнкыйтьләүдән – тыелып торырга», – диде миңа Элана. Моны эшли алмаучыларга, бигрәк тә, телләк тә белдермәүчеләргә киңәшем: балаларыгызга, йә оныкларыгызга укырга була бу китапны андый очракта. Аларның күз күремен киңәйтер, белемен тирәнәйтер өчен, мәсәлән.

Яңа Афондагы ирләр монастыре Абхазиянең Афон тау итәгендә урнашкан. 1875 елда Иске Афоннан, ягъни Грециядән күченеп килгән Изге Пантелеймон исемендәге рус монастыре монахлары тарафыннан нигез салынган аңа. Монастырь рус-төрек сугышы елларында талана һәм җимерелә. Совет хакимияте аны склад рәвешендә дә, ял йорты буларак та куллана. Грузин-абхаз конфликты вакытында ул хәрби госпиталь вазыйфасын үти. 2011 елдан Абхазия хөкүмәте аны яңадан монахларга кайтара.

Афон мәгарәсенә, имештер, нәкъ менә шушы монастырь изгеләренең берсе рухи аскезага киткән. Бик мөмкин, әмма без тарихка күз салыйк. Аңа керү юлын 1961 елда Гиви Смыр дигән кеше таба. Тикшерү эшләре башлана. 1975 елда мәгарә туристлар өчен ачыла. Бүгенге көндә ул 9 залдан тора, аларның алтысына экскурсияләр керә ала. Залларның һәрберсенең үз могҗизалары – җир асты күлләре, гипс куышлыклар, төрле зурлыктагы сталактитлар белән сталагмитлар...

Залларны гаҗәеп матур яктырткычлар белән бизәгәннәр – барасың, әйтик, каршыңдагы патшаларча зур сталактитның каршына, ул үзенә күрә арфаны да хәтерләтә, органны да, һәм шул мәлдә Бахның Прелюдия фа миноры яңгырый башлый. Ул халәтне сүз белән аңлату кыен булганга, артыгын сөйләп тормыйм. Мин, аннан чыккач, күршедәге Шулганташка да өстәмә опцияләр кирәкле, дигән фикергә килеп кайттым.

Йомгак ясап, Абхазиянең холык-фигылен, һәр персонажында, һәр детальдә чагылган поэзиясен яхшырак аңлар өчен, Фазыл Искәндәрнең «Сандро из Чегема» эпопеясын уку да зарур. Бу китаптагы колорит алдыңа килеп басканда, аңа әзер булыр өчен...





Куктау (Коктебель)

КУКТАУ ТЫЛСЫМЧЫСЫ ҺӘМ БАКЧАСАРАЙ ӘСИРЕ

Куктауны (Коктебель) уз да Волошинга кунакка керми кит инде. Әйе, әйе, без – Кырымда! Әйе, әйе – каршыда гына – Каратау (Карадаг), аннан арырак – атаклы Аютау (Аюдаг). Сүз уңаеннан, быел Кырымда ял итү дә Россия туристларының кесәсенә шактый суга торган. Аеруча – Коктебель. Әмма моннан барыбер дә кеше өзелми – аеруча сәнгать белән җенләнүче халык.

Куктаудагы Волошин йорты – әдәбият җене кагылган туристларның яратып килә торган урыны. Үзенә күрә – Мәккәсе. Бу йортны шагыйрь Максимилиан Волошинның әнисе Елена Оттобальдовна Волошина әле бу җирләр үзенең кыргый матурлыгын саклаган чакта ук, узган гасыр башында, сатып ала. 1903–1913 елларда төзелә ул. Рус әдәбиятының Көмеш чоры вәкилләреннән бу йортта купчелеге булып китә, алай гына да түгел, айлар буе яши дә торган була. Әйтик, Марина Цветаева һәм аның сеңлесе Ася, Осип Мандельштам, Валерий Брюсов, Андрей Белый, Софья Парнок, Михаил Булгаков, Алексей Толстой һ.б. бик күпләр. Елена Оттобальдовна монда яшәүчеләрне, ярым орышып һәм үтә дә яратып, үз итеп, «охламон»нар дип атый торган була. Революциядән соң, Макс белән Пра (Елена Оттобальдовнаның әдәбиятка кереп калган кушаматы) бергәләп акларны да, кызылларны да яшереп тоталар. Максның карары катгый була: «Мин бер яклы да түгел, мин кешелеклелек яклы».

«Шагыйрь йорты» дип символик атамага ия булган утарны чекистлар күзәтү астына ала – янәсе, сез өегезне кунакханә буларак кулланасыз. Хәзер Кырымның буеннан-буена мондый мөмкинлекне олымы-кечкенәме йорты булган берәү дә кулдан ычкындырмый, әмма бу бит – хәзер. Һәм – әйбәт кенә бәягә! Ә ул чакта Пра белән Макска Йортта яшәүчеләрдән «Мин монда акча түләп яшәмим» дип имзаланган беркетмә-язу таләп итүдән башка чара калмый.

Волошин йорты заманында буп-буш яр буенда калкып торган, хәзер инде бирегә пляжны да, яр буен да «яулап» алганнар, билгеле. Һәм «Шагыйрь йорты» эчтәрәк калган, Киммериянең үзенең дә кыргыйлыгы җуелып бара. Йорт эчендә барысы да – Волошиннардан калганча: менә Волошинның остаханәсе, аның түреннән безгә үтә күренмәле һәм сынаулы карашы белән Таиах бага, менә Волошин үз куллары белән ясаган эскәмияләр, язу өстәле, Алексей Толстойның басып язу җайланмасы (ул утырып яза алмаган, йоклап китә торган булган, шуңа да Макс аңа басып язу өчен махсус өстәл корган), менә киштә тулы французча-немецча-русча китаплар һәм журналлар...



Бакчасарай

Күктауны гомере буена яраткан, аның тылсымчысы һәм әсире булган Максимилиан Волошинның «Киммерийские сумерки», «Киммерийская весна» китапларын тәкъдим итәм – анда Россия тарихының зилзиләләре белән Макс эзләгән борынгы тәпкелләр, катламнар, бергә укмашып, бүгенге заманга, хәзерге Кырымга һәм безнең мәмләкәтнең сәясәтенә карата да булган караш ноктасын үзгәртә, ачыграк итә төшә. Әсәрендәгечә, йөгереп барышлый гына, Александр Гринга да «сугылып» үтми ярамый: «Алые паруса» белән «Бегущая по волнам» әсәрләре язучы Коктебель ярларында йөрмәсә язылмас иде.

Бакчасарайны мин бөтенләй башкача күзаллый идем. Зурдыр, искиткеч масштаблыдыр, диеп. Әмма Гәрәйләрнең сарайлары үзенең тыйнаклыгы белән гаҗәпләндерә. Дөрес, купшы да, зиннәтле дә, матур да ул, әмма... бәләкәй. Пушкин дөньяга таныткан фонтан да мәрмәр ташына саргаю йөгертеп, саран гына ир-ат яшьләрен хәтерләтеп, еламсырап утыра. Сүз уңаеннан: «Бахчисарайский фонтан» күңелендә бөреләнгәнче, аның алдында тәэсирләнеп, әсире булып, оза-а-ак басып торган Пушкин бик матур традиция-гадәт керткән: фонтанга ике роза чәчәген китереп куйган. Моны барыбыз да беләбез. Мин балачактан ук ул розаларны үзе белән алып килгәндер, дип уйлый идем, ә, юк икән, мут классигыбыз аларны шушыннан – Ханның розалар бакчасыннан гына өзеп алып кергән икән. Пушкин бит безнең әле Иосиф абзабызга кадәр үк булган юл күрсәтүчебез, аның кылган гамәлләре дә – үзе бер символ, шуңа сарай комплексының хезмәткәрләре бүген дә аның йоласын какшатмыйча саклый – җәен розаларны бакчадан һәр иртә кертеп куялар, кышларын исә ясалма чәчәкләр ярдәмгә килә.



ДОН МИШӘГӘ ОХШАГАН

Кайтуын без Дон трассасыннан кайттык. Кубань кичләренең күе зәңгәрлеген ярып машинада очканда, кинәт кенә, башыбызга китереп сукты: монда, янәшәдә генә, Шолохов станицасы булырга тиеш. Бик озак чыгымчылый торгач, Гугл безгә, ниһаять, Вешенская станицасына юлны салды – трассадан 150 км керәсе. Ярый соң, дидек, Сталин янына кергәнне, Шолохов янына кермичә кайтып китеп булмый бит инде. Һәм – бордык рульне Донның трассасыннан елгасына таба.

150 км дигәнебез бераз ераграк булып чыкты, асылда бөтен көнебезне алды. Әмма Дон ярында басып торган Григорий белән Аксиньяның сыннарын күргәч тә, җанны «ярый әле керми узмадык» дигән рәхәт бер хис биләп алды. Баксаң, бер без генә түгел икән шундый акылсызлар, Геленджиктан кайтышлый Шолоховка кунакка кергән тагын бер абзый белән таныштык.

Биредә Шолоховның йорты, үзенең һәм хатынының каберләре урнашкан. Михаил Александрович белән Мария Петровнаның каберендә – тере чәчәкләр. «Еш һәм күп килмәсәләр дә, килгәлиләр, – ди безгә музей хезмәткәре. – И, булган ул заманнар – мәктәп укучыларын көтүе белән китергәннәр...» Яратам шушындый йортларны – язучының эзе калган, рухы, күләгәсе. Җылысы. Яки – ачынулары, әрнүе. Кайсы булса да – кадерле, газиз.

Язучының икенче каттагы кече бүлмәсендә «Поднятая целина», «Судьба человека» әсәрләре язылган. 2003 елдан ачылган гаражда Шолоховка хезмәт иткән машиналар экспозициясе эшли. Хәер, язучы җәяүләп Дон ярына төшеп йөрергә яраткан, дип инандырдылар безне. Һәм әле ул тагын бик тә өйдә утырырга, туктаусыз эшләргә – язарга яраткан, диеп. «Юкса «Тихий Дон» кадәр «кирпечне» ничек язар иде...» – дип тә өстиләр. «Ул үзе язмаган диючеләр дә бар», – дигән җөмлә янәдән тел очымда, әйтелмичә, эленеп кала. Һәм шулай итәм дә. Шолохов сукмагы буйлап Донга тәпилибез. Аксинья һаман да көянтәсен асып су китерә, Григорий гайрәтле атын авызлыклап аның юлын кисә. Аларның мәхәббәтенә монда берәү дә комачауламый. Һәм, иң беренче чиратта, алар үзләре.

Ә, әйтергә онытып торам лабаса: Донның мондагы борылышлары үзебезнең туган Мишәбезгә охшаган. Һәм аның күрше станицасы, безгә газиз булган исем белән, «Казанская» дип атала.

Кубань,
Вешенская станицасы

ҮЗГӘРҮ

(ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ)



25 август – язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның туган көне. «Татарстан» журналы, юбилей уңае белән, аның «Үзгәрү» дип аталган эссесыннан өзекләр тәкъдим итә.

ВАТАН

«Ватан» сүзе татарга гарәптән кергән бугай. Төркиләрдә ул «ил» дип йөртелә. Бала чакта безгә ватаны да, иле дә авыл иде. Мәктәпкә йөри башлагач, «туган ил» дип атала торган сүз барлыгын белдек. Аның СССР дип аталганын да аңлаттылар. Соңрак «ватан» дигәне телебезгә керде. Ул хәтта «туган ил» дигәнне дә алыштырды шикелле. Чөнки ул ничектер серле ишетелә, китапча яңгырый. Ә китапта язылган һәр сүз – акыллы сүз, кирәкле сүз. «Китап сүзе» дигән төшенчә безгә укырга кергәнче үк инде сеңдерелгән. Әбиләр телендә ул бөтен бәхәсләргә дә чик куя торган дәлил.

Туган ил турында безгә бик күп җырлар өйрәттеләр:

Нинди иркен минем туган илем,
Елгалар күп анда, кырлар күп.
Кеше болай иркен сулый торган
Башка илләр әле җирдә юк.

Без бу җырны класста да, сәхнәләрдә дә җырладык. Соңрак беленде: ул җыр русчадан тәрҗемә икән. Русчасы болай икән. Анысын да җырлаттылар:

Широка страна моя родная,
Много в ней лесов, полей и рек.
Я другой такой страны не знаю,
Где так вольно дышит человек.

Әйе, мәгънәсен аңлап бетермәсәк тә, җырладык.

Урман, кырлар, суларның күплеге аңлашыла иде безгә, ә «Где так вольно дышит человек» дигәне аңлашылып бетми иде. «Бүтән илләрдә кешеләрнең сулышы кысыла микәнни?» диебрәк уйлый идек. Укытучылар аңлаткандыр инде анысы. Ләкин тотып карамагач, кабып карамагач, безгә ул барыбер аңлаешлы булмагандыр. Икмәк менә аңлашыла иде. Аның изге нәрсә икәнлегенә дә тиз төшендек. Чөнки без ачлар идек. Бер сынык ипидән дә кадерле ни-нәрсә бар? Ә туган ил безгә булды ни дә булмады ни. Авыл булгач, бик җиткән. Хәтта район үзәге «Камски Устие» дә безгә ят. Олыларга ияреп Камскига бару кызык үзе. Анда Идел, пароходлар. Пристаньда базар. Салам башлы марҗа кызлары, көрәк сакаллы руслар русча гына сиптерәләр. Русча сөйләшкән кеше безнең өчен бөек кеше инде ул. Камскига баргач, берәр сүз өйрәнеп кайтабыз да мактанышып йөрибез. Мәктәптә дә укыталар рус телен. Тик мәктәптә укыткан тел кызык түгел. Базарда өйрәнгәне кызыграк та, кирәгрәк тә. Бәрәңге сатканда безгә киләләр дә: «Почем картошка?» – дип сорыйлар. Син чартлатып: «Один ведра тристы рублей», – дисең. «Дорого» – дисә, «Дурыгы булса, не бери», – дип кистереп куясың.

Авыл күңелгә якын булса да, без авылда тууыбыз белән түгел, СССРда тууыбыз белән горурланып үстек. Әтиләребез сугышка киткәч, аларны зарыгып көттек. Фашистларга ләгънәт укыдык. Әтиләр җиңеп кайткач, ватаныбызның көче белән чын күңелдән мактандык. Әтиләре кайтмаганнарга «Ватан өчен барган изге сугышта батырларча һәлак булды» дигән язу килде. Бу сүзләр кордаш малайларның кайгысын бераз киметә төшкәндер, ахры. Авылыбызга Германиядә әсирлектә булганнар да кайтты. Аларны без кешегә санамадык. Чөнки аларга ватанны сатучылар дигән тамга ябыштырылган иде. Андыйларның малайларын, «плинни малае» дип атап, арабызга кертмәдек.

СССР ватаныбыз булгач, авыл безгә тарайды, аннан тизрәк чыгып китеп, ватанны урап кайтасы килә башлады. Өстәвенә, авылда тормыш авыр, әниләрнең безне тизрәк авылдан чыгарып җибәрәселәре, кеше итәселәре килә. Ләкин авылдан җибәрмиләр шул, документ бирмиләр. Бүгенгечә әйтсәк, крепостное право инде. Аннан качуның ике юлы бар: берсе – армиягә китү, икенчесе – укырга керү. Армиягә китү авылдан качуга саналмый, ватанга хезмәт итү дип атала. Шуңа күрә яше җиткәннәр, шатланып, горурланып китәләр. Минем дә бик хезмәт итәсем килде. Күзең начар күрә, дип алмадылар. Ничек кимсенгәнемне үзем генә беләм. Җитмәсә, кызлары да «кәҗә билеты» дип мыскыл итәләр. Авылдан китү минем төп максатыма әйләнде. Шулай итеп, авыл миңа туган ил булудан да, ватан булудан да туктады. Университетка керергә имтиханнар биреп карадым. Немец теленнән «икеле» куйдылар.

Мәктәптә укыганда, әти янында бухгалтерия һөнәренә өйрәнгән идем, сельпода хисапчы булып эшләдем. Шуннан мине Казанга сельпо бухгалтерлары әзерли торган курсларга җибәрделәр. Аны тәмамлагач, чирәм җиргә озаттылар. Поездларга төялеп, Казаннан чыгып киткәндә, миннән дә бәхетле кеше юк иде. Алма-Атага, аннан Кустанай дигән шәһәргә поезд белән ватаныбыз буйлап ничәшәр тәүлек барганда, мин чыннан да СССР дигән ватанымның зурлыгына шаккаттым.

Мәскәүдә театр училищесында укыганда да СССР баласы идем. Биш ел ватанымның башкаласында укып кайткач, анда-монда буталып йөргәннән соң, кулга язучы каләме алгач, каләмдәшләр белән сөйләшеп утырганда, съездларга делегат итеп сайланып, бүтәннәрне тыңлаганда нәрсәнең нәрсә икәнен аңлый башладым. «Ватан» дигән төшенчә бик үк изге түгел икән. СССР дигән ватанда бөтенебез дә тигез түгел икәнбез ләбаса. Беренче сортлы, икенче сортлы, хәтта өченче сортлы халыкларга бүленгәнбез икән. Кемнәргәдер нәрсәдер рөхсәт ителә, кемгәдер – юк. Нигә алай? Ни өчен, әйтик, союздаш республикаларга әллә ничә журнал чыгарырга рөхсәт ителә, безгә – юк? Ни өчен аларда киностудияләр бар, бездә – юк? Югыйсә халык саны буенча без СССРда алтынчымы, җиденчеме урынны билибез. Яшәгән саен сораулар кимемәде, арта гына торды.

МИЛЛӘТ

Сабый чакта милләт дигәнең шул әти белән әниең, абый-энеләрең, апа-сеңелләрең инде. Үсә төшкән саен, дөнья киңәя бара; туганнарының күп икәнен аңлаталар. Нәсел дигән сүз барлыгын беләсең. Хәтерлим әле, балачакта бүрәнә өстендә утырган агайлар кемнең кемгә кайсы яктан туган икәнлекләрен тикшерәләр иде. Нәтиҗәдә, авылыбызның бөтен кешеләре бер-берсенә туган булып чыкты.

Милләтнең ни икәнлеген аңларга миңа гомерем буена тормыш өйрәтте. Мин туган районда рус авыллары күп иде, районның үзәге – Кама Тамагында – гел руслар гына яши иде. Беренче булып, әлбәттә, русның без түгеллеген аңладым. Чөнки безнеңчә сөйләшмиләр, киемнәре дә, ашаган ризыклары да үзгә. Тора-бара безнеңчә сөйләшмәүнең сәбәбе аңлашылды – алар башка халык, рус дип аталган милләт икән. Мәктәптә ул халыкның бөек икәнлеген укыттылар. Укытучы әйткәч, аның дөреслегенә без шикләнмәдек. Тик менә ул бөек халыкның телен өйрәнү генә ачуны китерде. Алар сүзен дөрес әйтмәсәң дә, дөрес язмасаң да, «икеле» куялар. Шул чактадыр,

PRESSA.RU

күрәсең, рус булу теләге күңелгә кереп оялагандыр. Бераз вакыт үткәч, дөньяда руслардан башка да кешеләр яшәгәнен белдек.

Дөнья киңәйгән саен, анда төрле телдә сөйләшүче күп халыклар, милләтләр барлыгы ачыкланды. Алар дус яшиләр икәнлеген укыттылар. Бик үк дус булмаганнарын тормыш күрсәтте.

Бүген инде минем беркем буласым килми. Байбайлардан күчә-күчә килгән кан ныграк уйный. Күп тапкырлар әйттем, яздым, тагын да кабатлыйм: бу татарлыгым бүтән халыкларны кешегә санамаудан түгел, менә шул халыклар арасында татарым да барлыгын һәм аның беркемнән дә ким түгеллеген аңлауда һәм аны озаграк яшәтергә теләүдә, яшәвемнең мәгънәсе кемдер булып түгел, татар булып яшәвемдә һәм туганлык канын бездән соң килгәннәрнең тамырына аз булса да салып калдыруда.

ИҖАТ

Язучыларны бергә җыеп эшкәртү өчен, Язучылар берлеге оештырылды. Без аның әгъзалары идек. Язучыдан зур бер агрегатның винтигы ясау идеологиясе мин әдәбият бусагасын атлап кергәндә көчле иде әле. Ул идеологиягә буйсынмый яшәү бик кыен иде. Чыгымчылаучыларны тәртә арасына кертүнең күптөрле ысуллары бар иде. Чыбыркы белән бергә прәннегә дә эләгә иде, билгеле. Мин инде аларны санап тормыйм. Һәрхәлдә, әдәбиятка килүче яшьләргә игътибар хәзергедән күпкә яхшырак иде. Без ташландык хәлдә түгел идек. Безгә күрсәтелгән игътибар өчен без иҗат ирене белән түләргә мәҗбүр идек. Шулай да, таш араларында үсәргә омтылган, хәтта өстенә җәелгән асфальтны да тишеп чыккан үлән, агачлар кебек, җан ирекка омтыла иде. Җәмгыятьтә кемнеңдер әйткәнен кабатлау белән канәгатьләнмичә, үз сүзеңне әйтергә тырышу инстинкты күңелләрдә яшәп килде. Без ул турыда аерым-аерым да, кайчакларда берничә язучы бергә мәҗлесләрдә җыелганда да уйлана, сөйләшә, фикер алыша идек. Бәхетемә күрә, мин инде иҗат тәҗрибәләре булган талантлы кешеләр арасына килеп эләктем. Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Альберт Яхиннар белән мәҗлестәш булып, күп нәрсәгә өйрәндем.

Язарга берәүне дә өйрәтеп булмый. Хәреф танырга, җөмлә төзергә, нокта-өтерне кая куярга өйрәтеп була, ә әдәби әсәр язарга – юк. Хәер, бәлки, анысына өйрәтеп буладыр, ләкин ул өйрәтелгән язучы өйрәнчеклектән үлгәнче чыга алмыйдыр. Ул гомере буе остазын кабатлый гына торгандыр. Әдәбиятта үз йөзең, үз сүзең булмаса, исемең дә булмый.

Яза-яза мин бер нәрсәгә төшендем: акыллы фикер әйтәм дип көчәнергә кирәкми икән язучыга. Үзеңнән дә акыллырак булып булмый. Акыллырак булып маташсаң, укучы синең дурак икәнеңне тиз сизә. Гомумән, көчәнү – адәм баласы өчен зарарлы нәрсә.

Язу өчен көннең кай вакытын сайлау да әһәмиятледер. Кемнәрдер төнлә, кеше-кара йоклагач, тынычлап яза, мин исә организмның эшкә иң әзер чагын сайладым. Иртән утырып язам. Йокы туйган, баш ял иткән.

Иҗат өстәл янына утыргачы башлана. Баш шәрифләренә ниндидер бер тема дип әйтикме, идея диикме, шул килеп керә дә тынычлыгыңны ала. Йөртәсең шуны күңелеңдә, уеңда төрлечә әвәлисең, пьеса формасынамы, хикәяләү калыбынамы утыртасың. Иң рәхәте, иң кызыгы шул чакта. Берәр чибәргә бер күрүдә гашыйк булып, шуны тагын очрату бәхетенә ирешү өчен планнар корган кебек. Кайвакыт корган планнарың язарга утыргач кына үзгәрә… Кайчак җитешсезлегеңне сәхнәдә күрәсең. Бервакыт карап утырам язганымны. Спектакльнең бер күренеше ошамый. Күрәм: гаеп режиссерда да, артистларда да түгел, үземдә. Шунда мин: «Болай язалармыни?!» – дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

ХОЛЫК, ГАДӘТ

Кеше холкы туганда ничек булса, үлгәндә дә шулай кала, диләр. Шулайдыр. «Туганда ук чүпрәккә төргәнне яратмадың, елый идең, үсә төшкәч, өстеңдә юрган тотмадың», – ди торган иде әни. «Бөтен бала да билгәнне яратмый инде», – дигәч, «Мин беләмме, син беләсеңме, ничә бала үстердем», – дип, авызымны томалады.

Үзсүзле идем, кире идем. Үзем теләмәсәм, кушылган эшне эшләми идем. Әти сүз дәшмәде, энидән эләгә иде. Такташ әйтмешли, «шактый тал чыбыгы ашадым».

Кычкырып сөйләшә торган гадәтем бар. Югыйсә саңгырау да түгел. Күрәсең, безнең гаилә гадәте миңа сеңгән. Бездә әтидән кала барыбыз да кычкырып сөйләшә идек. Өебез яныннан үтеп китүчеләр «болар ызгыша икән» дигәннәре хәтердә. Көлгәндә дә кычкырып көләбез. Барыбыз бергә кычкырып көлгәндә, өй селкенә иде. Бу гадәтемне үзгәртергә күпме тырыштым – булмады. Кешеләр еш кына: «Нигә кычкырасың?» – диләр иде. Бигрәк тә начальство янына кергәндә уңайсыз иде. Чөнки түрәләр үзләре каршында койрыгын кысып, шыпан гына утырып, гаепле кеше сыман курка-курка, әкрен генә сөйләгәнне хуп күрәләр. Бигрәк тә әлеге гадәт гаиләдә җайсыз, әкрен генә, сабыр гына нәрсәдер аңлатырга тырышасың. «Нигә кычкырасың?» – диләр. Юк, үзгәртеп булмас, ахры. Чөнки кычкырып сөйләшүнең кайбер яхшы яклары да бар. «Туфан абыйның яшерен эше, яшерен сүзе, мәкере юк аның», – диләр. Юктыр, мин өрми торган эттән куркам, дәшми утырган мыштым кешеләрне өнәмим. Оятсызларны яратмыйм.

ШӘХЕС

Кайчакларда башка әллә Язучылар союзыннан чыгыйммы икән дигән уйлар да килгәләде. Ләкин тирәнрәк фикер йөрткәч, бу уйдан кире кайттым. Милләтне бергәләп яклар өчен, бергәләп саклар өчен, безнең берләшебрәк яшәвебез кирәк. Чөнки без, төрле-төрле булсак та, милләт мәсьәләсендә бер фикеребез уртак. Ләкин бер фикеремнән кире кайтмыйм: әгәр Язучылар союзы шәхесне кыса икән, ул кирәкми. Язучы шәхес булырга тиеш. Ягъни Союз шәхесләр союзы булырга тиеш.

Үз кадереңне үзең белү инстинкты нәселебез, каннан күчсә дә, аны гомер буе саклап килеп, бүген аңлы рәвештә аны яклау дәрәҗәсенә ирештем. Мин Дәүләт Советы мөнбәреннән: «Үз кадерен үзе белмәгән кеше – чүп ул, үз кадерен үзе белмәгән халык – чүп өеме», – дип әйткәнмен икән, кемнәрөчендер кисәтү дә иде. Мине кемнәрдер кимсетергә тели икән, ниятләре барып чыкмастыр. Мин кайчакларда буйсынган булып уйный алам, әмма җаным иркле.

* * *

Үзгәрү процессы дәвам итә. Ул соңгы сулышкача дәвам итәчәк. Ничаклы гына үзгәртсә дә дөнья, мәңгелеккә кешеләрнең рәнҗеп һәм котылдык дигән уйларын сизмичә китәргә язсын иде.

Дөньяда бердәнбер абсолют гадел нәрсә – үлем. Бөтенебезне тигезли. Олигарх та байлыгына күмелеп үлә, бомж да сәләмәсенә уралып үлә. Җир астында урын күп, анда ипотека юк. Кайчакта мин «Ни хәлләрдә яшисең?» дигән сорауга «Үләргә әзерләнәм» дип җавап бирәм. Җавабымны ишетүчеләр сәерсенеп калалар, юатырга тотыналар. Ә кеше үлемгә әзерләнергә тиеш. Исән-сау җир җимертеп йөргәндә дә, мин калганнарга ни калдырып, үзем белән ни алып китәм, дип уйланырга тиеш. Мин дә Ходай каршына ни күтәреп барачагым турында еш уйланам. Буш чумадан белән Бөек Зат каршына бару оят.


Печищи
Набережные Моркваши
Югары Ослан
Введенская Слобода
Ключищи
Куралово

PRESSA.RU

Югары Ослан районы

ИННОПОЛИСКА – ПОЛЕОЗОЙ АША

Иделнең уң як яры Казанга яхшы күренә: без аңа шулкадәр еш карыйбыз, хәтта сизмибез дә диярлек. Ә бит анда, Югары Ослан районында, санаулы сәгатьләр эчендә чиксез тирән үткәннәрдә дә, һәм шул ук вакытта якынлаша гына башлаган технологик киләчәктә дә булып кайтырга мөмкин.

Автор фотолары

Вознесение-Макарьев монастыре урнашкан тау итәгендә 2001 елда агач чиркәү-коендыру урыны төзелгән. Суы боз кебек салкын!

PRESSA.RU

Настя белән Алеся Голубиналар туктаусыз хәрәкәттә – әле күнегүләр, әле җыеннар, әле ярышлар. Шул ук вакытта кызлар яхшы гына укырга, баскетбол һәм волейбол уйнарга да өлгерә.

Автор:
Олеся Бондаревская

АВЫРЛЫК ҺӘМ АНЫҢ ҖИҢЕЛЛЕГЕ

Югары Осландагы өр-яңа «Чемпион» спорткомплексының иркен залларының берсенә ачык тәрәзәдән кояш нурлары төшә. Ике кыз бер тавышсыз диярлек штангаларындагы дискларын алыштыралар – 15 килограммлысын 20 килограммлыга. Кызларның берсе 55 кг авырлык белән ашыкмыйча һәм матур итеп иелү-бөгелү хәрәкәтләре ясый башлый.

Настя (ыргылыш – 80 кг, этелү – 98 кг) һәм Алеся (ыргылыш – 65 кг, этелү – 85 кг) Голубиналар белән Ришат Мансуров монда инде берничә ел дәвамында күнегүләр ясый. Настя – авыр атлетика буенча 18 яшькәчә кызлар арасында Россия беренчелегендә ике тапкыр көмеш призер, Алеся да – шул ук ярышларда ике тапкыр көмеш призер булган, ә быел 18 яшькәчә категориядә алтын медаль яулаган. Кызлар – бөтен Россия ярышларына, ә Алеся, өстәвенә, 18 яшькәчә кызлар арасында Европа беренчелегенә сайлануга әзерләнә. Бөтен буш вакытлары күнегүләргә багышлана. Алеся – Казандагы Олимпия резервы училищесына, ә Настя шулай ук Казандагы Спорт һәм туризм академиясенә укырга керергә җыена.

– Кызларга хас булмаган спорт, – дим мин.

– Шулай тоела гына ул, – дип елмая бертуган кызлар.

– Бу Печищи кызлары Россия ярышларында республика данын яклый, ә хәзер халыкара дәрәҗәдә ил данын яклау мөмкинлегенә дә ия булачак. Алар күп нәрсәгә иреште, әмма алда тагын да зуррагы тора, – ди тренер. – Мин үзем Олимпия уеннарында катнаштым, байтак спорт мастерларын тәрбияләдем. Әйе, спортта җиңүләр дә, казанышлар да бар, җиңелүләр дә була. Әмма шунысы бар – бервакыт һәм бөтенләйгә син үз-үзеңне табасың, үзеңне җиңәргә, үз-үзең һәм, димәк, тормышың белән дә идарә итәргә өйрәнәсең.

ЮГАРЫГА ЕГЫЛУ

Дүрт урынлы «Сессна» җирдән аерыла да, бөтен корпусы белән калтырап, югарыга омтыла. Түбәндә өй түбәләре генә шакмакланып күренгән ямь-яшел Югары Ослан җире җәйрәп ятканын күзәтеп, эчтән генә бик үк югары күтәрелмәсен иде инде, дип телибез.

Колакчыннарыбызда Югары Ослан районы башлыгы урынбасары Сергей Осянинның:

– Игътибар итегез, сул борт ягында – Каинки, – дигән тавышы ишетелә. Ул – бер үк вакытта тарихчы, бу якларны бик яхшы белүче, шуңа күрә, безнең экскурсовод та. – Биредә, Крестовоздвиженская чиркәвендә, XX гасыр башында Вакытлы хөкүмәт башлыгы булачак Керенский әфәнде Ольга Барановская белән никахлашкан.

Без аздан гына районның бик күп талантлы кешеләре һәм фамилиядәш Осяниннар туган легендар Коргузага очып җитмичә калабыз.

Безне туктаусыз «сыйлап» торган «чокырлар» һәм «таулар», һәм шул сәбәпле иртәнге кофеның гравитациягә инде буйсынмавы Сергей Викторовичка берни түгел. Ул дәртләнеп дәвам итә:

– Хәзер иң мөһиме – беспилотник белән кисешмәскә. Монда аларның базасы ерак түгел...

Пилот елмая, әмма, саклык йөзеннән, диспетчер аша «коридорның» чисталыгын тикшереп ала. Без ялтырап торган кристаллар – Иннополис биналары өстеннән очабыз. Тагын – «Казан» тау чаңгылары курорты, дулкыннар өстендә яткан зур бер ташбака төсле Свияжск өстеннән... 250 миллионнан артыграк яшьтәге Печищи геологик уемы өстеннән. Кыргый агач куелыклары арасында агарып күренгән Макарьев монастыре өстеннән...

Самолетыбыз борыны белән җиргә төбәлә, һәм пыяла артында Иделнең чиксез көмешсу-зәңгәр киңлеге пәйда була.

– Монысы Соколка тавы – кайчандыр Казан ханлыгы идарәчеләре биредә лачыннар белән ауга чыга торган булганнар. Шушы тау белән лачын безнең гербны бизи. Ә менә Меркуша тавы – монда Франциянең

400 метр биеклектән Свияжскидагы бөтен урамнарны һәм өйләрне бик яхшы күрергә була. Утраудагы биналарның интерактив планын шунда ук, Свияжск музеенда, табарга мөмкин.

«Футуроскоп»ына охшаган югары технологияле гаилә-танып белү паркы төзелергә тиеш, – дигән аңлатмасы ишетелә экскурсоводның.

Сергей Викторович, каядыр аска таба күрсәтеп, сөйләвен дәвам итә. Артык тавышлар аны ишетергә комачауласа да, мин чамалыйм: мөгаен, анда үткәннәр белән киләчәкнең очрашу ноктасыдыр. 400 метр биеклектән ул уч төбендәге кебек күренә.

Максим Осянин

Сергей Викторович, каядыр аска таба күрсәтеп, сөйләвен дәвам итә. Артык тавышлар ишетергә комачауласа да, мин чамалыйм: анда үткәннәр белән киләчәкнең очрашу ноктасыдыр.

УЙНА, МАКСИМ!

Куе мальва «сөңгеләре» арасыннан аккордеон тавышы ишетелә. Бераздан мин аның нинди көй икәнен дә аңлап алам: «На позицию девушка провожала бойца...» Югары Осландагы Балалар сәнгать мәктәбендә, күрәсең, каникул юктыр.

– Бу мәктәпкә быел 46 яшь тулды. Биредә өч бүлек эшли – музыка, хореография һәм сынлы сәнгать. Мондый мәктәпләр башка юк, шуңа күрә биредә шөгыльләнергә бөтен районнан киләләр, – дип сөйли директор Ольга Киреева.

Мин мәктәп турындагы белешмәгә күз салам: аның уңышлары өч биттә санап чыгылган. Укучылар һәм укытучылар алган грантлар, призлар, бүләкләр. Ә бит бу 40 ел стажлы педагогның уртача хезмәт хакы 13 мең сум гына булган килеш. Уңышларга омтылыш каян?

– Үз эшеңә, шушы җиргә мәхәббәттән, – дип елмая Ольга Анатольевна, иңнәрен җыерып.

Аның Югары Осланга мәхәббәте 15 ел элек башланган. Алар, ире Виктор белән, Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң, башкаладагы музыка мәктәбендә эшләгәннәр. Виктор, халыкара конкурс лауреаты, А.Шутиков җитәкчелегендәге Дәүләт халык уен кораллары оркестры солисты, Югары Осланда дәресләр дә биреп йөргән. Кышларын Идел аша, кайчакта иңнәренә баян аскан килеш, җәяүләп чыга торган булган. Әмма бер бәйрәм концертында аның таланты район башлыгын җәлеп иткән. Нәтиҗәдә Викторны да, Ольганы да биредә яшәргә һәм эшләргә чакырып алганнар, торак биргәннәр. Озакламый Ольга музыка мәктәбенең директоры булган, соңыннан аны сәнгать мәктәбе итеп оештырган.

– Авыл балалары бик хезмәт сөючән, гаджетлар һәм башка күңел ачу чаралары аларның күзен томаламый. Алар тырышып эшли белә һәм күп нәрсәгә ирешә дә. Безнең районда Коргуза авылы бар. Анда талантлы балалар искиткеч күп. Менә шуларның берсен, Максим Осянинны, ата-анасы 5 ел буе атнасына өчәр тапкыр, кышкы салкынга һәм җәйге челләгә карамыйча, 40 чакрымнан биредә дәрескә йөртте. Хәзер ул Казанда укый. Һәм мондый өметле балалар бездә күп, – ди Ольга Киреева.

МОННАН СОҢ БЕРКЕМ ҺӘЛАК БУЛМАСЫН

– Китәребезгә дүрт көн калган иде. Шунда мине бәхет басты. 2,5 метр чамасы тирәнлектә портмоне таптым. Аның эчендә «Гвардия» билгесе һәм 30 тиен акча бар иде. Тагын адреслы кәгазь кисәге – сугышчының кайда үлгәнен хәбәр итү өчен. Аннары бу табылдыкны Фәннәр академиясендә ачыкладылар. Сугышчы Ленинградтан булып чыкты. Хәзер аның туганнарын эзлиләр, – дип сөйли Югары Осланның тугызынчы класс укучысы Влада Долгушова. Бу җәйдә Югары Осланның унбиш яшь эзтабары арасыннан Влада һәм тагын ике укучы Нева пятачогында булган. 1941 елдан 1943 елга кадәр анда Татарстаннан меңнән артык сугышчы һәлак булган. Югары Осланнан – 70 кеше.

Югары Ослан ветераннары оешмасы рәисе Римма Троицкая җитәкчелегендәге эзтабар-укучылар отряды, сугышлар барган урыннарга даими чыгып, үз алларына Нева пятачогында һәлак булган Югары Ослан кешеләренең исемнәрен мәңгеләштерү бурычын куя.

– Кем Бөек Ватан сугышында катнашкан, кем безнең җиребезне фронтта һәм тылда саклаган, шулар турындагы истәлекләрне барлау – безнең төп бурычыбыз, – дип сөйли Римма Сергеевна. – Бу безнең кешелек һәм, ничек кенә пафослы яңгырамасын, патриотлык бурычыбыз. Һәм, әлбәттә, бу истәлекләрне оныкларыбызга тапшыру шулай ук бик мөһим. Безнең укучыларыбыз энтузиазм белән казу эшләренә чыга, сугышчыларның язмышла-

Районның Римма Троицкая җитәкчелегендәге «Совесть памяти» эзтабарлар отряды инде икенче ел рәттән Нева пятачогына – 1941–1943 елларда Ленинград өчен каты сугышлар барган урынга юлга чыга. Узган ел укучылар өч сугышчы сөякләрен һәм бер медальон тапкан. Сугыш вакытында биредә Татарстаннан 1000гә якын сугышчы һәлак булган.

PRESSA.RU

Ю

рыначыклап, аларның туганнарын эзләп, зур архив эшләре алып бара икән, мин илебезнең киләчәге өчен тынычрак була алам.

Ә балалар үзләре моңа ничек карый соң?

– Бу истәлекне саклау мөһим. Тарихны саклау мөһим. Чөнки аны үз максатларында файдаланырга теләгән кешеләр тарихның хаклыгына яный, – ди миңа Влада. – Әгәр син эзтабарлык белән шөгыльләнәсең, аларның сөякләрен, пуля тишкәләгән шәхси әйберләрен, котелокларын табасың икән, бу окопларда кешеләрнең нинди корбаннарга барганын аңлыйсың. Минем, үз туган ягымның, үз илемнең мәнфәгатьләрен һәм башка кешеләрнең мәнфәгатьләрен яклау өчен, сәясәтче буласым килә. Һәм – киләчәктә мондый корбаннарны булдырмас өчен.

ЧӘЙ ТУРЫНДА

– Ни гаҗәп, моннан бик тә танылган кешеләр узып киткән, кунак булган. Ә тарихта ниндидер көнкүреш детальләре генә саклана. Мәсәлән, Радищевның бездә итләрнең аз, ә кыярның күп булуы турындагы гыйбарәсе, – дип, шаярткандай борчылуын белдерә Югары Осланның туган якны өйрәнү музее директоры Анжелика Решетова.

Ул безгә музейның экспозициясен – панорама-китапта тасвирланган кебек ачык төстәге йөзләр һәм вакыйгалар тезмәсен күрсәтә.

Менә Иван Грозный Свияжскидан су юлы белән китеп бара, менә Ключищи буйлап булачак шәфкать туташы Даша Севастопольская йөгерә, менә Карамалы Тауда сөргенгә бару юлында Меньшиков авырып үлгән хатыны өчен кайгырып елый һәм Ослан зиратында аңа үзе кабер казый, менә, көймәче-татар зарын тыңлый-тыңлый, Герцен Идел кичә, менә Каинкида әле генә никахлашкан булачак Вакытлы хөкүмәт башлыгы җыелган халык төркеменә вак акча сибә, менә Идел-ана аша Романовлар күперен төзиләр, ә Введенская Слобода дачасындагылар, верандаларында чәй эчә-эчә, төзелешне күзәтә, менә Соколкада кызыллар һәм ак чехлар арасында революциянең язмышын хәл итәчәк сугыш бара...

Югары Ослан яры дачаларында яшәүчеләр, әйтерсең лә, тарихның бөтен давылларын, күңелсезлекләрен һәм ыгы-зыгыларын уңышлы уздырып җибәргәннәр дә верандаларында урман һәм болын үләннәре кушылган чәйләрен эчүне дәвам итәләр. Мич торбаларының

Биредә Кызыл Байракның текә ярыннан ачылган Идел күренеше күренекле татар композиторы Салих Сәйдәшевне «Зәңгәр шәл», «Наёмщик», «Кандыр буе» кебек спектакльләр өчен танылган әсәрләр, һәм шулай ук «Әдрән диңгез» җырын язарга рухландырган, диләр. Менә 16нчы ел инде монда «Сәйдәшстан» уникаль музыка фестивале үтә, ул үзенә татар классик һәм эстрада җырларын иң яхшы башкаручыларны җыя.

Ключищи авылындагы Иоанн Предтеча Тууы хөрмәтенә төзелгән гыйбадәтханә совет заманында ябылгач, кайбер кешеләр аның кирпечләрен сүтеп ала башлаганнар, дип сөйлиләр. Әмма Иоанн Предтеча – кырыс холыклы изге, гыйбадәтханәгә кул сузучылар озакламый авырый башлаган. Җимерү тукталган. Изге йорт 2011 елда кабат торгызылган.



Бернича ел элек бирегә, текә Печищи ярына, атна буе бер кеше килеп йөргән, диләр. Мондагы кеше түгел, Көнчыгыш акценты белән сөйләшкән. Һәр көнне, иртә таңнан кояш батканчы, лотос позасында утырып торган. Аның кем булуын, каян килгәнлеген сорарга беркем дә җөрьәт итмәгән, Идел бит ул – бар кешенеке дә.



Печищида ташлар җыю вакыты «Татарстан» журналын да читләп үтмәде. Хәзер безнең дә борынгы әкәм-төкәм кабыгы эзе төшкән ташыбыз бар.

төтене кояш баешы алды томаны белән кушылып китә, һәм бу Идел суына тиң борчусыз тынлыкның ахыры булмас кебек тоела.

– XX гасыр башында монда бик күп сату алачыклары булган, барысының да товарлары – төрле. Бирездә ял итүче алпавытлар һәм дворяннар сәүдәгәрләрдән бурычка акча да алып торганнар, – дип, минем хыялларымны бүлә Анжелика. – Күптән түгел безгә бер китап китерделәр. Кем генә юк анда! Менә Архип Бабушкин, 2 нче гильдия сәүдәгәре, пароход хуҗасы да әле, 5 сум бурычы бар. Ә менә Боратынская, Мария Евгеньевнаның бурычы – 2,5 сум...

Музейның ишеге ачык, урамнан нарат күркәсе күмере, әйбәтләп пешерелгән бөтнек, урман чәе, каен җиләге исләре аңкып керә...

– Күз алдына китерегез, без Пермь диңгезенең төбендә басып торабыз. Кайбер галимнәр, мондагы бутта сакланып калган микроорганизмнар мохитен өйрәнеп, диңгездәге суның төче булганлыгын раслыйлар.

ПЕРМЬ ЧОРЫ ПАРКЫ

Идел өстендә томан тарала, аның аша күтелмәгәнчә якын булып Казан яры контурлары, Аракчинодагы Барлык диннәр храмы, ә сул якта шактый еракта автомобиль күпере шәйләнә башлый. Томан куера, һәм барысы да эреп югала. Печищи пристане, киң елга һәм андагы кечкенә көймәләр генә кала.

Печищи – районның иң борынгы авылларыннан берсе. Известняк табу һәм аны мичләрдә кыздыру белән Иван Грозный заманнарында ук шөгыльләнә башлаганнар – исеме дә шуннан килә. Монда табылган известь ташы – бут – бик сыйфатлы санала. Әмма геологлар җәмәгатьчелегенә Печищи уемы барыннан да элек – 250дән 300 млн елга якын тарихка ия булуы белән кызыклы. Бу палеозой эрасының соңгы периоды булган «пермь» геология һәйкәле.

– Күз алдына китерегез, без Пермь диңгезенең төбендә басып торабыз. Кайбер галимнәр, мондагы бутта сакланып калган микроорганизмнар мохитен өйрәнеп, диңгездәге суның төче булганлыгын раслыйлар, – ди Янка Купала музее директоры Римма Абызова. Без шактый биек Печищи кыясының кырыенда ук басып торабыз. Әллә кайда, түбәндә, вак ташлы яр буйлап ял итүчеләр йөри.

– Узган ел биредә геологларның халыкара симпозиумы үтте. Дөньяның төрле илләреннән 100дән артык галим килде. Һәм аларның күбесе безнең уемның – төбәктә генә түгел, дөньяви кыйммәттәге һәйкәл булуын раслады, – ди Римма Абызова. Шул ук вакытта һәйкәл үзе җирле проблемалардан җәфа күрә – табигатьтә ял итәргә яратучылар аны туктаусыз чүпли.

Музей хезмәткәрләре биредә даими рәвештә мәктәп укучылары өчен экскурсияләр үткәрә. Таралып яткан известняк кисәкләре арасыннан укучылар мавыгып миллион еллар элеккеге тереклек – бөҗәк, вак балык, моллюск, суүсем эзләре калган ташларны эзли.

Римма Юрьевна миңа тарихи бәхетемне сынап карарга тәкъдим итә. Эшем шунда ук уңа: кулыма үзеннән-үзе катлы-катлы әкәм-төкәм кабыгы эзе төшкән таш эләгә. Вакыт борылмаларын тою хисе ирексездән сискәндереп җибәрә.

Ю

МАРАТ ЗЫЯТДИНОВ: «ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫНЫҢ ИННОВАЦИОН КИЛӘЧӘГЕ БАР»

Югары Ослан районы башлыгы безнең журналга Татарстанның Идел буендагы иң кызыклы территориясенең берсен үстерү буенча планнары турында сөйләде.

– Марат Галимжанович, октябрьдә районга 85 яшь тула, бу – җитди сан. Ул Сезнең үзегез өчен дә мөһимдер...

– Бу бик матур дата, без аңа зур уңышларга ирешеп килдек һәм юбилейның үзен дә киң колачлы итеп билгеләп үтәбез. Әмма районның һәм бирәдә яшәгән халыкның, монгады вакыйгалар һәм урыннарның тарихы әлеге саннан да колачлырак һәм тирәнрәк. Экскурсиягә килегез – үкенмәссез! Ә без исә үткәннәр мисалында үзебездә булган ресурслардан файдалы, дөрес итеп файдаланырга өйрәнәбез.

– Районның озак вакытка һәм якын киләчәккә исәпләнгән планнары нидән гыйбарәт?

– Территорияне үстерү буенча барлык планнарыбыз да «Югары Ослан районын 2030 елга кадәр үстерү стратегиясе»ндә чагылыш тапкан. Документ теге яки бу проектны эшләү һәм тормышка ашыру барышында без үзебез таянган берничә идеяне үзенә туплаган була. Стратегиянең төп пунктлары безнең якның туристлык потенциалын, кайчандыр районда зур үсешкә ия булган авыл хуҗалыгында эшкәртү өлкәсен яңадан торгызуга һәм Иннополис шәһәре территориясендә IT-технологияләрне үстерү белән бәйле булган перспективаларга кагыла.

– Һәр юнәлеш турында тулырак сөйләгез әле, зинһар.

– IT-кластердан башлыйм. Быел җәй көне Россиянең яңа тарихында беренче булган IT-шәһәр рәсми рәвештә ачылуына бер ел тулуны билгеләп үтте. Бирегә әкренләп белгечләр күчеп килә. Даими рәвештә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә Иннополисның Күзәтчелек советы утырышлары уза, «Иннополис» махсус икътисадый зонасының яңа резидентлары турында карарлар кабул ителә. Бүгенге көнгә аларның саны 21гә җитә. Иннополис Университеты студентлары инде өченче курста укый. Бик зур эш башкарылды, һәм ул дәвам иттереләчәк. Без үз чиратыбызда кирәк булган барлык административ ярдәмне күрсәтеп торабыз.

– Туристлык өлкәсен дә шулай ук инновацияләргә бәйле рәвештә үстерү күздә тотыламы?

– Әлбәттә, бик дөрес әйтәсез. 2014 елда Меркушино тавында гаилә өчен күңел ачу паркы проекты эшләнгән иде. Паркның проект буенча каралган мәйданы 70 гектарга якын, берьюлы өч мең кеше сыярлык. Проект белән Франция инвесторлары кызыксынды. Бүген проектны алга этәрүгә Татарстанның Инвестицияле үсеш агентлыгы да актив рәвештә кушылды, һәм проект Сеулда Lotte иң эре күңел ачу паркларының берсенә хуҗа булган Кореянең Lotte Group* девелопер компаниясе тарафыннан презентацияләнде.

– Ә ни өчен нәкъ менә күңел ачу паркында тукталдыгыз?

– Беренчедән, парк салу өчен бүлеп бирелгән территория гаять зур рекреацион (ял итү өчен җайлы булган) потенциалга ия, аны исә Иннополисның IT-белгечләре тарафыннан башкарылган технологик эшләнмәләр белән тулыландырырга мөмкин. Икенчедән, бу, үз чиратында, масштаблы инфраструктур проектларны тормышка ашыру өчен кирәк булган трафикны тәэмин итүнең оттырышсыз варианты.

– Казан һәм Югары Ослан арасында транспорт системасын үстерү буенча планнар бармы соң?

– 2030 елга кадәр республиканы үстерү стратегиясе тарафыннан зур Казан боҗрасының көньяк өлешен төзүне мантыйкый рәвештә тәмамлау буларак Гребень районы тирәсендә Идел аша автомобиль күпере төзү күздә тотыла. Әмма бу – озак вакытка исәпләнгән хыяллар. Ә хәзергә – Казанның үзәк тимер юл вокзалына якын җирдән Югары Осланны мегаполис территориясе белән тоташтырачак канат юлын төзү каралган. Инде хәзер аны проектлаштыру буенча эшләр башланды. Эшләр уңышлы барган очракта әлеге проектны тормышка ашыру «Идел Дискавериз» күңел ачу паркын төзү башлану белән туры киләчәк.

– Сез эшкәртү тармагын үстерү турында әйтеп уздыгыз. Әлеге проект турында тулырак сөйләсәгез иде.

– Барыбыз да белә, советлар заманында бездә бик күп хуҗалыклар бар иде, анда сәнәгать масштабында җиләк-җимеш үстерелде. Сүз уңаеннан, җирле туфрак составы бөртекле

* Lotte Group (Лотте Груп) – Көньяк Корея компаниясе.

культураларга караганда бакчачылык өчен күбрәк туры килә. Элегрәк берничә эре эшкәртү предприятиесе эшләгән. «Татплодоовощпром» тырышлыгы белән әлеге заманнардан «Заря» агрофирмасы бакчаларын саклап калырга мөмкин булды. Бүген биредә җитештерү күләмнәрен арттыралар, заманча яшелчә саклагычлары төзелә. Без җимеш-яшелчә культураларын эшкәртү традицияләрен торгызырга телибез. Авыл хуҗалыгы продукциясен, балыкны саклау, эшкәртү, ярымфабрикатлар чыгару, бал җыю һәм төрү буенча цехлар урнаштырылган агросәнәгать мәйданчыклары проекты тормышка ашырыла да инде. Предприятиене Воробьевка авылы тирәсендә урнаштырырга планлаштырабыз.

– Әлеге мәйданчык чимал белән тәэмин ителәчәкме?

– Һичшиксез. Район территориясендә җиләк бизнесы булдыру белән кызыксынучы эшмәкәрләр дә бар. «Кызыл Шәрык» һәм «Идел аръягы агрофирмасы» («Ак Барс» холдингы) кебек авыл хуҗалыгы предприятиеләре бар. Алар инде бүгеннән башлап үз продукцияләрен китерергә әзер. Моннан тыш, «Заря» агрофирмасы төрле авыл хуҗалыгы культураларын үстерү мәйданын 400дән 700 гектарга кадәр арттырырга планлаштыра. Кешеләрнең шәхси бакчаларын һәм 80 бакча кооперативы потенциалын да исәптән төшерергә ярамый.

– Бүгенге көндә сез ирешкән уңышларның аеруча мөһим булганнары турында да сөйләгез әле.

– Биредә муниципалитетларның социаль-икътисадый үсеше рейтингы аерым индикатор булып хезмәт итә ала. Гыйнвар-май нәтиҗәләре буенча без 6нчы урында, ә узган елның шул ук чорында исә бары тик 16нчы урында гына булганбыз. Сәнәгать предприятиеләре керткән өлеш зур – Кураловодагы «Таткрахмалпатока», куас сосласы һәм солод экстрактларын җитештерү шактый яхшы әйләнеш алып килә. Яр буе Морквашидагы «Вельветте Марин» верфе бүгенге көндә берничә классы унбер төрдәге заманча катерлар чыгара. Суыртып агызу насос станцияләренә һәм композит материаллар, тиз төзелә торган йортлар һәм тимер-бетон эшләнмәләрен эшләп чыгару буенча цехка комплектлау частьләрен эшләп чыгару өчен СПИ станокларында металл эшкәртү буенча предприятиеләр үзен яхшы яктан күрсәтте.

> – Биредә муниципалитетларның социаль-икътисадый үсеше рейтингы аерым индикатор булып хезмәт итә ала. Гыйнвар-май нәтиҗәләре буенча без 6 нчы урында, ә узган елның шул ук чорында исә бары тик 16 нчы урында гына булганбыз.

– Ә җирле халык үзгәрешләрне ничек кабул итә? Яңа җитештерүләр ачылуга ничек карый?

– Югары Осланда яшәүчеләр арасында Казанда эшләүчеләр күп. Аларны шәһәр кешеләре дип тә атарга мөмкин. Ә менә авыл җирлекләре өчен «Таткрахмалпатока», «Югары Ослан агрофирмасы», «Керамика Синтез», «Ключищи керамикасы» кебек предприятиеләр – кешеләрнең мәшгульлеген тәэмин итә торган бюджет булдыручылар булып тора. Димәк, минемчә, халык үзгәрешләрне уңай кабул итә.

– Сезнең еллык докладыгызда, аерым алганда, үзара салым җыю процессын активлаштыру турында сөйләнелә.

– Әйе, бу безнең өчен мөһим момент. Монда да, безнең шәһәр яны үзенчәлеген истә тотып, шуны әйтергә мөмкин: унөч авыл җирлеге халкын программага җәлеп итү – үз үк алга таба шактый зур адым. Мондый активлык барлыкка килү – үз авылыңа, үзеңнең кече Ватаныңа битараф булмау билгесе. Моннан тыш, быел барлык авыл җирлекләре буенча референдумнар узды, яртыеллык азагына халыктан 100% күләмендә диярлек акча җыеп алынган инде. Акчаны нигездә юлларны ремонтлауга, зират коймасына, контейнерлы мәйданчыклар, сууткәргечләрне төзекләндерү өчен җыялар. Кертем күләме гадәттә 350–450 сум. Әлеге процесс бездә бик тиз бармый, шулай да лидерлар бар – Мәйдан авылында, мәсәлән, инде икенче ел рәттән референдумнар үткәрелә. Сүз уңаеннан, XVII гасырда Мәйданда укчыларны урнаштыра торган булганнар. Ягъни бу – тарихтан килгән мөстәкыйльлек һәм җаваплылык.

– Сез күпләрнең Казанда эшләве турында әйтеп үттегез? Ә яшьләр? Китәләрме, калалармы?

– Яшьләр белән эшләү – ул аерым бер зур юнәлеш. Әлбәттә, Казанга укырга киткәннәрнең күбесенең кире әйләнеп кайтасы килми. Без хәзер әлеге яшьләр күңелендә үз йортлары, үз җирләре, тамырлары турындагы истәлекләр барлыкка килеп, алар өчен җаваплылык хисе тусын өчен эшлибез. Нәкъ менә шул патриотизм була да инде, әмма ул буш урында гына барлыкка килми. Җиңүнең 70 еллыгына без һәр авыл җирлегендә Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларыбыз исемлеген урнаштырдык. Район үзәгендә Геройларның мемориаль паркы ачылды. Тыл хезмәтчәннәре скверын төзү тәмамланып килә. Соколка тавында Россиядә Гражданнар сугышы башлануга йөз ел тулуга багышланган, ул куркыныч вакыйгаларда катнашучыларның килешүе һәм тәүбәгә килүенең символы буларак калкып чыга алган тарихи-ландшафт паркы төзү буенча планнар бар. Миңа калса, бу бик мөһим. Яшүсмерләр үз бабайларының фамилияләрен күргән чакта аларның нәкъ менә балалары, оныкларының киләчәге өчен башларын салуын аңлый. Үз җирең өчен батырлык эшләү – буш сүз түгел.

– Ә сез үзегез әлеге якның патриотымы?

– Әлбәттә. Мин биредә, Макыл авылында туганмын. Авыл хуҗалыгы институтында укыр өчен генә китеп тордым туган авылымнан. Бөтен тормышым монда, Югары Ослан җиренең һәр карышын беләм. Безнең район – үзенчәлекле ул, матур ул, кызыклы ул. Һәм мин аның киләчәктә динамик, инновацияле рәвештә үсә торган территория булуын телим. Югары Ослан районында яшәүчеләр моңа лаек.

> – Яшьләр белән эшләү – ул аерым бер зур юнәлеш. Әлбәттә, Казанга укырга киткәннәрнең күбесенең кире әйләнеп кайтасы килми. Без хәзер әлеге яшьләр күңелендә үз йортлары, үз җирләре, тамырлары турындагы истәлекләр барлыкка килеп, алар өчен җаваплылык хисе тусын өчен эшлибез.

PRESSA.RU

Менә 13 ел инде «Кызыл Шәрык» агрохолдингының Югары Ослан филиалы районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре арасында лидерларның берсе булып тора. Компания предприятиеләрендә өч йөзгә якын кеше генә эшләүгә карамастан, җитештерү күләменә шаккатырлык.

КОЯШ КӨНЧЫГЫШТАН ЧЫГА

«Кызыл Шәрык» агрохолдингы инвестицияләре килү белән тулаем продукция күләме дүрт мәртәбә артты.

2015 ел эчендә генә дә 12,2 мең тонна югары сортлы кайнамаган сөт тапшырылган. Ә бит әле 14–15 ел элек кенә Югары Ослан районының барлык авыл хуҗалыгы предприятиеләре 9 мең тонннадан да кимрәк сөт эшләп чыгарган, бер баш сыердан савым 3 мең литрдан артмаган. Район республикада әлеге күрсәткеч буенча тотрыклы рәвештә иң соңгы урыннарда булган.

«Кызыл Шәрык» агрохолдингы тарафыннан кертелгән инвестицияләр һәм заманча технологияләрне куллану унөч ел дәвамында тулаем продукция күләмен дүрт мәртәбә диярлек, шул исәптән ит һәм ашлык эшкәртүне – ике, сөтне алты тапкыр арттырырга мөмкинлек бирде.

Безнең көннәрдә «Кызыл Шәрык Агро» ААҖ, «Идел буе Токым эше» ҖЧҖ һәм «Шәрык Зернопродукт» АҖ компанияләренең авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче предприятиеләре – Югары Осландагы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир мәйданнары буенча иң эреләр арасында. Предприятиеләрдә югары сыйфатлы сөт җитештерелә, югары продуктлылыкка ия токымлы яшь терлекләр үстерелә, ашлык эшкәртелә һәм саклана.

Узган елны ашлыкның тулай җыемы 17,5 мең тоннага җиткерелде. Сүз уңаеннан, «Кызыл Шәрык» агрохолдингы килгәнче, соңрак филиал составына кертеләчәк хуҗалыкларда бөртеклеләрнең тулай җыемы бары тик 7,1 мең тонна тәшкил иткән.

2015 елда азыкны да мулдан әзерләдек – 14,5 мең тонна азык берәмлегенә кадәр. Ә ул, һәркемгә мәгълүм инде, терлекчелекнең нигезе: мал-туарны ничек ашатасың, шуның кадәр яхшы сөт алачаксың.

Сөт терлекчелеге – «Кызыл Шәрык» агрохолдингы эшчәнлегенең төп юнәлеше. Хәзер Югары Осланда хайваннарның физиологик ихтыяҗларын, көтү үзенчәлекләрен истә тотып проектлаштырылган заманча сөт комплекслары эшли. Биредә аларны тоту өчен бик уңайлы һәм җайлы шартлар тудырыла. Заманча саву залларында – югары технологияле «Де Лаваль» техникасы, ул бер сыердан елына 6 500 литр сөт савып алырга ярдәм итә.

> **Район башлыгы Марат Зыятдинов:** «Терлекчелекнең нигезе – ул баш саны. «Кызыл Шәрык» агрохолдингы җитәкчеләре һәм белгечләре моны бик яхшы аңлый һәм аның тотрыклылыгын тәэмин итәргә тырыша. «Макыл» комплексы терлекчеләре 2015 елда мөгезле эре терлек санын һәм аның продуктлылыгын арттырды. Нәтиҗәдә сөт һәм ит җитештерү күләме артты».

БЕЛЕШМӘ

«Кызыл Шәрык» агрохолдингы килгәнче, Югары Ослан районы республиканың иң депрессив территорияләренең берсе булып тора иде. Район администрациясе башлыгы Владимир Осянин үтенече буенча, 2003 елның мартында компания, АСК үстерү дәүләт программасы кысаларында инвестицияләү проектын гамәлгә кертеп, райондагы авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү тармагын күтәрергә карар кыла. Ул вакытта районның 15 мең гектардан артык җире ташландык хәлдә, машина-трактор парклары һәм терлекчелек фермалары җимерелгән, кыр эшләрен үткәрү өчен техника һәм акча җитми, ә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре еллар буе хезмәт хакы алмый торган була.

«Кызыл Шәрык» агрохолдингы хуҗалыкларында 2015 елда 3057 баш үрчем алынган, ә бу уртача 100 сыерга 84 бозау дигән сүз. Һәм гаҗәп тә түгел. Бозаулар конвейердан гына төшеп торган «Макыл»да, мәсәлән, үрчем өчен бер атналык вакытларыннан ук тулы бер «перинаталь» бүлек эшли. 1 июльгә карата Югары Ослан филиалы буенча мөгезле эре терлек саны 7282 башны тәшкил итте.

Бүгенге көндә агрохолдинг карамагында 26,1 мең га җир бар, шуларның 19,3 мең гектары – сөрү җирләре. Уңдырышлылык гектарыннан 30 центнер тәшкил итә, бу район өчен яхшы күрсәткеч булып тора.

2004 елның августында «Кызыл Шәрык» агрохолдингы инвестицияләре ярдәме белән тулысынча реконструкцияләнгән «Макыл» мегафермасы куллануга тапшырылды. Биредә хәзер 5500 савым сыеры бар. Сөт комплексы көн саен 34 мең тоннадан артык күләмдә югары сортлы сөт сата.

13 ел эчендә «Кызыл Шәрык» агрохолдингының Югары Ослан филиалын үстерүгә 2,8 млрд сум инвестицияләнгән. Шуларның:

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга – **1,4 млрд;**

ашлык кабул итү предприятиесен, складлар һәм ындыр табаклары төзүгә – **0,05 млрд;**

терлекчелек биналары төзүгә һәм реконструкцияләүгә – **1,35 млрд.**

Реклама

Ужым басуларын сөрү.

Ашлык җыю.

ИДЕЛ АРЪЯГЫНДА

«Идел арьягы» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖ бүлекчәләре Югары Ослан районының Карагуҗа, Мәйдан, Олы Мәми, Шеланга, Канаш авылларында һәм Яшел Үзән районының Бишнә авылында урнашкан. АСК «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ составына керә.

«Идел арьягы» АСК эшчәнлегенең төп юнәлеше булып үсемлекчелек тора. Сөрү җирләре күләме 17 мең гектар. Өч мең баш мөгезле эре терлекләре бар, шуларның 860ы – савым көтүе.

Предприятие директоры, ТР авыл хуҗалыгының атказанган хезмәткәре Ильяс Габбазов сүзләренчә, хәзерге вакытта тулы куәткә уҗымнарны, азык әзерләү һәм урнаштыру эшләре бара.

– Көзге культуралар әлегә бик шатландыра, – ди ул. – Уртача уңыш – гектарыннан 32 центнер, бу Югары Ослан өчен бик яхшы күрсәткеч. Бөртеклеләрнең барлык 11,5 мең гектарыннан 3650 гектарны уҗым культуралары тәшкил итә. Әмма быел без аларның мәйданын 4005 гектарга кадәр арттырачакбыз.

Директор сүзләренә караганда, күпьеллык үсемлекләрнең беренче чабымы күптән тәмамланган, икенче чабымнан һәм берьеллык үсемлекләрдән азык әзерләүгә керешкәннәр. Әмма инде аннан башка да, бер шартлы баш өчен 22,5 центнер азык берәмлеге исәбеннән, мал-туар азык белән яхшы тәэмин ителгән.

18,5 мең тонна сенаж һәм 1600 тонна печән хәстәрләнгән. Чиратта тагын кукуруз әзерләү – ул 650 гектар мәйданда үсә.

Азыкның артыгы ярдәмендә акча эшләп алырга да була. Шулай, узган елда предприятие үз холдингының Буа һәм Апас, Кайбыч һәм Чүпрәле районнарындагы агрофирмаларына ярдәм итте. «Кызыл Шәрык» агрохолдингы да өстәмә азыкны әлегә предприятиедән сатып алды.

– «Сөт – сыерның телендә» дип юкка гына әйтмиләр. Яхшы ашатасың икән – сөт була. – ди директор. – Карагуҗада без быел комплекс буенча тугызар тонна сөт савабыз. Узган елгы күрсәткечләрне киметмибез. Әмма кысыр таналар бар, алардан да тагын бозаулау һәм сөт көтәбез.

2,5 ел дәвамында эшләү эчендә терлекчелек фермалары тулысынча реконструкцияләнде. Бөтен җирдә сөтүткәргечләр яки саву заллары, кул эше бөтенләй калмады диярлек. Карагуҗада 2015 елда реконструкциядән соң заманча җиһазландырылган яңа югары техногияле сөт-товар комплексы эшли башлады, Мәйданда 2014 елда 1000 башка мөгезле эре терлекне симертү өчен мәйданчык төзелде. Шелангадагы сөт-товар фермасын реконструкцияләүдән соң, биредә савым көтүе 200дән 300 башка кадәр үсәчәк.

Даими рәвештә 220 кеше хезмәт итә торган предприятие, ә сезон вакытында аларның саны 270кә җитә, зыянсызга эшли. Терлекчелекнең рентабельлелеге – 10, ә ашлык җитештерүнеке – 13 процент. Уртача хезмәт хакы – 18 мең сумнан артык, бу райондагы авыл хуҗалыгы предприятиеләре арасында иң югарылардан санала.

«Идел арьягы» АСК зур социаль эш алып бара. Предприятие катнашында Карагуҗада балалар бакчасының яңа бинасы төзелде, балалар өчен – уенчыклар, җирле мәктәп өчен спорт җиһазлары сатып алынды. Мәктәп укучыларына республика һәм Россия спорт ярышларында катнашыр өчен акча бүлеп бирелә. Украинадан гаиләләре белән күчеп килгән хезмәткәрләр өчен ике шәхси йорт төзелде. Торак пунктларны төзекләндерүгә, чиркәү һәм мәчетләрне реконструкцияләүгә ярдәм күрсәтелә.

Реклама

Симертү мәйданчыгы.

Комплекс.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ СӨЛӘЙМАН БАЛЫГЫ

«Дивный берег» ҖЧҖ балык продукциясен җитештерү заводы 2005 елдан бирле эшли. Компания ышанычлы рәвештә Татарстан базарында беренчелекне били, һәм ул Россиянең күп кенә регионнарында киң танылу алган. Компаниянең партнерлары – «Перекрёсток», «Пятёрочка», «Магнит», «Карусель», «Ашан», «Метро», «Зельгрос», «Бәхетле», «Эссен» эре федераль челтәрләре...

«Дивный берег» ҖЧҖ продукциясенең ассортиментында 90 исемдәге тозлы, ысланган, какланган балык һәм башка төрле диңгез продуктлары бар. Югары Ослан авылында урнашкан заводта керкә, сөмбаш, горбуша, кета, сельдь, скумбрия, майлы балык, мойва, диңгез кысласы, мидияләр, кальмар эшкәртелә. Чыгуда – төрле зурлыктагы полиэтилен банкаларда пресервлар, вакуум төргәктәге бөтен һәм кисәкле балык, сырт ите, балык кисәкләре, сыра өчен җыелмалар, диңгез продуктларыннан коктейльләр. Барлык продукциянең куркынычсызлыгы норматив документларга туры килү турында декларацияләр белән раслана. Заводның ике лабораториясе бар, биредә иң мөһим физик-химик һәм микробиологик күрсәткечләр тикшерелеп тора.

2014 елдан импортны алыштыруга таба йөз тотылды. Моңа Норвегиядән сөләйман балыгын кертүне тыю сәбәп булудан битәр, халыкның сатып алу мөмкинлеге кимү һәм сатып алучыларның «сары» бәяләргә күбрәк игътибар бирүен ассызыклаган сәүдә челтәрләренең теләге торды.

– Бүген завод сатып алучыларның төрле төркемнәрен канәгатьләндерергә тырыша, – диде «Дивный берег» ҖЧҖнең генераль директоры Галия Радионова, – аларга сорау шактый кимесә дә, кыйбатлы балыклардан – керкә, сөмбаш һәм барыбызның да алырга мөмкинлеге булган халыкчан сельдь та сатуда калды. Импортны алыштыру кысаларында без Ерак Көнчыгыш сөләйман балыгыннан: кета, горбуша, кызыл балык, кижуч, голецтан продукция эшләп чыгаруны арттырабыз. Безнең өчен яңа булган балык төрләре белән даими рәвештә төрле экспериментлар үткәрәбез, тозлау һәм әзерләүнең оригиналь рецептларын уйлап чыгарабыз.

Шунысы да бар: сатып алучылар үзебездә җитештерелгән сөләйман балыгының арзанрак кына түгел, ә импорт аквакультурага караганда файдалырак булуын да шактый тиз арада аңлап алдылар. Чөнки чит илдә балыкны ачык сулыклардан тотмыйлар, ә бройлерлар кебек үстерәләр, аңлашыла инде, ясалма өстәмәләр кулланып ашаталар да.

Югары технологияле чимал, табигый көнбагыш мае һәм тәмләткечләр нигезендә завод хезмәткәрләре (ә аларның саны 200ләп) ел саен 400 млн сумлык өч мең тоннадан артык экологик яктан чиста продукция җитештерә. Балык продукциясе сыйфаты, компаниянең сыгылмалы бәяләр сәясәте һәм Түбән Новгород, Ульяновск, Самара, Киров, Ижевск, Уфа һәм Нефтекамск, Пермь һәм Березнякта, Саратовта, Чиләбедә, Екатеринбург һәм Оренбургтагы дистрибьюторларның төгәл төзелгән эше нәтиҗәсендә Идел буе–Урал регионы базарларында ихтыяҗ шактый зур. «Дивный берег» сәүдә маркасы белән чыга торган балык һәм диңгез продуктлары шулай ук Мәскәүдәге «Бәхетле» кибетләрендә дә тәкъдим ителә.

Предприятиедә программа ярдәмендә идарә ителә торган югары җитештерүгә китерүче импорт җиһазы куйдырылган: порционер, төргәкләү өчен термоформерлар, югары технологияле куәтле ыслау пичләре. Планда – балыкны өлешләргә бүлү, май салу һәм пресервлы банкаларны ябу өчен автомат линия булдыру.

Заводның эшләү дәверендә «Дивный берег» продукциясе берничә мәртәбә «Россиянең иң яхшы 100 товары» һәм «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» бәйгеләре лауреаты дипломнарына лаек булды.

2016 елда заводта этаплап ХАССП сыйфатны тикшерүнең Европа системасы принциплары гамәлгә кертелә.

Реклама

Реклама

ИТАЛИЯ СТИЛЕНДӘГЕ
ПРЕМИУМ ЯЛ

«Кабан күле хәзинәләре» фильмындагы вамп-ханымның бруталь катеры тамашачыларның күбесенә үзенең чит илнекенә генә хас була ала торган кәттәлеге һәм нәзәкатьлелеге белән истә калгандыр, мөгаен. Шул ук вакытта ул – Россиянең пыяла-пластиктан ясалган 5–12,5 метрлы кече суднолар сегментында иң эре җитештерүчесе булган Югары Осланның катерлар һәм премиум-класслы яхталар чыгара торган Вельветте Марин верфе продукты.

Җитештерү 2007 елда арендага алган остаханәләрдә хәзер дә иң популяр булып кала биргән 6 метрлы Velvette 20 Image[1] көймәсен чыгарудан башлана. Бер ел эчендә компания елына 100 катер чыгаруга ирешә.

– Волга машинасы, көймәләр белән кызыксынуым күптәннән бар иде, – ди компаниягә нигез салган һәм аның директоры булган Михаил Клопоух. – 80нче еллардан ук дусларым белән Боровое Матюшинода суда ял иттем: йөгерә, балык тота, бабайларыбызның «дюралька»ларын һәм асылмалы моторларын ремонтлый идек. 1998 елда иптәшем белән икәүләп «Амур» катерын җыйдык: кулланышта булган корпусны ремонтладык, таныш моторчы белән «Волга»дан калган движокны яңадан җыйдык. Әлеге тәҗрибә яңа бизнес башлау өчен этәргеч булды да инде.

Әле 90 нчы елларда, юрфак студенты чагында, Михаил клуб дискотекалары оештыра башлый. 23 яшьтә Казанда иң эреләрдән саналган «Арена» төнге клубының генераль директоры вазыйфасын үти башлый ул, ә 2003 елдан үзенең даими компаньоны Константин Иванов белән «Бохра»дагы «BeerЛожа» дип аталган беренче рестораннарын ача. Хәзер OFS[2] челтәре исәбендә дистә ярымнан артык ресторан бар.

Суднолар төзү бизнесы өчен яңа дәвер «Ямаха»ның Казан янында япон көймәләрен җитештерүне урнаштыру буенча тәкъдименнән башлана. «Ямаха» контроле астында менеджмент һәм сыйфатны тикшерү системасы оештырыла, үз КБлары барлыкка килә. Yamaha FR 23 Active Sedan[3] катерын һәм премиум-класслы Image[4], Euphoria[5], Envy[6] катерлары гаиләсен серияле чыгару башлана.

2010 елда Югары Ослан районында компания яңа заводны эшләтеп җибәрә, аны техник яктан җиһазлау тулысы белән premium класслы катерлар төзүгә карата булган халыкара таләпләргә туры килә. Ике елдан соң компания Evolution[8] һәм Intelligent[9] брендлары белән бергә, Faserind[7] суднолар төзү верфен сатып ала: шул рәвешле сызымнар, калыплар, технологияләр ярдәмендә модельләр рәтен яхталар һәм катерларның 6 гаиләсенә кадәр киңәйтә һәм 10 метрдан 12,5 метрга кадәрле кораблар базарының яңа сегментына керә.

Бүген көймәләрне җитештерү дәрәҗәсе, дизайн һәм функциональ чит ил катерлары белән уңышлы көндәшлек итә, Дюссельдорфтагы Үзәк Европа яхталар һәм катерлар күргәзмәсенә чыгу планы җентекләп өйрәнелә. Компания 11 модель чыгара, өчесе өчен, заказчы сайлавы буенча, алюминий яки пластиктан ясалган корпус үзләштерелгән. Алты модель «Вольво» двигателе белән бара, бишесе – клиент теләгенә карап, асылмалы моторлы булырга мөмкин. Узган елдан бирле фин технологияләре буенча балык тоту һәм ял өчен пластик һәм катнаш төрдәге (пластик белән алюминий) корпуслы Velvette 16 Prime[10] һәм Velvette 18 Prime[11] катерлары чыгарыла.

Һәр көймәнең үз билгеләнеше бар: кемгәдер балык тоту өчен кирәк, кемгә – гаиләсе белән сәяхәт итү өчен. Су өстендә кичәләр үткәрәсе килүчеләргә пляж көймәсе бара. Компаниянең модельләр рәте техник, дизайн, функционал ягыннан бик бай: балык тотучыларныкыннан алып каюталы көймәләргә кадәр. Кабиналы Velvette 23 Active Sedan[12] һәм «судагы дача» – 12,5 метрлы яхта Velvette 41 Evolution[13] тә бар. 2013 елдан тиз йөри торган (сәгатенә 120 км га кадәр тизләкле) катер Velvette 27 NGT[14] ачык, агрессив дизайнлы спорт моделе чыгарыла. Спорт һәм бизнес йолдызлары өчен – тендер тибындагы яхта Velvette 33 INTELLIGENT[15]. Кинодагы судно – 2012 елда Казан дизайнеры Ленар Мөхетдинов тарафыннан эшләп чыгарылган авторлык продукты. Әлеге стильдә Европада берничә оешма гына эшли: Голландиянең Van Dutch[16] һәм Норвегиянең Fjord[17], ә Америкада – беркем дә юк. Сүз уңаеннан әйтеп китик, әлеге стильгә, Wally[18] гә нигез салучы Лука Бассани тәкъдим иткән яхталар бик зур һәм 30–50 млн евро тора, ә Velvette[19]ның бәясе исә 100 мең евродан башлана.

– Сатып алучылар бөтен Россиядән килә, – ди Михаил. – Үсәбез һәм, импортны алыштырып, киң таралабыз. Элек чит ил көймәләре безнекеләргә караганда 30 процентка кыйммәтрәк иде, ә курсның үсүе белән бәяләр ике мәртәбә артты. Аларны хәзер кертмиләр дә диярлек: безнең илгә кертү пошлинасы һәм ӨКС (өстәмә кыйммәткә салым) 42 процентка кадәр җитә, тагын 15–25 процентны дистрибьютор өсти. Без исә көймәләрне дилерлар челтәре аша 15 шәһәрдә сатабыз һәм аны киңәйтеп торабыз. Шулай итеп, кемгәдер – кризис, ә безнең өчен – алга таба үсү мөмкинлеге.

[1] Velvette 20 Image – Вельветте 20 Имэдж. [2] OFS – бөтен шәһәр буенча төрле рестораннарның зур челтәренә ия булган идарә компаниясе. [3] Yamaha FR 23 Active Sedan – Ямаха FR 23 Актив Седан. [4] Image – Имэдж. [5] Euphoria – Эйфория. [6] Envy – Энви. [7] Faserind – Фазеринд. [8] Evolution – Эволютион. [9] Intelligent – Интеллиджент. [10] Velvette 16 Prime – Вельветте 16 Прайм. [11] Velvette 18 Prime – Вельветте 18 Прайм. [12] Velvette 23 Active Sedan – Вельветте 23 Актив Седан. [13] Velvette 41 Evolution – Вельветте 41 Эволютион. [14] NGT – табигый газ нигезендәге технология. [15] Velvette 33 INTELLIGENT – Вельветте 33 Интеллиджент. [16] Van Dutch – Ван Дач. [17] Fjord – Фьёрд. [18] Wally – Валли. [19] Velvette – Вельветте.

PRESSA.RU

Ю

РОССИЯ КУАСЫНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН ЧЫГАНАКЛАРЫ

«Мәскәү куаслары уңышлы булып чыксын өчен, җиләкләрнең, һичшиксез, өлгергән һәм яңа җыелган булуы кирәк, югыйсә куас тәмсез булачак. Мондый куаслар авылда иң арзанлы һәм салкын эчемлек, җиләкләр дә бушлай; аларны шешәләрдә әзерләү яхшырак, чөнки мичкә һәм кисмәкләр кайчакта агызырга мөмкин. Әмма кура җиләге һәм җир җиләге куасын капкачлы кисмәктән башка савытларда ясарга ярамый, аларның һәрвакыт ябык һәм боз эчендә булуы шарт».

(Елена Молоховец «Яшь хуҗабикәләргә бүләк, яки Өйдәге хуҗалыкны алып барганда чыгымнарны киметү чарасы» (1901))

Югары Ослан районында, мөгаен, дәрәҗәле «Мәскәү куасларын» кайнатканнардыр, чөнки монда җиләк-җимеш һәрчак мулдан булган. Бу искиткеч эчемлекнең бүгенге күләмдә кулланылуы, бәлки, аны әзерләүнең изге серлелеген юкка чыгарадыр, әмма куас сосласын җитештерүнең югары технологияләрендә дә серләрсез булмый.

ВИСКИ ДА КҮЗДӘ ТОТЫЛА

Элекке спиртзаводның XX гасыр башы кирпеч корылмалары ишегалдында көтелмәгәнчә аклы-зәңгәрле төстәге өр-яңа кайнату цехы кукраеп утыра. Сизелер-сизелмәс әчкелт арыш икмәге исе корыч исе белән аралаша: мондагы процесс башыннан ахырынача автоматлаштырылган, металл тегерменнәр, чаннар, конверторлар, фильтрлар эченә «тутырылган».

– 1905 елда сәүдәгәр Обухов биредә чимал спирт җитештерүче завод төзегән. 1985 елга кадәр уңышлы гына яшәп килгән бу предприятиедә Кураловоның бөтен халкы эшләгән, – дип, экскурсия үткәрә безгә Альберт Прокопьев. Ул, Казан кешесе, КХТИны тәмамлагач, 1987 елда бирегә эшкә билгеләнгән. Элекке спирт заводы цехлары ул чакта «Таткрахмалпатока» дәүләт предприятиесенә тапшырылган. Шулай итеп, аның директоры итеп билгеләнгән Альберт Иванович Кураловога килеп эләккән.

– Завод ул чакта мальтоза патокасы җитештерә иде, аннары куас сосласы концентраты чыгара башлады. Совет линияләре 2014 елга кадәр эшен суза алды. Аннары түзеп булмый иде инде. Без, кредитлар алып, бөтен җиһазларны бельгиянекенә һәм немецныкына алыштырдык. Идарә итү системаларын хорватлар монтажлады, – дип дәвам итә Альберт Иванович. – Хәзер без экстракт чыгышының 100%ын алабыз. Чыгымнарны киметү продукциянең яхшы сыйфаты белән бергә әйбәт бәяләр тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә. Соңгы елларда клиентларыбызның саны артты – куас җитештерүчеләр күбәйде, быел, мәсәлән, Бочкарёво сыра кайнату заводына куас сосласы концентраты тапшыру тендерын оттык.

Бүген «Таткрахмалпатока» куас сосласы концентраты, арыш һәм арпа солодлары экстрактлары, арыш һәм солод мальтоза патокасын җитештерә. Барысы да – Татарстан һәм күрше төбәкләрнең үз кырларында үстерелгән чималдан.

– Нәрсәнедер яхшырта башласаң, икенчесен дә яхшыртырга кирәклеген сизәсең. Бервакыт, исәпләп карагач, ферментацияләнгән коры арыш солоды (ул куас сосласы составына керә) өчен кирәкле арышны, сатып алуга караганда, үзең үстерү отышлырак икәнен аңладык.

Ике түтәлле солодовня төзедек. Бүген ул безнең бөтен ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерә. Безнең әле тагын яшел солод җитештерү корылмасы да бар. Безнең солод экстрактын сыра һәм виски җитештерүдә дә кулланып була. Сыра кайнату заводлары бездән аны акрынлап сатып ала башлады инде. Виски җитештерүчеләр мөрәҗәгать итмәде итүен, әмма кем белә, – ди Альберт Иванович.

Заводка үз лабораториясе хезмәт күрсәтә, андагы хезмәткәрләр сәгать саен чимал һәм продукциянең сыйфатын тикшерәләр. Лаборатория клиентка йөз белән карарга мөмкинлек бирә: сосла һәм экстрактларның төсен, тәмен һәм исен заказчы теләгәнчә сайларга булыша. Мәсәлән, солод экстрактында амино-азот күләмен арттыра ала. Шул хисапка сыра җитештерү заводы әчү процессын тизләтә. Ә бу югары сезон чорында аеруча актуаль.

КЫТАЙЛАР УЯНДЫ ДА КУАС ТАЛӘП ИТӘ

Без цех буйлап йөрибез, ә директор куас сосласын сатып алучыларны санап күрсәтә: Новгород «Дека»сы («Никола» куасы), «Бочкарёво» сыра кайнату заводы, «Вятич» (әлеге дә баягы «Вятский квас»), PepsiCo* («Русский дар» куасы) һ.б.

– Бөтен Россия куасны Югары Ослан концентраты нигезендәге эчә булып чыга инде?

– Теоретик яктан (шундый зарурилык туса) һәм гамәлдә (егәрлекләр мөмкинлек бирә) без Россия территориясендә эшләгән барлык куас җитештерүчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерә алабыз.

– Ә экспортка ни дә булса каламы?

– Әлбәттә. Безнең барлык БДБ илләрендә, Польшада, Канадада, АКШта партнёрларыбыз бар. Кытай уянды һәм куас эчәсе килә башлады. Гомумән, миңа татлы газлы сулар эрасы бетеп бара кебек тоела. Эре җитештерүчеләр котылу юлын эзли, шуларның берсе – куас җитештерү.

Операторлар бүлмәсенә керәбез. Бер егет белән кыз дүрт монитордан технологик процессны күзәтә.

– Заводның йөрәге – ул майшфильтр. Бирегә пешерелгән һәм шикәрләнгән ашлык чималының тыгызландырылган массасы килә. Майшфильтр шул массаны түп белән сиропка аера, соңгысы, парга әйләндерү өчен, немецлардан алынган җайланмага озатыла. Аларның төп өстенлеге шунда: сироптан 50% дым чыгарыла. Процесс бик тиз бара, һәм канцероген матдәләр хасил булу куркынычы калмый, – дип сөйли баш технолог Ольга Победа.

– Бездә барысы да максималь дәрәҗәдә автоматлаштырылган: сосла концентраты җитештерүнең бөтен линиясендә, әзер чимал белән эшләүче персоналны санамаганда, нибары дүрт кеше эшли, – дип сөйли җитештерү башлыгы Елена Хәсәнова. – Әмма бу технологик камиллеккә дә җитештерүне һәм автоматика белән идарә итүне бердәй яхшы аңлаган белгеч таләп ителә. Авылда мондый белгечләр юк. «Таткрахмалпатока»ны ул яктан «бәхет басты»: Альберт Иванович КМТТУның аттестация комиссиясенә җитәкчелек итә, һәм безнең операторларны – вузны иң яхшы тәмамлаучы инженер-технологларны үзе сайлап алды. Егетләр бирегә Казаннан сменалап килеп йөри.

КУРАЛОВОНЫҢ ТӨП ЧАҢЫ

– Бездәге хезмәт хаклары район өчен ярыйсы гына көндәшлеккә сәләтле булып – 20–40 мең сумны тәшкил итсә дә, без кадрлар кытлыгын да шактый сизәбез. Әле ачылган гына чагыбызда, бөтен көйләүчеләр, инженерлар һәм төзүчеләр бирегә Казаннан, башка шәһәрләрдән һәм хәтта чит илләрдән дә килә иде. Шул сәбәпле, Кураловода хәтта кунакханә дә төзедек. Кайчакта анда өстәмә сменада калырга тиеш булган хезмәткәрләр туктала, – дип, Альберт Прокопьев механизмы шушы дәрәҗәдә көйләнгән предприятие өчен гаҗәбрәк тоелган проблемалары белән уртаклаша. – Югарырак вазыйфалар белән мәсьәләне без ничектер хәл иттек әле, алай дисәң, әлегәчә баш инженерыбыз юк. Әмма, җитештерүдән тыш, безнең шушы җитештерүгә хезмәт күрсәтә торган авыл хуҗалыгы юнәлешебез дә бар бит. Без үз арыш, арпабызны үстерә башладык, бәяләр үсүгә бәйле булмас өчен, элеватор төзүне күздә тотабыз. Ә түпне малларга ашатабыз – герефорд нәселле 400 баш мөгезле эре терлек асрыйбыз. Һәм безгә квалификацияле эшче профессиясенә ия белгечләр җитешми! Урта һөнәри белемгә ия белгечләр чыгару бөтенләй туктатылган кебек тоела хәтта.

«Таткрахмалпатока» ААҖ составында бер Казан заводы да бар. Эш фронты кечкенә түгел. Әмма Югары Ослан Штольцы, күрәсең, ару-талуны белми: узган ел Альберт Прокопьев Югары Ослан районы депутаты итеп сайланган.

– Завод ачылганнан соң, Обухов Куралово халкына нәрсә төзергә – мәктәпме, чиркәүме, дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән. Халык мәктәпне сайлаган. Әмма ул күптән ябылган инде. Ә без «Неупиваемая чаша» Мәрьям-Ана иконасы чиркәвен торгызуда катнаштык. Обуховның үе, ниһаять, тормышка ашты, – дип сөйли Альберт Иванович. Алты чаңны алып кайтырга дип, Прокопьев чиркәү башлыгы – Николай атакай белән Киров өлкәсенә барган. Чаңның иң зурысы – 260 кг.

– Минемчә, кешедә иман булмаса, аның эчендә бушлык барлыкка килә, һәм анда теләсә нәрсә килеп тула, өстә генә торган, матди теләкләр канәгатьләндерелә. Ә мин кешеләрнең матур итеп, шатланып яшәвен телим.

Цехның тышкы ягындагы иртәнге җиләслек көндезге челлә дулкыны белән алышынды. Бу җәйнең эсселегенә караганда, заводны да заказ дулкыннары, юк – цунамилары көтә. Әмма «Таткрахмалпатока»га мондый күтәрелешләр куркыныч түгел: көндәшләреннән аермалы буларак, ул кыш көне дә тик тормый, ә продукцияне складка чыгара. Монда барысы да сәгать кебек төгәл эшли.

Ярты көн җитүен белдереп, Куралово чаңы кага. Майшфильтр яңа циклын башлый.

Реклама

ЮГАРЫ ОСЛАННЫҢ СӨТ ЮЛЫ

– Тыгызлыгы – 28, әчелеге – 18, антибиотиклар барлыгы беленмәде, – радиодиктор тавышы белән шулай итеп тыныч кына белдерә лаборант Ольга Шаронова, ареометр күрсәткечләренә карап. Һәм өстәп куя: – Югары сортлы сөт.

ПАКЕТЛАРДАГЫ АРИФМЕТИКА

Без Югары Ослан агрофирмасы ҖЧҖ лабораториясенең кабул итү бүлмәсендә. Хәзер монда Арчадан килгән яңа сөт партиясенең сыйфатын тикшерәләр. Аннары аны эшкәртергә җибәрәчәкләр – коры сөткә, пастеризацияләнгән эчә торганга яки «Крестьян мае»на. Үз машиналары көн саен заводка Татарстанның төрле почмакларыннан 70-80 тонна сөт алып кайта.

– Сөтне чит төбәкләрдән, мәсәлән, Мари Элдан сатып алган чакларыбыз да бар иде, – дип сөйли агрофирманың генераль директоры Рөстәм Гайнетдинов. – Әмма бүгенге көндә безнең Татарстанда да яхшы тәэминатчылар җитәрлек.

Ә «Югары Ослан» продукциясенең сыйфатын без үзебез үк бәяли алдык. Регламент буенча бирегә сөт белән майны көн саен директорлар да, баш технолог та кабып карый. Үзләрендә сыный, кем әйтмешли. Без дә сынадык – тәмле!

Сыйфат ягыннан җирле брендлар белән дә, күрше төбәкләрнең продукциясе белән дә көндәшлеккә сәләтле.

Килгән барлык сөтнең якынча 10%ы эчә торган пастеризацияләнгән сөт фасовкасына бара. Калган чимал, сепарат аша чыгарылып, каймакка һәм сыек сөткә (обрат) аерыла. Каймактан атланмай ясала (тәүлегенә 3 тоннага кадәр). Сыек сөт, пастеризацияләнеп, киптерергә озатыла – без коры сөт җитештерү цехында басып торабыз. Рөстәм Кыяметдинович 6 метрлы вертикаль «ракета»ны күрсәтә, аның иллюминаторы аша касмакланып җиңел генә сөт тузаннары очып төшкәне күренә.

«Югары Ослан» коры сөтне күмәкләп сата. Күп кенә предприятиеләр аны йогырт, эремчек, кондитер әйберләре, казылык һ.б. ризыклар җитештерү өчен сатып алалар.

– Ә аны кабат сөткә әйләндереп буламы?

– Була, ләкин аны гадәттә майсызландырылган түгел, майлы коры сөттән ясыйлар, һәм ул «Сөт эчемлеге» дип аталырга тиеш.

– Һәм мондый сөт әйбәт булып чыгамы?

– Ә нигә булмасын? Тик шунысын истә тотарга кирәк: аны җитештергәндә, бөтен киптерү процессы киресенчә башкарыла һәм ул гадәти сөттән арзанрак тора алмый. Сөтне «яңадан торгызу» натураль продуктлар тиешенчә җитештерелмәгән төбәкләр өчен актуаль. Ә Татарстанда, кабатлап әйтәм, яхшы сөт җитәрлек.

«КОСМИК» ПОТЕНЦИАЛ

Ә гадәти сөт? Аның бәяләре белән эш ничек тора?

– Сөтне без бирегә, республикада, нигездә, якын-тирә районнардан литрын 20 сумнан сатып алабыз, ә пастеризацияләнгәнен сәүдә ноктaларына 26–27 сумнан сатабыз. Бу җитештерү рентабельлегенең иң нечкә сызыгы, – дип дәвам итә «Югары Ослан»ның генераль директоры. – Шул ук вакытта без әледәнәле вак күмәкләп сатып алучылар белән дә очрашабыз, алар безнең бәяләрнең үзләре өчен кыйммәт булуын әйтә. Ә менә, мәсәлән, күрше өлкәдән аларга шактый арзанга китерәләр… Аны нәрсәдән әзерлиләрдер, бу – табышмак. Кыскасы, мин Татарстан сөт продуктларын алырга киңәш итәм, өстәвенә, алар берничә бренд, сайлап алу мөмкинлеге зур.

Без аксыл чәчле, алсу йөзле хезмәткәр кызның коры сөтне кәгазь пакетларга тутыруын карап торабыз.

– Вера, һичьюгы кадрга елмаи инде! – ди кызга цех башлыгы Сергей Салин, кулларын болгый-болгый, җитештерү турында сөйләгән сүзләреннән тукталып. – Ул бит безнең чибәркәебез! Һәм, гомумән, безнең монда һәммәсе дә – булдыралар!

– Ә сездә кадрлар белән хәлләр ничек? – дип сорыйм Рөстәм Кыяметдиновичтан.

– Бездә тотрыклы коллектив. Барлыгы – 130 кеше. Җитештерүдә хезмәткәрләрнең штаты тулы. Мин югары квалификацияле кадрлар белән генә кыенрак. Авыл яшьләре, Казанда укып чыккач, кайтырга ашыкмыйлар, – ди директор.

Без эссе цехтан эссе ишегалдына чыгабыз. Складтан товар бушаталар.

– Ә сатып алучылар кемнәр?

– Күңелле рәсемнәр төшерелгән пакетлардагы 2,5% һәм 3,2% майлылыктагы сөтне Казанга, төрле нокталарга илтәбез. Май һәм коры сөтне күмәкләп – Россия буенча, Түбән Новгородтан һәм Мәскәүдән башлап, Калининградка кадәр. Хәтта Казахстанга да.

Мин дилерлык челтәренең озынлыгына хәйран калам.

– Без Айга да сатарга әзер, вакытында түләсеннәр генә, – дип елмая Рөстәм Кыяметдинович.

Чыннан да, мондый сыйфат белән галәмгә дә чыгарга мөмкин!

Реклама

ГОЛЬФ: ҮЗЕҢӘ-ҮЗЕҢ ХАКИМ

Гольф уенын күзәтү – бик күңелле, ә менә аңламаучылар күзлегеннән караганда – шикле: кыр буйлап затлы киенгән кешеләр йөри, салмак кына әңгәмәләр алып баралар, бик озак төзәп торгач кына, тупка сугып җибәрәләр. Хәер, ул читтән караганда гына шулай тоела: гольф күңелсез һәм элитар уен гына булса, бөтен дөнья буенча аңа мөкиббәннәр артып тормас иде. Кулына бер тапкыр кәшәкә алган кешегә шунда ук бу уенның нинди мавыктыргыч гамәл икәне аңлашыла башлый.

Бөтен стереотипларны янга куеп, гольфчылар сафына кушылып китү бик гади: моның өчен «Свияжские холмы» курортының гольф-клубына килү дә җитә.

Үзен гольфта сынап карарга теләүчеләр өчен башта гандикап алырга (уенчының квалификациясен раслый торган үзенә күрә кырга чыгарга рөхсәт таныклыгы) кирәк, аның өчен инструктор белән берничә дәрес үтәргә һәм тиешле «имтиханнар»ны тапшырырга туры киләчәк. «Свияжские холмы» гольф-клубына бер айлык абонемент тренер белән җиде дәреская һәм тугыз чокырчыкка имтихан уенына исәпләнгән, шуннан соң уенчыга клуб гандикапы тапшырылырга мөмкин. Гандикапның дәрәҗәсе (ул 54тән башлана) уен нәтиҗәләренә карап бирелә. Шунысы игътибарга лаек, гольфта арбитрлар юк, һәр уенчы – үзенә үзе хаким. Моннан тыш, гандикаплар системасы яңа кешегә оста уенчы белән көрәшкә керергә дә мөмкинлек бирә. Ә профессионалдан бәрешне оту – үзе бер рәхәтлек.

Башлангыч гандикапны алу өчен күнегүләр «Свияжские холмы» driving range*да – күнегүләр зонасында үтә. Уенчыга, әйтик, тупка турыдан-туры чирәмнән бәрү мөмкинлеге бирелә, югыйсә, мондый «корбаннар»га бөтен клублар да бармый – чирәмле кәскә зыян китерү ихтималлыгы зур.

«Свияжские холмы» кыры уенның дөнья стандартларына туры килерлек итеп эшләнгән: монда чирәмнең биеклеге зур төгәллек белән исәпләнә (бу күрсәткеч тупның тизлегенә турыдан-туры йогынты ясый), ком тоткарлагычларга ап-ак кварц комы сибелә.

Гандикапны алгач, уенчы кырның үзендә уйнау хокукына ия була: барлык 18 чокырчыкны да «ти»дән башлап (старт мәйданы), «грин»га (финиш) җиткәнче узу өчен, ким дигәндә, 5–6 сәгать вакыт кирәк булачак, бу вакытта уенчы 7 чакрымлап юл үтә.

...2016 ел – гольфның озакка сузылган тәнәфестән соң спортның Олимпия төрләре программасына кабат кайту елы: элек гольф буенча ярышлар 1900 һәм 1904 еллардагы җәйге Олимпиадаларда гына үткән (гольфка спортның Олимпия төре статусын бирү карары 2009 елда Халыкара олимпия комитеты әгъзаларының 63 тавышы белән кабул ителгән, 27 тавыш каршы булган).

Россиядә спортның бу төре әлегә популярлашып кына килә. Һәр сезонда эшләүче «Свияжские холмы» шәһәр-курорты барлык теләүчеләргә дә үзен шушы борынгы, әмма бөтен дөньяда популярлыгын югалтмаган уенны яратучыларны берләштерүче глобаль «клуб» әгъзасы итеп тою мөмкинлеге бирә.

«Свияжские холмы» шәһәр-курорты һәр кышта иң яхшы Идел буе тау чаңгысы курортларының берсенә әверелә:

- Гомуми озынлыгы 3,5 кмны тәшкил иткән төрле катлаулылык дәрәҗәсендә җиһазландырылган 4 трасса.
- Бөтен трассалар яктыртылган, бу тәүлекнең караңгы вакытында да тау чаңгысы адреналинын «тотарга» мөмкинлек бирә.
- Тау чаңгысы тауларында кәнафиле күтәргечләр генә эшли – бу хәтта башлап килүче спортчылар өчен дә бик уңайлы.
- Катлаулылыгы төрле дәрәҗәдә һәм джиб-фигуралары булган сноупарк.
- 3 инвентарь прокаты пункты, ски-сервис һәм шуарга өйрәтү хезмәте.

Кунаклар өчен тагын:
- 4 кунакханә һәм альп өйләре.
- 10 ресторан, 5 банкет залы, конференция заллары.
- Боулинг-клуб, бильярд заллары һәм сауналар комплексы.

Реклама

* Driving range – күнегүләр кыры.

PRESSA.RU

ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР **МОХИТЕ**

Әле 2012 елда гына биредә чиста кыр иде. Ә инде өч ел узуга, Премьер-министр Дмитрий Медведев тантаналы рәвештә бу урында яңа шәһәр – Россиядәге иң яшь шәһәрне ачты. Бүген аның инфраструктурасы 5 мең кеше өчен уңайлы тормыш тәэмин итә ала. Ә 2030 елга исә Иннополиста 150 мең кеше яшәячәк – планнар әнә шундый.

ИННОПОЛИС һӘМ АНЫҢ ХАЛКЫ

– Иң мөһиме – Иннополиска Россиянең әйдәп баручы IT-компанияләре, югары квалификацияле белгечләр һәм аларның гаиләләре тартылсын өчен, һәм кешеләрнең бу уникаль шәһәрдә яшисе һәм эшлисе килсен өчен, тиешле шартлар булдыру, – ди Иннополисның мэры Егор Иванов.

Россия IT-индустриядә дөньяның әйдәп баручы илләреннән әлегә калыша, шул ук вакытта белгечләр – чит илләргә, ә төбәкләрдәге белгечләр, төбәк икътисадына зыян китереп, Мәскәүгә китүләрен дәвам итә. Билгеле, илгә альтернатив үсеш нокталары кирәк, һәм Иннополис – әнә шуларның берсе. Аның төп өстенлекләре – университет, махсус икътисадый зона һәм уникаль шәһәр мохите. Университет максималь рәвештә индустрия ихтыяҗларына җавап бирә торган белгечләр әзерли. Махсус икътисадый зона, уникаль салым ташламалары һәм преференцияләр хисабына IT-өлкәдәге компанияләр өчен магнит булып тора. Шәһәр мохите белгечләрне һәм аларның гаиләләрен тормышның югары сыйфаты һәм уңайлы инфраструктурасы белән җәлеп итә.

Шәһәр биредә яшәүче кешеләр-клиентлар өчен сервис компаниясе буларак үсәргә тиеш, дип исәплиләр Иннополиста. Дөньяның аеруча уңышлы шәһәрләре әнә шундый мантыйк белән үсә, ә Россиядә Иннополис – пионер. Кешеләр анда барырга теләсен өчен, шартлар тудырырга кирәк: күчеп килүне катлаулы итмәскә, арендага җиһазлары, көнкүреш техникасы һәм уңайлы яшәр өчен бөтен кирәк-ярагы булган яхшы торак бирергә. Шәһәрдә гаилә өчен инфраструктура булырга тиеш. Гомумән алганда, монда боларның һәммәсе дә бар инде. Мәсәлән, хәзер Иннополиста билингваль укыту системасына корылган балалар бакчасы, мәктәп, IT-лицей-интернат, медицина үзәге, спорт комплексы эшли. Хезмәт күрсәтү өлкәсе, сервис инфраструктурасы сафка куелган. Шәһәрдән машина белән унбиш минутлык юлда тау чаңгысы курорты, гольф кыры, ату комплексы урнашкан, ә шәһәр үзе велосипед юллары белән әйләндереп алынган. Сентябрьдә төрле дисциплиналарны, шул исәптән, триатлонны да эченә алган спорт мәктәбе ачылачак.

Шәһәр федераль һәм төбәк акчаларына төзелгән, бөтен инженерлык инфраструктурасы: су җыю корылмасы, канализация, җылылык үзәге, электр челтәрләре, телекоммуникация челтәрләре һәм юлларның 90 проценты төп инвестор – «Иннополис махсус икътисадый зонасы» ААҖ балансында. Шәһәрне оештыручы икенче оешма һәм төп җәлеп итү ноктасы – «Иннополис университеты» АКБОсы.

Бүгенге көндә Иннополис мэриясе университет бинасында урнашкан. Башкарма комитет – 13 белгеч – санап кителгән структуралар һәм шәһәр төзүче подрядчылар белән хезмәттәшлек итә, проект документларының генпланга туры килү-килмәвенә контрольне әле беркем үзгәртмәгән. Әмма иң мөһиме – социаль инфраструктураны, төзекләндерүне һәм төрле чаралар уздыруны тәэмин итү. Ул шәһәр кешеләренә Югары Ослан һәм Свияжск буйлап экскурсияләр оештыруны да, Автомобильсез көн яки Милләтләр кроссын, ял көннәрендә Шәһәр квестын үткәрүләрне дә, фильм күрсәтү яки театраль куелышларны да үз эченә ала. Монда Республика көнен билгеләп үтәләр, чыршы бизәп, Яңа елны бәйрәм итәләр. Профессиональ чаралар турында да онытмыйлар – IT-эшкәртүчеләр клубы эшли, тармак конференцияләре һәм форумнары үткәрелә.

– Көн дәвамында шәһәрдә ике меңләп кеше була, бу – төзүчеләр һәм кунакларны да кушып санаганда, – ди Егор Иванов. – Хәзер, мәсәлән, җәйге президент кампусы үтә, тагын 400ләп кеше. Даими яшәүчеләрнең саны, 300 студентны да кертеп, 1100не

ПО РАЙОНАМ / СПЕЦПРОЕКТ

тәшкил итә. Көн дәвамында иң күп кеше университетта тупланган булса, кичен – торак микрорайонда, андагы алты йортның 315 фатиры тулысынча кулланылышта.

– Август аенда халык тагын 300 кешегә артачак – студентларның яңа агымы килә. Аларның өчтән бере генә – республикабыздан, калганнары РФнең башка төбәкләреннән, ә 10сы – ерак чит илләрдән: Мексика, Колумбия, Венесуэла, Эфиопиядән. Ә яңа агымда инде аларның 25 процентын Россиягә читтән килүчеләр тәшкил итәчәк.

«СЕРВИС» ШӘҺӘРЕ

Башкарма комитетның дүрт хезмәткәре эшләгән «Административ-техник инспекция» МКУ шәһәрнең төп коммуналь процессларын – юлларны чистартуны, яктыртуны, су белән тәэмин итүне, көнкүреш проблемаларын контрольдә тота.

Яңа йортлар гарантиядә тора. Җитешмәгән яклар табылса, төзелеш оешмасы аны төзәтергә тиеш. Яшәүчеләрнең «Уютный дом» ИК, милек хуҗасы (ДТФ) һәм төзелеш оешмасы («Ак Таш») белән үзара мөнәсәбәтләре – мэриянең эше. Кешеләр ИКнең эшен тәүлек әйләнәсе эшләүче консьерж-сервис телефонына мөрәҗәгатьләр белән «төзәтәләр», андагы операторлар инглиз, татар һәм рус телләрендә сөйләшә. Әмма хакимиятнең кешеләр белән әңгәмәсендә төп инструмент – Telegram мессенджеры, чатта көн дәвамында 800-900 кеше онлайнда утыра. Һәр мөрәҗәгатькә номер бирелә, ИКнән башкаручы һәм куратор – башкарма комитет хезмәткәре билгеләнә. Мэрия, тариф сәясәтен эшләгәндә, яшәүчеләрнең мәнфәгатен яклап, ИК һәм ТР Төзелеш министрлыгы белән хезмәттәшлек итә.

Төзекләндерү идарәсе яшелләндерү һәм кече архитектура формалары, эскәмияләр кую, шәһәрне бөҗәкләрдән, кимерүчеләрдән, урам этләреннән саклау эшләре белән мәшгуль.

Шәһәрдә, кем әйтмешли, «барысы да кешеләрчә»: тору урынында теркәлү, хәрби бурычлыларны исәпкә кую... Загс вазыйфалары да йөкләтелгән мэр никахларны терки, менә августта инде икенче туй көтелә. «Үз» прокурорлары (Югары Ослан районының прокурор урынбасары), терәк пункт һәм үз участковыйлары, яңгын командасы да бар. Көн саен тәүлек әйләнәсе режимында ЧОП төркеме эшли, шул исәптән, мобиль системада да. Юл хәрәкәтен иминлек хезмәте экипажлары күзәтә.

Шәһәр кешеләре «Бәхетле» азык-төлек супермаркеты эшләвеннән дә канәгать, аның ассортиментында 9 мең исемдәге товар бар. Шул ук вакытта ассортимент әллә ни бай булмаган студентлар кесәсенә ятышлы бәяләр буенча махсус сайланган. Шәһәр территориясендә даруханә пункты һәм медицина амбулаториясе үзәге эшли, һәм ул беренче ярдәм күрсәтү белән генә чикләнми, организмны комплекслы тикшерү буенча уникаль хезмәтләр дә күрсәтә. 2015 елда 743 өлкән кешегә һәм 295 балага ярдәм күрсәтелгән. Көтелмәгән очракларда Югары Ослан ҮРХнә илтеп җиткерү өчен ашыгыч ярдәм машинасы кизү тора.

Шәһәрдә 36 бала йөри торган балалар бакчасы һәм гомуми белем бирү мәктәбе бар. Бер елда аны 57 укучы тәмамлаган, 1 сентябрьгә 80 укучы көтелә. Университет каршында IT-лицей эшли, узган ел анда 95 укучы укыса, 1 сентябрьдән аларның саны 135кә җитәчәк.

Почта, Саклык банкы һәм «Ак Барс» банкы бүлекчәләре, «Таттелеком» абонентларына хезмәт күрсәтү офисы, автоюгыч-шиномонтаж бар. Шәһәрдә хәрәкәттәге кер юу һәм клининг хезмәтенә дә, азык-төлекне китереп бирү хезмәтенә дә ияләшкәннәр. Хәтта матурлык салоны да ачылган.

– Күчеп килү турындагы соңгы карарны гадәттә хатын-кыз кабул итә, – дип аңлата мэр. – Шуңа күрә яңа урында кибет, балалар бакчасы, мәктәп, куркынычсызлык һәм... матурлык салоны булу аеруча мөһим. Хәзер болар барысы да бар. Кешеләр кичләрен утырып аралаша, ниндидер вакыйганы билгеләп үтә алырлык бар-ресторан да булса... Булдырырга ниятлибез.

Район хакимияте белән үзара мөнәсәбәтләр шулай ук көйләнгән. Иннополисны төзекләндерү мәсьәләләрен, теге яки бу объектны төзү кысаларында, район башлыгы үзе контрольдә тота, чөнки IT-шәһәр районның визиткасы бит. Иннополисның мэры – район советы депутаты, ул аның утырышларында һәм җирлек башлыклары белән эшлекле дүшәмбеләрдә катнаша.

Әлбәттә, чишелгәннәренә караганда, хәл итәсе мәсьәләләр күбрәк әле. Барлык хезмәткәрләрнең дә хатыннарын эш белән тәэмин итеп булмый, аларның кайберләре Казанда эшли. Әмма шәһәр бу юнәлештә дә актив эш алып бара.



Реклама

PRESSA.RU

МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ЯЛ ИНТЕРНАТ-ЙОРТЫ

Беседкада «фәлән яшьтән әз генә узган» ханымнар төркеме талгын музыка астында күнегүләр ясый. Янәшәдә генә шашка уйныйлар. Без, идиллияне бозмаска тырышып, сиздермичә генә күзәтәбез.

– Кулларны күтәрәбез, киерeлә-без! – гимнастиканы дәвалау физкультурасы инструкторы Лиля Зверева ясата. Югары Ослан картлар һәм инвалидлар интернат-йортында зарядка, башка күп нәрсә кебек үк, көндәлек шөгыль. Күнегүләрдән соң әлеге тату компания җептән картиналар ясау серләренә өйрәнер өчен бина эченә керә. Социаль хезмәткәр Антонина Банникова җитәкчелегендә җепләрдән гүзәл картиналар туа. Ә салкынчарак көннәрдә биредә яшәүчеләрнең күпчелеге бакчачылык белән шөгыльләнергә ярата икән. Су сибү өчен иганәчеләр акчасына төрле зурлыктагы сусипкечләр алынган – һәркем үзе теләгәнен сайлый да эшкә керешә.

Гомумән алганда, биредә яшәүчеләрнең эленке-салынкы йөрергә вакыты юк. Учреждениене карап чыкканнан соң, аның исеме генә казнаныкы булуына инанасың. Чынлыкта исә бу гүя шифаханә – аның үзенә генә хас, әмма биредәге һәркем өчен җайлы ритмы бар, бүлмәләре чиста һәм уңайлы, атмосферасы да ничектер күңелгә ятышлы. Интернат хезмәткәрләренең көндәлек тырыш һәм сыйфатлы эш нәтиҗәсе бу, атмосфера нәкъ менә шуңа якты да, эчкерсезлек һәм игелек белән дә тулы. Һәм инде өлкән яшьтәге, авырудан интеккән кешене өметен өзгән туганнары бирегә китергәч, аның янәдән яшисе килә башлый икән, моңа беркем дә гаҗәпләнми. Мондый очраклар күп биредә. Барысы да диярлек шундый.

КИРӘКСЕЗЛӘР ЮК

– Кайберәүләр картлар һәм инвалидлар өчен интернатны алар соңгы көннәрен уздыра торган сагышлы социаль учреждениегә саный. Мин үземнең беренче эш көнемдә үк, бездә болай булмаячак, дип карар кылдым. Кыен булды, әмма Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы җитәкчелегенең һәм иганәчеләрнең актив ярдәме, шулай ук инде, әлбәттә, хезмәткәрләребезнең тырыш хезмәте нәтиҗәсендә без үзебез горурланырлык йорт булдыра алдык. Биредә яшәүчеләргә дә рәхәт, без дә көн саен сөенеп эшкә киләбез. Максатыбыз – өлкән яшьтәгеләргә һәм инвалидларга мөмкин булганча тулыканлы тормыш белән яшәргә ярдәм итү. Еш кына кайгыртуга мохтаҗ кешенең туганнары, төрле сәбәпләр аркасында, аңа тиешле ярдәмне күрсәтә алмый. Бу хәзерге заманның җитди проблемасы. Без мондый очракларда гаиләләргә профессиональ ярдәм күрсәтәбез, – дип сөйли интернат директоры Элеонора Серебрякова.

Бүген интернат-йортта 62 кеше яши: шуларның 46сы – төрле төркемгә караган инвалидлар, 13 е даими кайгыртуга мохтаҗ.

Хәзер инде без экскурсияне бүлмәләр буйлап дәвам итәбез.

– Исәнмесез! Йә, бүген хәлләрегез ничек? – дип сораша 18 нче бүлмәдәге әбидән Элеонора Яковлевна. Бүлмәдә якты, өстәлдәге вазада – кәнфитләр. Без әбине тегүеннән аердык.

– Яхшы, рәхмәт! Кайчан Раифага экскурсиягә барабыз? – дип, үз соравын бирергә ашыга әби.

– Бераз эсселек басылуга ук, оештырырбыз! – ди Элеонора Яковлевна.

Икенче бүлмәдә ирле-хатынлылар яши, икесе дә – балачактан ук инвалид. Нәкъ менә алар Элеонора Яковлевна белән популяр «Мужское/Женское» телетапшыруында катнашкан.

– 62 койка-урынның 12се тулысынча түләүле нигездә эшли. Асылда биредә кешеләр реабилитация үтә, вакыты исә аларның сәламәтлекләренә бәйле. Республикадагы шундый ук учреждениеләр белән чагыштырганда, бездә бу чор кыскарак. Белгечләрнең квалификациясе югары булу һәм интернатның кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителүе нәтиҗәсендә, – дип сөйли Элеонора Яковлевна.

Интернат хезмәткәрләрен ул җентекләп сайлап ала, биредә очраклы кешеләр юк. Дорфалык катгый тыела. Хәер, әлеге бинада дорфалыкны күз алдына да китереп булмый.

– Үз вакытында мин ике җирдә – биредә һәм балалар бакчасында эшли идем. Балалар да, безнең әби-бабайлар да бердәй ихлас һәм эчкерсез. Аларның ышанычын акламый булмый, – дип сөйли психолог Юлия Лыкина.

Юлия һәм башка белгечләр (хезмәт буенча инструктор, социаль хезмәткәр, мәдәни чараларны оештыручы, юрист – барысы да югары белемле)

Реклама

интернат-йортка тулы ставкага килсен өчен, учреждениенең күзәтү советы эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм түләүле хезмәтләрдән кергән керемнең 60 процентын персоналга өстәмә түләүләргә юнәлтергә карар кылган.

Юлия үзенең кабинетын күрсәтә. Стендларның берсендә – интернат белгечләре тарафыннан эшләнгән ике дистәләп реабилитация программасы. Ә менә болары – релаксация һәм тынычлану өчен сенсор бүлмәсе. Монысы – өске сулыш юлларын дәвалау һәм кисәтү процедуралары өчен спелеокамера. Тоз кирпечләрен Уралдан кайтартканнар. Сүз уңаеннан, интернат-йортта күп нәрсә хезмәткәрләрнең гаиләләре катнашында эшләнә – территорияне төзекләндерү дә, вак-төяк ремонт эшләре дә, хәтта бирeдә даими уздырыла торган гаммәви мәдәният чараларын оештыру да.

– Бездә – гаилә подряды! – ди Элеонора Яковлевна.

ӨМЕТ БАКЧАСЫ

– Интернат-йортыбызны яхшырак итүгә без күп көч куйдык. «Туган авылым» территориясен хайван сыннары һәм чәчәк түтәлләре белән бизәдек, хәзер ул чын утарга әйләнде. Рус һәм татар мәдәниятләренә багышланган ике кечерәк кенә музей ясауны да планлаштырабыз. Барысы да «Безнең кадерле ветераныбыз» бәйге-акциясендә катнашудан башланды. Аның максаты – ветераннарның (Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тыл хезмәтчәннәренең) яшәү шартларын яхшырту, – дип сөйли Элеонора Яковлевна. – Республика бюджетыннан безгә капремонт өчен акча бүлделәр. Ә бездә ветераннарның бүлмәләре болай да яхшы җиһазландырылган. Республика буенча конкурста барлыгы 17 интернат катнаша. Без үзебездәге конкурс комиссиясе күрсәткән барлык кимчелекләрне төзәтергә тырыштык. Тик ничектер аерылып та торасы килде, шунлыктан әлеге музейларны уйлап таптык. Хәзер конкурста күрсәтергә җыенабыз.

Элеонора Яковлевнаның тел төбеннән ук аңлашыла – әлеге әзерлек төпле булачак. Мондагы бөтен нәрсә кебек үк. Мөгаен, шуңа да аның кабинетының диварларын грамоталар һәм рәхмәт хатлары чуарлыйдыр, интернатта яшәргә теләүчеләр исә чиратка баскан. Туганнары гына түгел, картлар үзләре дә, биредәге шартларның бик шәп икәнен кайдандыр белеп, гаризаларын китерә икән.

Әмма, сүз дә юк, күпсанлы иганәче һәм волонтерлар катнашыннан башка сенсор бүлмәсе дә, җептән картина ясау түгәрәге дә, сусипкечләр дә – гомумән, интернаттагы бүгенгедәй тормыш булмас иде. Булышучыларның саны йөздән арта. Шунысы гаҗәпләндерә һәм ихтирам уята: күбесе исемнәрен дә әйтергә теләми хәтта.

– Безгә бик күп булышалар – хосусый затлар да, оешмалар да. Ярдәм төрле – принтер өчен кәгазьдән алып оргтехникага, иҗат итү өчен материаллардан – бәйрәм чаралары үткәрүгә кадәр. Безгә елына 700ләп кеше килә. Бүген интернат-йортларга коммерция эшчәнлегеннән керем алу бурычы да куелган. Тагын әле безнең эшләп тапкан акчаны файдалану буенча лимитларыбыз да бар. Шунлыктан иганәчеләр һәм волонтерлар ярдәме беркайчан да артык булмый. 2010 елдан бирле интернатның сайты эшли, һәм безнең даими хәйриячеләребезнең күбесе безне аның аша үзләре эзләп тапты, – дип сөйли директор.

Бер оешма системалы рәвештә кайнар һәм салкын су белән тәэмин итү буенча ремонт эшләрен башкара. Икенчесе кирәкле оргтехника сатып алган, аның хезмәткәрләре елына ике тапкыр участокта булышырга киләләр. Хәйриячеләр кунак бүлмәсенә, фойега, бүлмәләргә җиһазлар сатып алган.

Ярдәм һәрвакытта да урынлы, ди Элеонора Яковлевна. Аның кабинетындагы өстәл өстендә кирәк-яракларның исемлеге ята, һәм кемдер, кайдандыр өстән карап, аларны булдыру турында кайгыртып тора кебек.

– Белмим әле, анда ничек хәл итәрләрдер, – Элеонора Яковлевна әнә шунда – өскә ишарәли, – әмма безгә үзебезнең артезиан скважинасы бик кирәк. Коммуналь хезмәтләр чыгымнарына лимит билгеләнгән, ә суны еш сибәргә кирәк. Әнә бит, безнең бакчабыз нинди! Бөтен йортыбыз белән үстерәбез аны!

Бер оешма системалы рәвештә кайнар һәм салкын су белән тәэмин итү буенча ремонт эшләрен башкара. Икенчесе кирәкле оргтехника сатып алган, аның хезмәткәрләре елына ике тапкыр участокта булышырга киләләр. Хәйриячеләр кунак бүлмәсенә, фойега, бүлмәләргә җиһазлар сатып алган.

– Кайберәүләр картлар һәм инвалидлар өчен интернатны алар соңгы көннәрен уздыра торган сагышлы социаль учреждениегә саный. Мин үземнең беренче эш көнемдә үк, бездә болай булмаячак, дип карар кылдым.

PRESSA.RU

ЧЕМПИОН БЕЛӘН АТЫП КАРЫЙСЫҢ КИЛСӘ – РӘХИМ ИТ!

Югары Ослан районында урнашкан «Свияга» ату комплексын тәэмин итү өчен, ел саен бюджеттан 40 миллион сум акча бүлеп бирелә. Комплекс үзе дә акча эшли: теләгән һәркем, бер тапкыр ату өчен кассага 40 сум түләгәннән соң, инструктор, мылтык, мишень, патроннар һәм ату урынына ия була. Чемпионнар да шулай ата!

Биредә корпоратив чемпионат та үткәреп була – комплекс персоналы аны профессиональләрнеке дәрәҗәсендә оештырачак. Бары мишеньнәр генә олимпиячеләрнекеннән бераз акрынрак очачак.

Татарстанда стендка ату спорты Тәтешкә, отставкага чыгып, подполковник, Ленин ордены кавалеры Солтан Яруллин кайтканнан соң, күзгә күренеп үсә башлый. Энтузиаст укчы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенә нигез сала, 1961–1986 елларда аңа җитәкчелек итә, спорт осталары тәрбияли. Бүген ТР пуля белән һәм стендка ату РСДЮШОРы (Республика махсуслаштырылган Олимпия резервы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе) тренерларының яртысыннан артыгы, аның директоры Сергей Деминны да исәпкә алып, Тәтештә тәрбияләнгән.

– Тәрбия процессы Тәтештән Казанга күчеп китү белән тәгәлләнә иде, – дип сөйли комплекс директоры Сергей Демин. – Башкаланың исә үзенең көчле укчылары бар. Әмма Казан стенды үсә барган таләпләргә җавап бирми башлады. 2009 елда республика «Свияга» ату комплексы төзелешен финанслады, ә инде бер елдан соң ул Европа чемпионатын кабул итте, анда 700гә якын спортчы җыелды. 2011 елда биредә балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе ачылды, Тәтештәгесе исә филиал булып калды. Алар тренер кадрлары буенча да, тәрбияләнүчеләр дәрәҗәсе буенча да тигез сыйфатлы, икесе бербөтенне тәшкил итәләр.



Сергей Константинович әйтүенчә, кадрларны бирәдә калдыруга район администрациясе зур ярдәм күрсәткән: тренерлар коллективы һәм хезмәткәрләргә торак төзү өчен җир участоклары бүлеп биргән, шулай итеп, Яр буе Моркваши янында М-7трассасына янәшә генә Спорт урамы пәйда булган.

Җиһазландырылуы буенча яңа стенд – Россиядә иң яхшысы, Европа һәм дөньядагы беренче бишлеккә керә ул. 4600 квадрат метрлы мәйданда матбугат конференцияләре залы, ашханә һәм кафе, VIP-биналар, судьялар, жюри, рефери, апелляцион жюри бүлмәләре, спортчыларның ял бүлмәләре, тренерлар бүлмәләре, ике физкультура-спорт залы, дәвалану-профилактика чаралары уздырыла торган класслар, теоретик дәресләр өчен әзерләнгән класслар, видеомотор күнекмәләре класслары, массаж бүлмәләре һәм сауналар урнашкан.

Биредә хәтта Олимпия уеннары да үткәрергә мөмкин. Биш комплексы мәйданчык өч Олимпия дисциплинасын да – скит, трап һәм дубль-трап – кабул итә ала. Барлык процесслар автоматлаштырылган, ярышларны компьютер буенча үткәреп була, мәйданчыклардагы нәтиҗәләр мониторларда күрсәтелә. 2013 елда биредә Универсиаданың стендка ату буенча ярышлары уздырылган, быел сентябрьдә исә инде сигезенче тапкыр Россия чемпионаты үтәчәк.

Бүген спорт мәктәбендә (РСДЮШОР) дистәдән артык квалификацияле тренер эшли, алар өлкәннәр һәм балалар белән төркемләп һәм индивидуаль шөгыльләнә. Әледән-әле 11-16 яшьлек малай һәм кызларны түләүсез төркемнәргә җыялар. Төркемнәрне ату комплексына уңайлы автобусларда алып баралар.

Спортчылар Казаннан гына түгел, бөтен Югары Ослан районыннан да – Макыл, Татар Борнашы, Югары Ослан, Яр буе Моркваши, Введенкадан киләләр...

Район спортчыларыннан шәп нәтиҗәләргә ирешүчеләрне дә искә алып үтү кирәктер. Болар – 2015 елда Россиянең үсмерләр һәм юниорлар беренчелекләрендә җиңүче, Россия яшүсмерләр җыелма командасы әгъзасы Данила Маслов, спорт мастеры Влад Бузунов, спорт мастерлыгына кандидат Екатерина Архиереева һ.б.

Бирәдә 150 спортчы актив шөгыльләнә. Мәктәп эчендәге ярышларда көрәш кискен, чөнки мәктәптә халыкара классы 10 спорт мастеры, 20 спорт мастеры һәм 50 кандидат бар. Өч спортчы Рио-де-Жанейродагы Олимпиадада Россия данын яклый. Алар арасында 43 яшьлек Василий Мосин да бар, ул күптән түгел Италиядәге Лонатода үткән дөнья чемпионатында «дубль-трап» күнегүендә үзенең алтынчы алтын медален яулаган иде.

РАЙОННАР БУЙЛАП / МАХСУС ПРОЕКТ

Реклама



«МӘҢГЕЛЕК» КИРПЕЧ СЕРЕ

«Ключищи керамикасы» белгечләре раславынча, керамик эшләнмәнең, әйтик, гап-гади кирпечнең, хезмәт срогы 1000 елдан артык икән. Заводка экскурсиядән соң, хәтта шундый җитди сан да бернинди шик тудырмый. Шулкадәрле гомер итү теләге тудырса гына инде.

– Без биредә кирпечебезне ул кырыс чынбарлыкта дучар булачак барлык сынаулар белән чыныктырабыз – дип сөйли «Ключищи керамикасы» лабораториясе башлыгы Юлия Таранцева. Зур булмаган бинада берничә гадәти булмаган җайланма – реаль станокларның миниатюралары куелган.

Юлия туңдыру камерасын ача һәм аннан... кирпеч тартып чыгара.

– Хәзер бу үрнәк температура акрынлап төшә бара торган туңдыру процессында. Температура минус 20 градуска кадәр төшкәч, без аны сулы резервуарга күчереп, суда 4 сәгать тотачакбыз, аннары тагын туңдыру камерасына куячакбыз. Әлеге эксперимент ике айга диярлек сузылачак, – ди Юлия.

Стандартлар буенча, кирпеч шундый 75 циклга, ягъни «елга» чыдарга тиеш. «Ключищи керамикасы»ның бөтен продукциясе әлеге 75 циклга, хәтта аннан күбрәккә дә түзә. Салкынга чыдамлык тесты – лаборатория хезмәткәрләренең чималны һәм әзер эшләнмәләрне сынау ысулларының берсе генә, ә андый ысуллар – бихисап. Балчыкның – үзлелеге, ә әзер эшләнмәләрнең су йотучанлыгы, салкынга чыдамлыгы, бөгелү һәм кысылулары тикшерелә.

Болар нәрсәгә кирәк соң?

– Без эшли генә башлаган мәлдә янибызга Казансу ярындагы «Магеллан» торак комплексын төзүчеләр килде. Аларга матур сары кирпеч җитештереп бирә торган завод ябылган икән. Безгә шул кирпечне күрсәтеп, аның кебекне үк ясый аласызмы-юкмы, дип сорадылар. Без ясап күрсәттек. Һәм хәзер сез кайсы йортның – безнең кирпечтән, кайсысының Мәскәү кирпеченнән төзелгәнен берничек тә аера алмыйсыз, – дип сөйли генераль директор урынбасары Рөстәм Әкбиров.

Иң беренче заказчылар рәтендә – Универсиада авылы. Авыл төзелә башлаган чакта завод биналарны тышлый торган кирпеч җитештерүне үзләштерә генә башлаган була. Шулай булса да, таләп ителгән сыйфатлы 8 миллион кирпеч республика унъеллыгы төзелешенә иң кыска срокларда китереп җиткерелә.

Ә бит тышлый торган кирпеч сугу бик күп параметрларны үтәүне таләп итә. Мәсәлән, ул теләсә нинди һава шартларында да төсен һәм бөтенлеген җуймаска тиеш.

Рөстәм Нурислам улы әйтүенчә, элегрәк завод заказчылар теләгән һәр төстәге кирпечне дә сугарга тырышкан. Хәзер исә җылылык үткәрүчәнлеге 0,36 Вт/м·°Сны тәшкил иткән кирпеч өч иң популяр төстә җитештерелә: «шәфталу», «шоколад» һәм «салам» төсләрендә. Предприятие ассортиментында җылылык үткәрүчәнлеге 0,179 Вт/м·°С булган гади керамик (тишекле) таш та бар. «Ключищи керамикасы»ның бик шәп «куллану» характеристикаларына (экологик, чыдам, җылылык чыгармый) ия, силикат кирпечтән энергия саклаучанлыгы, тавыш үткәрмәве белән аерылып торган эшләнмәләре сыйфат өчен күп тапкырлар төбәк һәм федераль дәрәҗәдәге бүләкләргә лаек булган.

– Безнең даими сатып алучыларыбыз арасында – Мәскәү, Башкортостан, Чувашия, Мари Эл, Киров, Түбән Новгород, Ульяновск өлкәләре һәм илнең башка төбәкләрендәге компанияләр дә, – дип сөйли Рөстәм Әкбиров. – Керамик кирпеч төзелеш барышында да (җылылык саклау өчен өстәмә материаллар кирәкми), йортны киләчәктә кулланганда да файдалы.

Кирпеч өчен кызыл балчыкны предприятие үз карьерыннан чыгара. Ак балчыкны Тәтештән китерәләр.

– Заводта Испаниянең автоматлаштырылган Solincer («Солинсер») линиясе урнаштырылган. Һәр этапта процесс белән оператор идарә итә. Предприятиенең 180 хезмәткәреннән нибары 44е генә җитештерүдә мәшгуль – дүрт сменада 11әр кеше. Әмма барысы да үзеннән-үзе генә эшләнми. Югары сыйфатка ирешү өчен, бөтен нечкәлекләрне үтәргә кирәк: чималның дымлылыгын 1-2 процентка кадәр киметергә, чи кирпечне мичтә 67 сәгатькә кадәр билгеле бер температурада гына тотып чыныктырырга һ.б., – дип сөйли «Ключищи керамикасы»ның баш инженеры Евгений Ганин. – Барысын да дөрес һәм вакытында эшләү өчен, хезмәткәр җаваплы һәм югары квалификацияле булырга тиеш. Шунысы игътибарга лаек: әлеге сыйфатлар безнең һәр белгечебезгә хас. Бу, үз чиратында, предприятиебезгә көндәшлеккә сәләтле булу һәм клиентларыбызны сыйфатлы, экологик кирпеч белән тәэмин итү мөмкинлеге бирә. Сүз уңаеннан, чын табигый материал булганга, керамика үзенең төсен һәм чыдамлыгын бик озак саклый.

Реклама

PRESSA.RU

ҖИТЕШТЕРҮ – ИКЪТИСАДНЫҢ НИГЕЗЕ

Шеланга кирпеч заводындагы мич йокымсырап ятучы гаять зур аждаһаны хәтерләтә. Аның кызган карыны аша көн саен берничә тонна бик шәп сыйфатлы кирпеч үтә. Предприятие эшли башлаганнан бирле – 2001 елдан – «Керамика-Синтезда» аны шулкадәр күп җитештергәннәр инде, әгәр барысын да бер урынга җыйсаң, 150–200 мең кеше яши торган кечкенә шәһәр барлыкка килер иде.

– Заводны XX гасырның 20нче еллары азагында ук нигез салынган элеккесе урынында төзедек. Элгәресе кебек үк, «Керамика-Синтез» да зур бурычлар үтәргә – үзебездәге һәм күрше төбәкләрдәге барлык зур төзелешләрне кирпеч белән тәэмин итәргә тиеш иде, – дип сөйли завод директоры Рөстәм Фәйрушин.

Җитештерү линиясенең проект куәте елына 16-18 миллион данә шартлы кирпечне тәшкил итә.

Бүген Татарстанда һәм якындагы төбәкләрдә «Керамика-Синтез» материалларыннан төзелгән мәгълүм объектлар күп.

– Төп продукциябез – төрле әһәмияттәге биналар төзер өчен тәгаенләнгән куышлыклы-тишекле кирпеч.–Безнең кирпеч – йортның нигезе ул, бинаның матур тышлыгы астында кала торган нигезе. Кирпечтәге тишекләр аның җылы үткәрүчәнлеген арттыра. Моның өчен шихтага пычкы чүбе өстәлә, яндыру процессында ул янып бетә һәм куышлыклар калдыра. Үзебезнең ноу-хаулар нәтиҗәсендә берничә ел эчендә без әлеге күрсәткечне 20 проценттан 50 процентка җиткердек. Ягъни җылы үткәрүчәнлеге буенча безнең кирпеч агачка тиң диярлек, – дип аңлата предприятиенең баш технологы Сания Галиева.

– Без җитештерү процессын оптимальләштерү юнәлешендә даими эшлибез. Продукциянең сыйфаты өчен бүләкләребез инде күп булса да, ирешелгәннәргә канәгать булып кына утырмыйбыз, – дип сөйли Сания Галиева һәм безгә Казан, Чабаксар, Йошкар-Ола, Ульяновскидагы төзелешләргә китәр өчен әзерләнгән кирпечләрнең ничек «басылуын», калыпка салынуын, яндырылуын күрсәтә.

Технолог җитештерүдәге кайбер яңалыклар белән таныштыра. Менә пресс, ул продукция күләмен сизелерлек арттырырга мөмкинлек биргән. Менә корунд кыса, ул кирпечнең ян-якларын, бер-берсенә яхшырак берексеннәр өчен, сырлы итеп ясый. Менә кисү җайланмасы, ул берле кирпечне калыплаудан бер ярымлысына тиз арада күчү мөмкинлеге бирә.

– Боларның барысы белән дә квалификацияле кешеләрнең идарә итүе мөһим. «Керамика-Синтезда» дүрт сменада 90 кеше эшли. Шулардан 12се – административ состав, калганнары – инженерлар, мастерлар, сыйфат контролерлары. Һәркемгә зур җаваплылык йөкләнгән – мәсәлән, кемнеңдер ялгышлыгы аркасында мич туктап калса, без гаять зур зыян күрәчәкбез. Продукциянең сыйфаты һәр минутта диярлек контрольдә тотылырга тиеш. Без үзебезнең кешеләргә ышанабыз, чөнки аларның барысы да диярлек завод ачылганнан бирле эшли. Безнең кирпечебез кебек үк, яхшы чыныккан осталар алар – барысы да, – дип йомгак ясый Рөстәм Фәйрушин.

Реклама

МАХСУС ПРОЕКТ

— 14нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

БАШКАЛА ДӘРӘҖӘСЕНДӘ

Марат Хөснуллин, Мәскәү хөкүмәтендә шәһәр төзү сәясәте һәм төзелеш мәсьәләләре буенча Мәскәү мэры урынбасары, августта үзенең 50 яшьлеген билгеләп үтә.

Башкалага күчеп киткәнче, Марат Шакирҗанович тугыз ел дәвамында ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгын җитәкләде. Ул чорда республикада торак төзелеше үсешенең комплекслы программасы уңышлы җәелдерелде. Мәскәүдә Марат Хөснуллин шәһәр төзелеше һәм архитектурасы сәясәте, метрополитен үсеше белән бәйле мәсьәләләр өчен җавап бирә.

Юбилярның хезмәтләре «Россиянең мактаулы төзүчесе», «ТРның атказанган төзүчесе» исемнәре белән бәяләнде. Ул II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

Уңышлар юлдаш булсын!

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапромы» АҖ генераль директоры

Хөрмәтле Марат Шакирҗанович!

Бай тәҗрибәгез, һөнәри һәм кешелеклелек сыйфатларыгыз белән Сез хезмәттәшләрегез һәм хезмәткәрләрегез арасында лаеклы абруй һәм хөрмәт казандыгыз.

Сезгә һәрвакыт эшкә гаять җаваплы карау, беренче чиратта, үзегезгә карата таләпчәнлек, һәр яңалыкны кабул итәргә әзер торучанлык хас булды, һәм Сез әле дә туктаусыз эзләнүдә һәм үсештә – андый кешеләр дөньяда сирәк очрый.

ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында эшләгән чорда Казанда һәм Татарстанда күпсанлы мөһим объектларны торгызуда турыдын-туры катнаштыгыз. Бу – тузган торакны бетерү программасы, Казанның 1000 еллыгына әзерлек, «Алабуга» махсус икътисадый зонасын төзү, торак төзелеше һәм капиталь төзекләндерү буенча киң колачлы программалар, Универсиада һәм «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводлары комплексы объектларын төзү. Сезнең белән эшләү җиңел, Мәскәүгә күчеп киткәч тә, хезмәттәшлегебезнең дәвам итүе икеләтә сөенечле – бүген «Казан Гипронииавиапромы» компанияләр төркеме «Лужники» стадионын, «Лихоборы», «Саларьево», «Братеево» һәм «Митино» электродеполарын реконструкцияләү кебек Мәскәү өчен әһәмиятле объектларны проектлауда катнаша.

«Казан Гипронииавиапромы» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне, Марат Шакирҗанович, юбилеегыз белән тәбрик итәм! Чын күңелдән ныклы сәламәтлек, күңел күтәренкелеге һәм яхшы кәеф телим! Бәхет, иминлек һәм алга таба да яңа профессиональ биеклекләр яулаячагыгызга ышанам! Һәрвакытта да уңышлар юлдаш булсын Сезгә!

75 КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ

Реклама

Марат Айзатуллин,
«ТР Главинвестстрой»
ДКУ директоры

Һәрбер эшне ахырына кадәр җиткерү

Хөрмәтле Марат Шакирҗанович!

Югары дәрәҗәдәге җитәкче эшенең никадәр кыен, зур коллектив һәм аның хезмәт нәтиҗәсе өчен җаваплылыкның никадәр авыр икәнен Сез үз җилкәгездә татып беләсез. Төзелеш тармагының төрле җитәкче урыннарында эшләгәндә Сез һәр эшне – тузган торакны бетерү программасын гамәлгә ашырумы ул, Казанның 1000 еллыгына әзерләнүме, «Алабуга» МИЗ төзүме, Универсиада объектларын яки «ТАНЕКО» комплексын төзеп тапшырумы – ахырына кадәр җиткерергә сәләтле икәнлегегезне расладыгыз.

Дәүләт идарәсе баскычыннан акрынлап өскә күтәрелү, төзүче һөнәренең бөтен нечкәлекләренә төшенү Сезгә башкаланың гаять катлаулы төзелеш комплексы белән идарә итү өчен кирәкле тәҗрибә һәм белемнәрне үзләштерергә мөмкинлек бирде.

ТР ГИСУ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 50 яшь тулу көнегез белән котлыйм һәм ныклы сәламәтлек, бәхет, гаилә иминлеге телим! Һәрвакыт алга барырга, барлык планнарыгызны һәм ниятләрегезне уңышлы тормышка ашырырга насыйп булсын! Һәр мизгелнең кадерен белеп яшәгез, һәр туган көн белән хозурланыгыз һәм якыннарыгызны һәрвакыт яхшы кәеф белән шатландырыгыз! Һәрвакытта да шулай җиңел сөякле, яшь күңелле булып калыгыз! Озак һәм бәхетле яшәгез, үзегезне һәм якыннарыгызны язмыш иминлектән аермасын!



Чернышевский урамындагы офис бинасы – элеккеге Молоков табыш йорты (республика әһәмиятендәге архитектура һәм культура һәйкәле).

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ
генераль директоры

Эшегез белән Сез тармакның тарихын язасыз!

Хөрмәтле Марат Шакирҗанович!

«Грань» төзелеш компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Сезнең хезмәт юлыгыз – төзелеш тармагының бөтен нечкәлекләрен һәм идарә итү законнарын танып белү аша эзлекле һәм нигезле рәвештә гади хезмәткәрдән иң югары звено җитәкчесенә кадәр күтәрелү ул. Мәскәүнең төзелеш тармагы җитәкчесе булып билгеләнүегез дә очраклы гына булмады.

Профессиональлелегегез, тулысынча эшкә бирелә белүегез, оештыру сәләтегез республикабыз байлыгын арттыруга юнәлтелгән зур проектларны башкарып чыгарга мөмкинлек бирде: тузган торакны бетерү программасы тормышка ашырылды, Универсиада объектлары корылды, Казан метрополитены, «Кол Шәриф» мәчете, «Татнефть-Арена» спорт боз сарае кебек мөһим объектлар төзелде.

Чын күңелдән Сезгә бетмәс-төкәнмәс энергия, сәламәтлек, җаваплы эшегездә уңышлар телим. Эшлекле сыйфатларыгыз алга таба да катлаулы һәм әһәмиятле мәсьәләләрне уңышлы хәл итәргә ярдәм итсен, ә янәшәгездә һәрвакытта да тугры дуслар һәм фикердәшләр булсын!

Ринат Мохьянов,
«Татарстан Республикасы күперләре» АҖ генераль директоры

Олы бәхет Сезгә!

Хөрмәтле Марат Шакирҗанович! Чын күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Ике дистә елдан артык Сез төрле җитәкче урыннарда эшлисез, һәм бүген зур тәҗрибәгез, һөнәри белемегез, иң югары урыннарда эшләп, иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итә алырга мөмкинлек бирә. Башкаланың төзелеш комплексы белән идарә итү эшен нәкъ менә Сезгә ышанып тапшырулары гаҗәп түгел.

Гадел таләпчәнлегегез, һөнәри осталыгыгыз һәм җитәкчелек талантыгыз аркасында хезмәттәшләрегез һәм хезмәткәрләрегез арасында лаеклы абруй һәм хөрмәт казандыгыз.

Нигездә, Сезнең кебек җитәкчеләр булганга, Россия башкаласында заманча технологияләр кертелә, күп кенә уникаль проектлар уңышлы тормышка ашырыла. Һәм бу очраклы гына түгел. Төрле җитәкче урыннарда эшләгәндә Сез профессиональ формалашу юлында мөһим баскычлар уздыгыз. Белемнәрегез һәм тәҗрибәгез, зирәклегегез һәм принципиальлегегез әле озак еллар Мәскәү төзелеш комплексындагы уңышлы эшнең нигезе булып торыр, дип ышанам.

Марат Шакирҗанович, Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, иминлек һәм Ватаныбыз башкаласы һәм аның халкы файдасына алып барыла торган эшегездә яңа уңышлар телим!

ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:

тел: (843) 222-06-05

ФОНДНЫҢ ЮГАРЫ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ

Тәлгать Абдуллин, «ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты, августта үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Тәлгать Мидхәтович ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фондын 20 елга якын – 1997 елдан бирле җитәкли. Ике зур программаны – тузган торакны бетерү (1996–2004) һәм социаль ипотека (2005–2019) – үтәү нәкъ менә әлеге оешма өстенә төште. Бу программаларны финанслауның төп чыганагы сыйфатында бюджеттан тыш акчалар билгеләнде.

Тәлгать Абдуллинның хезмәтләре II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, Дуслык ордены, «Фидакарь хезмәт өчен» медале, «ТРның атказанган икътисадчысы» исеме белән бәяләнде.

Фәрит Хөснуллин,
ТР Сарман муниципаль районы башлыгы

Һәрвакыт уңышлар юлдаш булсын!

Хөрмәтле Тәлгать Мидхәтович!

Данлы хезмәт биографиягез – җәмгыять мәнфәгатьләре өчен фидакарь хезмәт итүнең ачык мисалы ул. Бүген Сез, ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды башкарма директоры буларак, югары җаваплылык, саекмас энтузиазм, максатка омтылучанлык һәм хәзерге заман икътисадындагы киләчәк үзгәрешләрне күрә белү кебек күркәм сыйфатларыгыз ярдәмендә торак программаларын тормышка ашыру мәсьәләләрен уңышлы хәл итәсез.

Хөрмәтле Тәлгать Мидхәтович, фонд коллективы үзен күптән инде эшне белеп, яратып башкаручы, иң катлаулы һәм зур мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле тәҗрибәле профессионаллар командасы итеп танытты. «Тузган торакны бетерү», «Социаль ипотека», «Россия гражданнарына – арзанлы һәм уңайлы торак», «1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү» программаларын тормышка ашыру кысаларында уннарча мең татарстанлы, шул исәптән безнең район кешеләре дә үзләренең яшәү шартларын яхшыртты.

Сарман муниципаль районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән 65 яшь тулу көнегез белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер һәм иминлек телим! Һәр башлангычыгыз тормышка ашсын! Киләчәктә дә яңа хезмәт казанышларыгыз булачагына һәм барлык ниятләгән проектларыгызның уңышлы тормышка ашачагына ышанам.

PRESSA.RU

ЗУР ТӨЗЕЛЕШ ПРОФЕССИОНАЛЫ

Юрий Аляшев, ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары, августта үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә.

Юрий Леонидович автошәһәрдә туып-үскән, 2008 елда Төзелеш министрлыгына килгәнче, Чаллы башкарма комитетында төзелеш идарәсенә җитәкчелек иткән. Министрлыкта ул сәнәгать объектлары төзелеше буенча эре проектлар өчен җаваплы. Аның хезмәте, белгәнебезчә, җимешләрен бирә: Татарстанда сәнәгать төзелеше кызу темплар белән бара, моннан тыш, тармакның күп кенә предприятиеләрендә җитештерүләрне модернизацияләү һәм үстерү программалары тормышка ашырылган.

Юрия Аляшевның хезмәтләре «ТРның атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем белән бәяләнгән.

Николай Глазков,
«Татнефть» ГАҖ
генераль директоры
урынбасары

Үз һөнәренең остасы

Хөрмәтле Юрий Леонидович!

Хезмәт биографиягезнең һәр чорында Сез көчегезне, мөмкинлекләрегезне һәм талантыгызны тулысынча зур һәм кечкенә мәсьәләләрне хәл итүгә багышладыгыз. Һәрвакыт намуслылык, сүзегездә торучанлык, кешеләргә аерым якын килә, катлаулы хәлләрдә килешүләргә бара белү кебек сыйфатларыгыз белән аерылып тордыгыз, һәм бу иң авыр проектларны да уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итте.

Нинди урында эшләсәгез дә, хезмәт юлыгыз профессиональ белемнәрегезнең – оештыру сәләте, җаваплылыгыгызның билгеләнгән планнарны тормышка ашыру белән үрелеп баруын күрсәтә. Исеме зур хәрефтән язылა торган төзүче, талантлы һәм тәҗрибәле җитәкче буларак, Сез алдыгызга куелган бурычларга ирешү юлында һәрвакыт гадәти булмаган юллар эзлəдегез. Республикада һәр елны яңа балалар бакчалары һәм мәктәпләр, театрлар һәм хастаханәләр, торак кварталлар һәм сәнәгать объектлары торгызыла икән, монда Сезнең дә хезмәтегез гаять зур.

Бүгенге истәлекле көндә Сезне 60 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәм һәм ихластан ныклы сәламәтлек, иминлек, күңел көрлеге һәм барлык башлангычларыгызның уңышлы тормышка ашуын телим! Йортыгызда һәрвакыт мәхәббәт һәм татулык яшәсен, янәшәгездә авыр чакларда таянырлык тугры дусларыгыз һәм фикердәшләрегез булсын!

Марат Айзатуллин,
«ТР Главинвестстрой» ДКУ директоры

Сез төзү өчен яратылган

Хөрмәтле Юрий Леонидович!
«ТР Главинвестстрой» ДКУ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм! Сез – төзү, яңарту өчен яратылган кеше. Укытучы һәм табиб кебек үк, кайчандыр тыныч тормыш һөнәре – төзүчелек эшен сайлаганнан соң, Сез аңа бер тапкыр да хыянәт итмәгәнсез. Хезмәт биографиягездә ак таплар юк – республика төзелеш тармагында икътисадның дәүләт һәм шәхси секторларында гади хезмәткәр булып та, җитәкче урыннарда да бердәй хезмәт куйдыгыз. Үзегезне тулысынча һәм төрле яклап күрсәтә, иң югары классллы профессионал һәм талантлы җитәкче итеп таныта алдыгыз.

ТР төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры урынбасары буларак, идарә итү осталыгыгыз тармак алдына куелган бурычларны уңышлы тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Җиңел төзелешләр булмады, юк һәм булмаячак та, ә уңышның сере команда эшендәге осталыктан, башкаларны куелган максатларга мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк итеп ирешергә этәрү сәләтеннән тора.

Хөрмәтле Юрий Леонидович! Безнең чор – җаваплы карарлар кабул итү һәм аларны тормышка ашыру чоры. Яхшы кәеф, максатчанлык һәм киләчәк өчен эшләргә әзер тору кебек сыйфатларыгыз Сезгә иң катлаулы һәм киң колачлы мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итсен! Үзегезгә һәм якыннарыгызга иң изге теләкләр юллыйбыз!

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ генераль директоры

Эшлекле сыйфатларыгыз катлаулы һәм мөһим мәсьәләләрне хәл итүдә юлдаш булсын!

Хөрмәтле Юрий Леонидович!
«Грань» төзелеш компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 60 яшьлегегез белән ихластан тәбрик итәм!

Бүгенге көндә төзелеш тармагы Татарстан Республикасының әйдәп баручы секторларының берсе булып исәпләнә. Инде күп еллар дәвамында төзелеш эшенә куйган хезмәтегез республика халкы тормышының матурлыгында һәм уңайлылыгында гәүдәләнә. Эшегез белән Сез тармакның тарихын язасыз: яңа сәнәгать җитештерүләре сафка баса, тормыш өчен әһәмиятле объектлар, торак микрорайоннар төзелә.

Югары һөнәри осталыгыгыз, оештыру сәләтегез һәм актив тормыш позициягез хезмәттәшләрегездә хөрмәт уята, ә таләпчәнлегегез һәм тәвәккәллегегез эшли белү белән үрелеп, уңышка ирешергә ярдәм итә.

Сезгә алга таба да республикабыз иминлеге өчен шундый ук нәтиҗәле хезмәт, шундый ук энергия телим! Уңышлар беркайчан да ташламасын!



Кол Гали урамындагы «Акчарлак» ябык йөзү бассейны, 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиада объекты.

PRESSA.RU

Фәрит Җиһаншин, «ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В. М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» ДАССУ баш табибы, сентябрьдә үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә.

ЧЫН ТАБИБ ҺӘМ ТАЛАНТЛЫ ОЕШТЫРУЧЫ

ТРның атказанган табибы Фәрит Җиһаншин Мамадышта һәм Алабугада, Әлмәттә һәм Казанда операция һәм җитәкчелек эшләрендә менә инде 36 ел дәвамында үзенә ышанып тапшырылган эшне оештыруда яңадан-яңа юллар эзләү белән мәшгуль. Фәрит Галимҗановичны Сәламәтлек саклау министрлыгында һәм аның белән эшләү бәхете тигән һәр коллективта югары бәялиләр.

ОПЕРАЦИЯ БҮЛМӘСЕННӘН – ОЕШТЫРУ ЭШЕНӘ

КДМИның дәвалау факультетын һәм «хирургия» белгечлеге буенча интернатура тәмамлаганнан соң, Фәрит Җиһаншин, 1980 елдан башлап, 24 ел дәвамында тәүлекләр буе диярлек вакытын операция бүлмәсендә үткәрә. Тугыз ел Мамадыш Үзәк район хастаханәсендә табиб-хирург булып эшли, хирургия бүлеге мөдире була, унике ел «Прикамнефть» НГТИ медсанчастенда хирургия бүлеген җитәкли, куышлыклар һәм кан тамырлары операцияләренең барлык төрләрен башкара, өч ел Алабуга шәһәрендә «Татнефть» ААҖ медсанчастен җитәкли.

Түләүсез медицина хезмәте һәм ирекле медицина иминияте буенча медицина ярдәменең күп төрләрен күрсәтү өлкәсендәге дәүләт гарантияләре программасы белән берләттән, медсанчасть түләүле хезмәтне дә киң җәелдерә. «Татнефть» ААҖнең үз акчасы һәм финанс ярдәме стационар һәм дәваханә биналарына капиталь ремонт үткәрергә, әр-яңа җиһазлар сатып алырга, офтальмология бүлеге ачарга һәм аны җиһазларга, нейрофизиологик тикшеренүләр өчен җиһазлар сатып алырга мөмкинлек бирә.

Инде 2004 елда ук Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре сәламәтлек саклау идарәсен җитәкләргә тәкъдим итеп, талантлы оештыручыны республикабызның нефть башкаласына чакырып китерүләре гаҗәп түгел. Иң әүвәл ул анда матди-техник базаны ныгыта, һәм бу диагностика һәм дәвалауның яңа ысулларын үзләштерергә ярдәм итә.

Үзәк һәм шәһәр балалар хастаханәләренә, психоневрология һәм туберкулезны дәвалау диспансерларына, бала тудыру йортына һәм стоматология дәваханәсенә капиталь ремонт үткәрелә, хастаханәләр өчен әр-яңа җиһазлар сатып алына.

2008 елда ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Әлмәт шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе көче белән «Татнефть» ААҖ медсанчасте базасында баш миендә кан әйләнеше бозылган авырулар өчен беренчел кан тамырлары бүлеге төзелә. Җиһаншинның гадәттәгечә нефтьчеләр тарафыннан хуплау тапкан инициативасы медсанчастьнең республиканың Көньяк-көнчыгышын югары технологияле медицина ярдәме белән тәэмин итүче яңа хирургия корпусын төзү һәм җиһазландыру белән тәгәлләнә. 2009 елда анда 407 коронарография, 122 коронар артерияләргә стент кую, 51 аортокоронар шунт кую үткәрелә.

Әлмәт бала тудыру йорты базасында медико-генетик консультацияне дә үз эченә алган гаиләне планлаштыру үзәге ачыла. Нефтьчеләр моның өчен 35 млн сум акча бүлеп бирә, аның 30ы лаборатор хезмәтне җиһазлауга китә. 2009 елның декабрендә районда Сәламәтлек үзәге ачыла. Федераль программа кысаларында район үзенең беренчел профилактика онкоүзәген булдыра.

Фәрит Галимҗанович авыл дәвалау учреждениеләре базасын яхшырту өчен дә күп эшләгән. Акташ участок хастаханәсе стационарына капиталь ремонт үткәрелә, Иске Багραж-Елховода табиб амбулаториясе өчен медицина җиһазлары сатып алына.

Реклама

Медицина ярдәменең тиз, үз вакытында күрсәтелүен арттыру максатында, район медицина учреждениеләренең санитар автотранспорты да яңартыла.

«Сәламәтлек» программасы буенча бала тудыру сертификатларын кертү ана һәм балалыкны саклау хезмәтен ныгытырга мөмкинлек бирә. Ун елга беренче мәртәбә районда үлү очраклары туудан азрак булып чыкты. «Ак чәчәкләр» конкурсында Фәрит Җиһаншин «Ел табибы» исеменә лаек була.

ЯҢА ВАЗЫЙФА

2010 елның июнендә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән Фәрит Җиһаншин В.М.Бехтерев исемендәге республика клиник психиатрия хастаханәсенең (РКПБ) баш табибы итеп билгеләнә. Аның җитәкчелеге астында, психиатрия практикасы тарихында беренче буларак, 2011 елда Татарстанда инвесторлар акчасына Казанның дүрт районы халкы өчен бер сменага 150 кеше кабул ителә торган яңа дәваханә төзелеп бетә.

2010 елдан РКПБда тәүлеклек 600 койка саны кыскартыла, 60 урынлы ике өй стационары ачыла, көндезге стационар урыннары саны 1,7 тапкыр арта. Госпитальдә үлүчеләр саны 2,3%тан 0,8%ка кими. Соматик һәм психик патологияләре бергә үрелгән каты авыруларга медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфаты яхшыра. Интенсив күзәтү палаталары ачыла, өстәмә рәвештә дәвалау-диагностика җиһазлары һәм каты авырулар өчен дарулар сатып алына. УЗИ һәм ФГДС кабинетлары барлыкка килә.

Баш табиб психиатрия хезмәтенә яшь белгечләрне тарту буенча да зур эш башкара. Соңгы биш ел эчендә хастаханәгә 103 табиб кабул ителгән, шуның 72се анда эшләүләрен дәвам итә. Яшьләрне җәлеп итүдә барлык мөмкинлекләр файдаланыла: уртак финанслау шарты белән, медико-профилактика факультетының 15 студентына дәвалау факультетында ике ел укулары өчен түләгәннәр. Бюджеттан тыш акча хисабына, соңыннан эшкә урнашу шарты белән, «психиатрия» белгечлеге буенча клиник интернатура өчен дә түлиләр. Биш табибка, торак шартларын яхшырту өчен, соципотека программасы буенча ТР Хөкүмәтенең 500 меңәр сум грантлары бирелгән. Нәтиҗәдә табиб-психиатр булырга теләүче студентлар саны арта. Баш учреждениенең табиблар белән тәэмин ителеше 61 процентка кадәр арткан.

РКПБ – республикада эксперт суд-психиатрия учреждениесе, ул ел саен 5 меңләп төрле төрдәге экспертиза үткәрә. Узган ел авыруларны психосоциаль тернәкләндерү бу өлкәдә яңа күтәрелеш булды.

«Сердәш 129» медико-психология хезмәте үз-үзеңә кул салу очракларын киметү максатына юнәлдерелгән, ул халык белән эшләүче белгечләр хәзерли, суицидаль гадәтләрнең сәбәпләрен анализлый һәм мониторинг үткәрә.

Фәрит Галимҗанович җитәкчелеге астында кризислы хәлләрдә халык белән эшләү өчен алты психолого-психиатрия бригадасы хәзерләнгән. Алар «Булгария» теплоходы батканда, «Казан» аэропортында «Боинг-737» һәлакәткә очраганда, «Адмирал» сәүдә үзәгендәге янгын вакытында һәлак булганнарның туганнарын озатып йөри. Телефон буенча тәүлек әйләнәсендә эшли торган ашыгыч психотерапия киңәше бирү хезмәте, «Serdesh1377» сайтында онлайн оештырыла. Хезмәтләре өчен Фәрит Җиһаншинга һәм белгечләргә Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ведомство бүлекләре һәм Рәхмәт хатлары тапшырыла.

Универсиада-2013 барышында медицина ярдәме оештыру һәм координацияләү штабы эшендә актив катнашуы өчен, баш табибка FISU* медицина дирекциясенең рәхмәт хаты тапшырыла.

Коллективның һәм аның җитәкчесенең уңышлары күз алдында. 2012 елда «Рухи сәламәтлек өлкәсендәге фидакарьлек өчен» Бөтенроссия конкурсының «Елның иң яхшы учреждениесе» номинациясендә РКПБга «Кече алтын күбәләк» статуэткасы тапшырыла. Учреждение дүрт ел дәвамында «ТРның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы лауреаты була: 2012 елда – «Сердәш 129» суицидология хезмәте, 2013елда –психоэндокринология хезмәте, 2014 елда – беренче психотик эпизод булегендә полипрофессиональ технологияләр, 2015 елда амбулатор психотерапия хезмәте диплом белән бүләкләнә.

Хөрмәтле Фәрит Галимҗанович!

В. М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсенең барлык коллективы исеменнән Сезне 60 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Алдыгызда әле бай һәм файдалы эшләр белән тулы күп еллар булачагына ышанабыз. Чын күңелдән Сезгә нык сәламәтлек, күңел көрлеге, барлык башлангычларыгызда уңышлар, гаилә иминлеге телибез! Юбилей елыгызда барлык ниятләрегез чынга ашсын, әякыннарыгызның мәхәббәте һәм хезмәттәшләрегезнең ярдәме йөрәгегезне һәрчак җылытып торсын!

*FISU – Халыкара студентлар спорты федерациясе.

PRESSA.RU

Асия Гудзь, Казан шәһәре «Торак-коммуналь хуҗалык һәм тышкы төзекләндерү буенча шәһәр программаларын тормышка ашыруны техник күзәтү хезмәте» МУП директоры, августта үзенең юбилеен билгеләп үтә.

Александр Поливин,
«Совет районы РТИ ИК»
ЖЧЖ директоры

Бөтен көчне куеп яшәргә һәм эшләргә!

Хөрмәтле Асия Йосыповна!

Тормышыгыздагы зур вакыйга – юбилейлы туган көнегез белән чын күңелдән котлауларыбызны кабул итегез!

Бу бәйрәм Сезнең энергиягезгә, бөтен көчегезгә яшәргә һәм эшләргә омтылуыгызга, Татарстан башкаласының торак-коммуналь хуҗалыгы һәм тышкы төзекләндерү буенча шәһәр программаларын тормышка ашыруны техник күзәтү өлкәсендәге катлаулы мәсьәләләрне дөрес һәм оператив хәл итә белүегезгә соклану өчен менә дигән сәбәп. Сез озак еллар шәһәребез төзелешен һәм аны төзекләндерүне күзәтүче уникаль структураны җитәклисез, һәм биредә данлы хезмәт юлыгыз һәм профессиональ уңышларыгыз чагыла.

Совет районы РТИ Идарәче компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән тәбрик итәм! Сезнең җитәкчелек талантыгыз, хезмәткәрләрегезгә сизгер караштa булуыгыз, бай тәҗрибәгез, максатчанлыгыгыз, югары һөнәри осталыгыгыз һәм теләсә нинди катлаулы хәлдә дә килешү таба белүегез игелекле эшегездә алга таба да уңышлар китерсен! Туганнарыгыз һәм якыннарыгыз – сәламәт һәм бәхетле, кәефегез шәп, күңелегез көр булсын! Бәхет, сәламәтлек һәм озын гомер телибез!

Олег Калимов,
«Мәскәү районы
ТКХ ИК»
ЖЧЖ директоры

Йортыгыз имин булсын!

Хөрмәтле Асия Йосыповна!

Хезмәттәшләрем һәм үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас тәбрик итәм! Иң әүвәл тирән соклануымны белдерәсем килә: Сез – гүзәл ханым, зур һәм мөһим предприятиене җитәклисез, һәм бу оста идарә итә белү талантына ия булуыгыз турында сөйли. Һөнәри осталыгыгыз, зирәклегегез һәм гаять зур тәҗрибәгез эшчәнлегегездә яңа биеклекләр яуларга ярдәм итә.

Безнең оешмалар арасындагы дуслык бер генә дистә ел белән исәпләнми, һәм ул елдан-ел ныгый бара. Ә партнерлар арасындагы дустанә мөнәсәбәт – һәрвакыт уңышлы эшнең нигезе. Сезнең кебек профессионал белән эшләү безнең өчен кыйммәтле тәҗрибә дигән сүз. Хезмәттәшлегебез күп кенә кыенлыкларны җиңеп чыгарга һәм мөнәсәбәтләребезнең тотрыклылыгын һәм ышанычлылыгын саклап калырга ярдәм итте, һәм моның нигезендә Сезнең һәм профессиональ командагызның тырыш хезмәте ята.

«Мәскәү районы ТКХ ИК» ЖЧЖнең барлык коллективы Сезгә уңышлар һәм эшегезнең чәчәк атуын, иң кыю планнарыгызның һәм башлангычларыгызның тормышка ашуын тели. Сезнең эшлекле сыйфатларыгыз, җитәкчелек таланты, хезмәттәшләрегезнең, партнерларыгызның ышанычы һәм ярдәме, дусларыгызның тугрылыгы яңа казанышларыгызның төпле нигезе булсын! Нык сәламәтлек, тормышка саекмас мәхәббәт, иминлек телибез!

Фото: Ксения Богданова

ТЫЙНАК ХЕЗМӘТКӘР ҺӘМ ОСТА ҖИТӘКЧЕ

Рузилә Һадиуллина

«Яшь көч» агрофирмасы җитәкчесе Рузилә Мирсәетовна Һадиуллина үзе турында сөйләгәнне яратмый. Ә менә Алабуга районындагы Дөм-Дөм авылы һәм аның халкы турында озак һәм рәхәтләнеп сөйли ала. Ярты гомереңне багышлаган җирнең кешеләре, иртәме-соңмы, туганнарың кебек якын була башлый шул.

Ә Рузилә ханымның тыйнаклыгы балачактан килә. Түгәрәге, үз мәнфәгатьләрең турында башкаларныкыннан соң гына уйларга гадәтләнелгән күп балалы гаиләләреннән. Ул гаилә Мөслим районының Туйгелде авылында яшәгән – Рузилә шунда туып-үскән. Әти-әнисе – гади кешеләр: әтисе гомер буе фермада мал-туар карый. Җиде баласын үзе кебек хезмәт сөючән, сүзендә нык торучан һәм... кеше хәленә керә белүчән итеп тәрбияли. Әйе, Рузилә ханым, җитәкче кеше өчен хас булмаганча, артык ярдәмчел, кызганучан кеше. Дөм-Дөмдә, ярдәм сорап, аның янына карты да, яше дә килә. Кем печән сорый, кем – төзелеш материаллары, ә кемгәдер дәвалану өчен акча кирәк була...

Беренче тапкыр Рузилә бирегә 1973 елда, Дөм-Дөм егете Әмир Һадиуллинга (аның белән Казан авыл хуҗалыгы институтында танышкан булалар) тормышка чыккач аяк баса. Әмирнең институтта укыган чагында ук авылга әйләнеп кайту, кече ватанында яшәү һәм аны торгызу хыялы була. Тик бу хыялны тиз генә тормышка ашырырга насыйп булмый. 1985 елга кадәр яшь гаиләгә Татарстан буйлап күчеп йөрергә туры килә. Өч авылны берләштергән «Кызыл нур» колхозы таркалып, Дөм-Дөмдәге хуҗалык аерым кооператив булып яши башлагач, аның җитәкчесе итеп Әмир Гыйльмуллович билгеләнә. «Яшь көч» исеме хуҗалыкка мирас булып күчә: 1929 елда төзелгән беренче колхоз шулай аталган була. Әмир Гыйльмуллович эшкә зур дәрт белән тотына. Әле бер, әле икенче идеяне тормышка ашыра: авылда асфальт юл салдыра, газ һәм су үткәртә, 160 балага исәпләнгән ике катлы мәктәп салдыра. Кызганыч, бу мәктәп инде элекке кебек гөрләп тормый – балалар саны җитмәгәнлектән, аны япканнар. Хәзер Дөм-Дөм балаларын автобус белән Шурнәк авылына йөртеп укыталар. Дөрес, мәктәп бинасы сакланган – анда балалар бакчасы, китапханә, медпункт урнашкан.

1998 елда Әмир Гыйльмулловичны Алабугага зуррак эшкә күчерәләр, һәм шуннан соң иренең Дөм-Дөмдәге эшен Рузилә ханым дәвам итә. Моңа кадәр ул шушында ук икътисадчы булып хезмәт иткән була, шуңа күрә җитәкчелекне җиңел кабул итә.

Ә җиде елдан соң Әмир Гыйльмуллович вафат була. Аңа әле бу вакытта 56 яшь кенә була. Бик авыр вакытлар була ул. Рузилә Мирсәетовна аны ничек кичергәнен үзе генә белә.

Ире вафатыннан соң да Рузилә ханым үз эшенә тугры кала. Авыл хуҗалыгы өчен табигать шартларының гел уңай килеп тормавына карамастан, «Яшь көч» агрофирмасы начар яшәми. Бүген аның өч мең гектар җире, биш комбайны, унсигез тракторы бар. Кредитлар алмаска, үз көчләренә таянырга тырышалар. Бирегә 50 кеше даими хезмәт итә, чәчү һәм урып-җыю вакытында эшләүчеләр саны ике тапкыр арта. Алар арасында күрше авыллардан вахта белән килеп йөрүчеләр дә бар. Хәтта 2010 елгы коточкыч корылык вакытында да агрофирмада мөгезле эре терлекнең баш санын киметмәделәр – алар барлыгы 1170 баш, шуларның 330ы – савым сыер. Печәнне хәтта Пермь краена барып хезерләргә туры килә. Нишләмәк кирәк, баш санын киметсәң, эш урыннары да кыскарачак. Авыл кешесенә эшсез яшәп булмый.

Билегеле, авырлыклар юк түгел. Хуҗалыкка әйләнештәге акчалар җитми. Бер литр сөтнең сатып алу бәясе нибары 17,5 сум – кибетләрдә эчә торган су да кайчак кыйммәтрәк тора. Эшче куллар җитешми, аеруча бүгенге сыер савучыларга һәм терлек караучыларга алмашка килердәй яшьләр аз. Нихәл итәсең, тирестә казынасылары килми... Юкса, «Яшь көч»тә хезмәт кешесенә һәрвакыт хөрмәт белән карыйлар, аңа ничек тә ярдәм итәргә тырышалар. Биредә туклану да бушлай, шифаханәләргә юлламалар алу белән дә булышалар, Сабантуй бәйрәмнәрендә кыйммәтле бүләкләрне дә кызганмыйлар. Ял вакытларын да матур итеп оештырырга тырышалар: үз көчләре белән концерт-спектакльләр куялар, эстрада артистларын да чакыралар. Балачагында Рузилә ханым үзе дә артистка булырга теләгән. Әмма кызганычка (әллә бәхеткәме), гади авыл балаларын артистлыкка алмаслар, дип шикләнгән. Ул бик матур җырлый да, спектакльләрдә дә оста уйный.

Әмма иң мөһиме, билгеле, бу түгел. Рузилә Мирсәетовна Дөм-Дөм өчен җанын бирергә әзер. Авылның яшәвен, авылдашларына яхшы хезмәт урыннары булуын, димәк, бу җирдә тормыш дәвам итүен тели. Безнең заман өчен бу бик кыйммәтле нәрсә.

Хөрмәтле Рузилә Мирсәетовна!

Чын күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Без, «Яшь көч» агрофирмасы хезмәткәрләре, Сезне игътибарлы, җаваплы һәм зирәк җитәкче буларак беләбез. Бернинди кыенлыклар да Сезне тугры юлдан тайпылдыра яки кешелеклелек һәм ярдәмчеллек кебек сирәк очрый торган сыйфатларыгызны югалттыра алмас. Без һәр эшегезнең уңышлы булып чыгачагына ышанабыз. Бу исәлекле көндә Сезгә нык сәламәтлек, озын гомер, бәхет һәм иминлек телибез!

Реклама

PRESSA.RU

Татарстан – яхшы кешеләргә генә түгел, гаҗәеп кызыклы риваятьләргә дә бай төбәк. Кайсы гына районга барып төшмә, үз якларына хас төгәллекләр белән тулы борынгы хикәятләрне сөйләп бирүче, барысыннан да хәбәрдар кеше һәрвакыт табыла.
«Татарстан» журналы республикабыз риваятьләрен туплады һәм алар белән сезне дә таныштыра бара.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: АК БАЙБИКӘ

Тенешкә – сарайлы авылга барган һәркем андагы матур, борынгы, тик, ни кызганыч, ярымҗимерек утарны күрми калмыйдыр. Бу – князь Гагариннар йорты. Аның белән бәйле борынгы риваять тә бар. Гүзәл, ләкин сагышлы риваять – чөнки җавапсыз мәхәббәт турында ул.

Димәк, болай. Яшь княжна – Сергей Сергеевич Гагаринның кызы – чибәр генә түгел, саф-чиста, белемле, өстәвенә, үзе кебек үк яшь һәм ваемсыз дворяннар – революциягә кадәрге «алтын яшьләр» белән рәхәтләнеп күңел ачарга да яраткан.

Шуңа күрә дә байлар йортында җәй саен яшьләр – княжнаның күпсанлы кардәшләре һәм танышлары кунак булып яткан. Һәм берзаман кыз кунакларының берсенә – бик тә сөйкемле, әмма җилбәзәк егеткә чын йөрәктән, гашыйк булган, тик өметсез. Серле карашлар, яшерен хатлар, перчаткасы белән аның кулына җиңел генә кагылып үтү, аның йокы бүлмәсе яныннан үкчәләрен шыкылдатып узу һәм үткән гасырның үткәнендәге туташларга хас башка шундый хәйләләр нәтиҗәсез булып чыга, ә сөекленә күзләр урынына йөрәкләр ясалган смайликлар җибәрергә мөмкинлек бирүче мобиль телефоннарның хәбәре дә юк бит әле! Ул чактагы әхлак кагыйдәләре дә гашыйк кызга җиңел генә хисләрен белдерергә рөхсәт итми. Алай кабул ителмәгән. Бу әдәпсезлек санала. Әмма княжна замана тәртипләре белән исәпләшеп тормаган һәм йөрәге сайлаган егеткә менә шушында, кызлар залында, сөюен белдергән, диләр. Тик егет, дворян булса да, хәзергечә әйткәндә, җитди мөнәсәбәтләргә әзер булмаган. Һәм бик тә нәзакәтле гыйбарәләр ярдәмендә княжнага шул хакта белдергән дә. Үпкәләтмәслек итеп, янәсе.

Әмма кыз мондый гарьлекне кичерә алмаган, һәм шул төндә үк үз-үзенә кул салган.

Кайгылы ата сөекле кызын мордарлар зиратына күмәргә теләмәгән. Ул аның өчен кабер урынын йортның террасасы астында сайлаган. Кайберәүләр ул табутны бинаның цоколь өлешендә томалап куйган, дип исәпли. Һәм шуннан башлана да инде. Мәрхүмә княжна, өрәкләргә хас булганча, ап-ак киемнәрдән төннәрен йорт идарәчесе янына килә башлый. Ул, куркып, ул бу хакта князьгә җиткерә. Һәм Сергей Сергеевич, кызын күрү өчен, һәр төндә икенче катка күтәрелеп, аны көтәргә керешә. Ул кайчакта килә, һәм бу әтисенә яраткан кызын югалту кайгысын беркадәр җиңеләйтә.

Бервакыт әлеге йортка княжнаның сөйгәне тагын килә. Нәрсәсен җуйган булгандыр – монысы билгесез. Әмма кайчандыр аны яраткан, ләкин җавапсыз мәхәббәтеннән башка яшәргә теләмәгән кызны күргәч, тораташ булып кала. Ак байбикә, күлмәк итәге белән сөйгәненә тияр-тимәс узып китә. Әмма бу кагылу эзсез узмый, егет, ябыгып-кибеп, бер ай эчендә вафат була. Сөйгәнен алып киткәч, княжна озак елларга тынычланып кала. Тик бөтенләйгә түгел. Тенештәге курку белмәсләр Ак байбикәнең әле дә төннәрен иске утарның икенче катында йөрүен күрүләре турында ант итәләр. Түземлегеңне җыеп һәм мышнамыйча, үзеңне сиздермичә көтсәң, аны күрергә дә була, ди. Иң мөһиме, күп күрергә теләүчегә аның күлмәк итәге генә тиеп китмәсен…

Яшь һәм сөйкемле егетләргә гомумән өрәккә карарга киңәш итмиләр – княжнаның аны үз гомерен корбан итүнең сәбәпчесе дип кабул итүе һәм үз янына алуы мөмкин.



Фото: Солтан Исхаков

БУ АЙ КӘЕФЕ: БУЙ-БУЙЛЫ

Безнең узган сандагы балык шулпасыннан авыз итәргә өлгермәүчеләр Каратайга балык шулпасы фестиваленә юл тотты. Бирeдә, Кама Тамагы районындагы иң балыклы җирендә, июль аенда «Идел–Кама» балык тоту чемпионаты һәм Кама балык шулпасы фестивале булып узды. Кама–Идел буенда балык тотучыларның һәм балык шулпасы пешерүчеләрнең иң шәпләре үзара ярышты һәм бәйрәмгә җыелган халыкны әлеге шулпадан авыз иттерде.

Балык тоту чемпионатында һәрберсендә 2–3 кеше булган 18 экипаж катнашты. Балык тотучылар, үз катерларына утырып, Куйбышев сусаклагычы акваториясенә, яки Камага юл тотты. Җиде сәгать – иртә таңнан алып төшке ашка кадәр балык тотканнан соң, пешекчеләр командасы тотылган балыктан шулпа пешерергә керешә. Һәр команданың – үз рецепты. Алар киемнәре белән дә аерылып торалар иде. Балык темасына багышлап иң матур киенүчеләр дип... бухгалтерлар танылды.

– Җөен бөтен коллектив белән табигатьтә җыелу – бик шәп күренеш. Балык шулпасын өч кыз һәм бер ир-ат – машина йөртүчебез әзерли. Ә без – җанатарлар сыйфатында, – дип сөйли ТР Кама Тамагы районының «Үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ хезмәткәре Миләүшә Хәбибуллова.

–Ел саен безнең районга 200 меңләп балык тотучы килә. Соң, гаиләләре белән килсеннәр! Әлеге максат белән без бирeдә кемпинг булдырырга планлаштырабыз. Кама Тамагы – ул гаилә белән ял итү урыны! – диде район башлыгы һәм дүрт бала атасы булган Павел Лоханов.

«Кама киңлекләре» базасын тәкъдим иткән балыкчы Андрей Ферафонтов үзенең Казаннан килгән дусты Александр Шаповалов белән 30 килограмм 800 грамм балык тоттылар. Әлеге экипаж «Иң күп балык тотучы» номинациясендә беренче урын алды һәм «Иң эре судак» номинациясендә җиңү яулады.

– Минемчә, балык тоту спортын үстерү – бик кирәкле эш, бигрәк тә Идел һәм Кама бергә тоташкан акваториядә. Республикада балык тоту өчен моңардан да яхшырак урын юктыр, – диде Андрей Ферафонтов.

PRESSA.RU

ТЕЛЕМ МИНЕМ – ДУСТЫМ МИНЕМ
ТАТАРСТАН
КАМСКИЙ СУДАК
ТАТАРСТАН
«ТАТАРСТАННЫ» ТАТАР ҺӘМ
РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ УКЫГЫЗ!